# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2020 2(26)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ХӘМИДОВА Ч.И.

## БУ САНДА

Баш редактор сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

### ТАССР ТӨЗЕЛҮГӘ – 100 ЕЛ

*Кириллова З.Н.* 1920–1930 елларда ТАССРда тел сәясәте . . . . . 9
*Асылгәрәев Ш.Н., Гайнуллина Г.Ф.* ТАССР оешуның башлангыч чорында татар теле белеменең торышы . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Заһидуллина Д.Ф.* 1920 еллар (1920–1934): татар әдәбияты һәм әдәбият белеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
*Миңнуллин К.М.* Татар профессиональ җырларының жанр буларак формалашу чоры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
*Ямалтдинов И.И.* ТАССР оешуының татар фольклористикасы үсешенә йогынтысы: 1920–1930 елларда фәнни проблемалар һәм аларны тикшерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
*Улемнова О.Л.* 1920–1930 елларда ТАССРның татар рәссамнары . 66
*Герасимова Н.В.* Казанда Көнчыгыш музее. Гамәлгә ашырылмаган проект . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
*Галимова Э.М.* ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан татар музыка сәнгате үсешенә күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Сөләйманов Җ.Ш., А.Р. Гатиатуллин, Гыйльмуллин Р.А., Хөсәенов А.Ф.* Татар теле һәм яңа инфокоммуникацион технологияләр . . . . . . 92
*Галимова О.Н.* Диахрон һәм синхрон аспектларда хайван атамалары синонимиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Заһидуллина Д.Ф.* Г. Ибраһимов – әдәбиятчы: яңа чыганаклар (15 томлык академик басманың 6–7 томнары басылу уңае белән) . . 114
*Миңнуллина Ф.Х.* Илем тарихы – халкым язмышы (1920–1930 еллар татар драматургиясе мисалында) . . . . . . . . 126

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Рәсүлов А.Н.* Фирганә үзәнендә төбәк матбугатын һәм полиграфия эшен оештыруда татарларның катнашуы . . . . . 134
*Сибгатуллина Г.Р.* Татарлар һәм ислам реформасы проекты: фәнни бәхәсләр, яңа карашлар . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Миңнуллин К.М., Закирова И.Г.* Татар әкиятләрен барлау юлында . 152

### СӘНГАТЬ

*Солтанова Р.Р.* Казан сәнгать мәктәбендә театр декорациясе бүлеге: тарихы һәм үсеш перспективалары . . . . . . . . . . . 159
*Газиев И.М.* Ибраһим Адамантов кем ул? . . . . . . . . . . . . 167

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

*Кәрам Г.* Казанда татарча спектакльләр (Театр вә музыка кыйсеме) . 178
*Мифтахетдинова Н.М.* Татарча язу машиналары хакында
М. Идрисовның хәреф комиссиясе алдында ясаган чыгышы . . . 184

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Ахунов А.М.* Исхак Әхмәровка багышланган яңа китап турында . . 190

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ


От главного редактора . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

**100 ЛЕТ ТАССР**

*Кириллова З.Н.* Языковая политика ТАССР в 1920–1930-е годы . . 9

*Асылараев Ш.Н., Гайнуллина Г.Ф.* Тенденции развития татарского языкознания в период становления ТАССР . . . . . . . . . . . 19

*Загидуллина Д.Ф.* 1920-е годы (1920–1934): татарская литература и литературоведение . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

*Миннуллин К.М.* Период становления жанра татарской профессиональной песни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

*Ямалтдинов И.И.* Развитие татарской фольклористики после образования ТАССР: научные проблемы и их исследование в 1920–1930-х гг. . . . . . . . . . . . . . . . . 58

*Улемнова О.Л.* Татарские художники первого десятилетия ТАССР . . 66

*Герасимова Н.В.* Музей Востока в Казани. Нереализованный проект . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80

*Галимова Э.М.* Обзор формирования и развития татарского музыкального искусства: к 100-летию образования ТАССР . . . . 85

**ЯЗЫКОЗНАНИЕ**

*Сулейманов Дж.Ш., Гатиатуллин А.Р., Гильмуллин Р.А., Хусаинов А.Ф.* Татарский язык и новые инфокоммуникационные технологии . . . 92

*Галимова О.Н.* Синонимия названий животных в диахронном и синхронном аспектах . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103

**ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ**

*Загидуллина Д.Ф.* Г. Ибрагимов – литературовед: новые источники (к выходу в печать 6–7 томов академического 15-томного издания писателя) . . . . . . . . . . . . . . . . . 114

*Миннуллина Ф.Х.* История страны – судьба народа (на примере татарской драматургии 1920–1930-х гг.) . . . . . . . . 126

**СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ**

*Расулов А.Н.* Участие татар в создании печатного и полиграфического производства в Ферганской долине . . . . . . 134

*Сибгатуллина Г.Р.* Татары и проект реформы ислама: учёные дискуссии и новые подходы к изучению . . . . . . . . . . 143

**НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО**

*Миңнуллин К.М., Закирова И.Г.* История изучения татарских народных сказок . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

**ИСКУССТВО**

*Султанова Р.Р.* Театрально-декорационное отделение в Казанской художественной школе: история и перспективы развития . . . . . 159

*Газиев И.М.* Ибрагим Адамантов . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Карам Г.* Татарские спектакли на казанской сцене . . . . . . . . . 178
*Мифтахетдинова Н.М.* Доклад М. Идрисова на совещании по установлению арабских шрифтов на пишущие машины . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184

## НОВЫЕ КНИГИ

*Ахунов А.М.* Новая книга об Исхаке Ахмерове . . . . . . . . . . 190

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

## БАШ РЕДАКТОР СҮЗЕ

XX гасыр башында узган инкыйлаби үзгәрешләр, гражданнар сугышы илнең иҗтимагый-сәяси яшәеш нигезләрен тулысынча үзгәртте. Социаль катламнар арасында барган кискен бәрелешләр, еш кына, илдәге халыкларның милли-азатлык хәрәкәте белән бергә үрелеп барды. Бу күп гасырлар дәвамында империя шартларында көн күргән халыкларның үз хокуклары өчен көрәше, ил эчендә туган вазгыятьтән файдаланып, тарих мәйданында үз урыннарын билгеләү омтылышлары белән бәйле иде. Нәтиҗәдә ил картасында яңа республикалар барлыкка килде.

Тарихка күз салсак, татар халкының да бу көнгә билгеле бер тәҗрибәләр аша килүе ачык күренә. XX гасыр башы милләт яшәешенең төрле өлкәләрендә туган үзгәрешләр Болак арты республикасы, Идел-Урал Штаты, Татар-Башкорт Җөмһүрияте, Татар Социаль Советлар Республикасы кебек сәяси проектларны мәйданга чыгара. Әмма төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә бу проектлар чынга аша алмый, аларга алмашка Татарстан Автономияле Социалистик Совет Республикасын төзү килә.

Күпсанлы фикер алышулардан соң, 1920 елның 27 маенда, РСФСР Халык Комиссарлары Советы рәисе В.И. Ленин, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты җитәкчесе М.И. Калинин һәм әлеге комитетның сәркәтибе А.С. Енукидзе тарафыннан «Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасы төзелү» турында Декретка кул куела. 1920 елның 25 июнендә, әлеге Декретның сигезенче маддәсе нигезендә, яңа төзелгән республиканың идарә эшләре Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан оештырылган Вакытлы Революцион Комитетка тапшырыла. Аның белән җитәкчелек эшләре күренекле сәясәтче һәм фикер иясе Сәхибгәрәй Сәетгалиевкә (1894–1938) йөкләнә. Шул рәвешле, татар дәүләтчелек тарихы сәхифәләренең яңа битенә нигез салына.

ТАССР төзелү һәм аның идарә органнары формалашуга ук, җирле Мәгариф халык комиссариаты составында Фән бүлеге оештырыла. Аңа төбәкне, аның «җитештерү көчләрен», шулай ук социаль, тарихи һәм этнографик үзенчәлекләрен өйрәнү өчен фәнни эшчәнлек оештыру таләбе куела. Бүлек нибары бер ел эшләп кала, соңрак аның функцияләре тагын да киңәйтелеп, Гыйльми үзәккә (Академүзәк) йөкләнә. Соңгысы РСФСР Мәгариф халык комиссариатының баш Академүзәге – 1921 елның 11 февралендә ХКС Декреты нигезендә гамәлгә куелган әлеге җитәкче орган структурасындагы яңа бүлекчә үрнәгендә төзелә.

Үзенең структурасы һәм бурычлары буенча ТАССРның Мәгариф халык комиссариаты Академүзәге төбәк фәнни үзәге, ул вакыттагы рәсми тел белән әйткәндә, «милли мәдәниятне үстерүнең төп җитәкче идея үзәге» була. Бик күп мәсьәләләр, шул исәптән күпсанлы фән тармаклары, уку-укыту, мәгариф, сәнгать һәм мәдәният өлкәсендәге эшчәнлекләр, республика масштабында туган якны өйрәнү әлеге фәнни һәм мәдәни-агарту оешмасы компетенциясендә була.

Академүзәк эшчәнлегенең иң нәтиҗәле чоры 1925–1927 елларга туры килә. Бу вакытта аны күренекле галим һәм татар әдәбияты классигы, иҗтимагый-сәяси эшлекле Г. Ибраһимов җитәкли. Үзенең

көрәштәшләре белән бергә ул безнең полиэтник республика халыкларының рухи тормышын һәм тарихын һәрьяклап өйрәнү, аларның милли-мәдәни үзаңын үстерү, белем дәрәҗәсен күтәрү өчен гуманитар фәннәр өлкәсендәге галимнәрне берләштерү юлыннан бара. Бу тырышлыкның нәтиҗәсе дә күренә: Академүзәктә Һ. Атласи, Җ. Вәлиди, В. Воробьёв, С. Сингалевич, М. Худяков, Г. Шәрәф, Г. Рәхим һ.б. кебек күренекле галимнәр эшли.

1923 елның язында Академүзәк һәм Бөтенроссия Көнчыгышны өйрәнү фәнни ассоциациясе тарафыннан Татарларны өйрәнү фәнни җәмгыяте төзелә, ул 1923–1927 елларда Академик үзәк структурасына керә. Бу җәмгыять гаять зур эш җәелдерә: татар халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, телен, әдәбиятын, мәдәниятен өйрәнүне ныклы гыйльми нигезгә куя. Бу өлкәдә СССРдагы 120 дән артык фәнни оешма һәм кайбер чит ил фәнни үзәкләре белән элемтә урнаштыра, җәмгыятнең үз басма органын булдыра. 1930 елга кадәр чыгып килгән «Вестник научного Общества татароведения» басмасы публикацияләренең дәрәҗәсе белән һәрдаим фәнни җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итеп тора.

Шунысы мөһим: Академүзәк яңа хакимият шартларында, иҗтимагый һәм рухи тормышның барлык яклары белән дәүләт-монополия идарәсе системасы формалашу шартларында эшчәнлек алып бара. Иске тәртипләр белән араны өзү (Октябрь инкыйлабы кебек халык революцияләре шуның белән аерылып торалар да) барлык элеккеге структураларның тарихи аренадан китүен аңлатмый. «Академик үзәк» исеме үзе үк Фәннәр академиясе гамәлиятен фәнни һәм мәдәни ресурслар интеграторы буларак билгели, өстәвенә, советлар Россиясендә академик система төрле формаларда яшәвен дәвам итә. Татарстан республикасы һәм аның башкаласы – университетлы Казан өчен төбәк академик учреждениесе идеясе якын була.

Академүзәк озак яшәми. Егерменче еллар азагында аның эшчәнлеге акрынлап туктый, ә 1930 елның язында ул хакимият карары белән юкка чыгарыла. Күп кенә фәнни, мәгариф һәм туган якны өйрәнү оешмалары һәм берләшмәләре дә Академүзәк язмышына дучар була. Алар бүген «Сталин социализмы» дип аталган иҗтимагый корылышның сәяси һәм идеологик чынбарлыгына туры килеп бетмиләр. Бары тик Академүзәкнең варисы буларак оештырылган һәм гуманитар фәннәрнең барлык юнәлешләре буенча диярлек тикшеренүләр алып барырга тиешле Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты гына (соңыннан Тел, әдәбият һәм тарих институты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) вакыт сынавын узган һәм бүген дә уңышлы гына эшләп килә.

Академүзәкнең киңкырлы эшчәнлеген республикабызда академик фән традицияләре үсешенең мөһим этабы буларак бәяләнә. Әлеге фикерләр исәпкә алынып, «Фәнни Татарстан» журналының бу санында фәнни җәмәгатьчелек игътибарына ТАССР төзелгәннән соң гуманитар фәннәр өлкәсендә барган үсеш-үзгәрешләр турында фәнни мәкаләләр тәкъдим ителә. Алар журналның «ТАССР төзелүгә – 100 ел» рубрикасына туплап бирелә.

УДК 35.082.23

*З.Н. Кириллова*

# 1920–1930 ЕЛЛАРДА ТАССРДА ТЕЛ СӘЯСӘТЕ

Данная статья посвящена исследованию языковой политики ТАССР в 20–30-е годы XX века. В 1920-е годы в республиках широко развивается процесс объявления государственным языком языка коренного населения, и Татарская Автономная Советская Социалистическая Республика не остается в стороне от этого течения. В работе была проанализирована деятельность Центральной комиссии по реализации татарского языка, а также сделан обзор применения татарского языка в сфере образования.
**Ключевые слова:** ТАССР, татарский язык, государственный язык, применение языка, обучение татарскому языку.

This article is devoted to the study of the language policy of the TASSR in the 20–30s of the XX century. In the 1920s, the process of declaring the indigenous language as the official language of the state was widely developed in the republics, and the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic did not remain aloof from this trend. The work analyzed the activities of the Central Commission for the implementation of the Tatar language, and also reviewed the use of the Tatar language in education.
**Keywords:** TASSR, Tatar language, state language, language use, teaching the Tatar language.

Милли телләрнең дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүе, гадәттә, илдә барган иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни үзгәрешләр, халыкларда милли үзаң уяну белән бәйле. Элек-электән башка милләт вәкилләрен христиан диненә күчерү сәясәте алып барган патша хөкүмәте чит халыкларның, шул исәптән татарларның да, иҗтимагый-сәяси һәм рухи-мәдәни үсеше белән кызыксынмый, киресенчә, моңа һәрьяклап аяк чалырга тырыша. Шуңа күрәдер дә, большевикларның милли мәсьәләгә аерым игътибар юнәлтүләре бернинди хокуксыз хәлдә «инородец» булып яшәгән Россия халыкларында зур яклау таба.

1917 елның 2 (15) ноябрендә басылып чыккан һәм яшь совет хөкүмәтенең беренче документларыннан саналган «Россия халыклары хокуклары декларациясе» буенча, Россия халыкларының тигезлеге һәм суверенлыгы; мөстәкыйль дәүләт төзергә мөмкинлек биргән ирекле үзбилгеләнү хокукы; барлык милли һәм дини өстенлекләрне һәм чикләүләрне бетерү; милли азчылык һәм этнографик төркемнәрнең ирекле үсеше тәэмин ителергә тиеш була [Советская политика..., с. 1].

Билгеле булганча, соңрак Россиядә формасы буенча милли, ләкин эчтәлеге буенча социалистик мәдәният формалаша [Беликов, с. 369]. Россиядәге халыкларның язмышы һәм телләренең үсеше күп

очракта автономиягә ия булу яки булмауларына, чикләренең ничек билгеләнүенә бәйле була. Әлбәттә, союздаш республикаларның хәле күпкә яхшырак, мөмкинлекләре күбрәк була.

Милли мәсьәләгә күчерелгән сыйнфый көрәш идеясе гражданнар сугышы кабынып китүдә дә шактый зур роль уйный. Канкойгыч сугышта җиңүгә ирешкәннән соң, совет хөкүмәте яңадан милли мәсьәләгә әйләнеп кайта. Һәм 1922 елга кадәр хөкүмәтнең милли сәясәт нигезләре салына [Советская политика..., с. 371]. Коммунистлар партиясенең X һәм XII съездларында, башка проблемалар белән бергә, милли мәсьәләгә дә зур урын бирелә. 1921 елның 8–16 мартларында Мәскәүдә узган X съезд карарлары аеруча игътибарга лаек, чөнки бу съездда рус булмаган халыкларның үсешен тизләтү буенча партиянең бурычлары итеп түбәндәгеләр билгеләнә: «...б) җирле халыкның тормыш-көнкүрешен һәм психологиясен яхшы белгән шул як кешеләреннән төзелгән һәм аларның ана телендә эш алып баручы суд, администрация, хуҗалык хөкүмәт органнарын үстерергә һәм ныгытырга; в) ана телендәге матбугат, мәктәп, театр, клуб эше һәм гомумән мәдәни-агарту учреждениеләрен үстерергә; г) идарә итүнең барлык тармакларында һәм беренче чиратта мәгариф өлкәсендә эшләү өчен, рус булмаган халыклар арасыннан квалификацияле эшчеләр һәм совет-партия хезмәткәрләрен әзерләүне тизләтү максатында, ана телендә эшләүче курслар, гомуми белем бирү һәм профессиональ-техник характердагы мәктәпләрнең киң челтәрен булдырырга һәм үстерергә (беренче чиратта кыргызлар, башкортлар, төркмәннәр, үзбәкләр, таҗиклар, азәрбайҗаннар, татарлар, дагстанлылар өчен)» [КПСС в резолюциях ..., с. 366].

Нәкъ шушы съезд карарларына нигезләнеп, 1920 елларда союздаш һәм автономияле республикалардагы украин, грузин, үзбәк, әрмән, азәрбайҗан, мордва, татар һәм башка дистәләгән телләр үз республикалары чикләрендә дәүләт теле итеп игълан ителә. Күпчелек очракта республика атамасында чагылыш тапкан җирле халыкның теле республиканың директив органнары карарлары нигезендә дәүләт теле дип билгеләнә. Әлеге карарларда дәүләт теле хакындагы нигезләмәне тормышка ашыру, аны дәүләт аппаратында, суд һәм прокуратурада, җирле хакимият органнарында, халык мәгарифендә, вакытлы матбугатта һәм һәр җирдә куллану буенча конкрет чаралар билгеләнә. Мәсәлән, Урта Азия республикаларында, Татарстанда һ.б. бу процесс шул рәвешчә үтә.

Шул ук вакытта кайбер республикалар төп җирле халыкның телен дәүләт теле дип игълан итү хакында карар чыгару һәм аны тормышка ашыру буенча эш алып бару белән генә чикләнмиләр, үзләренең конституцияләренә бу хакта аерым маддәләр дә кертәләр. Мәсәлән, өч союздаш республика – Грузия, Әрмәнстан, Азәрбайҗанның – һәм бер автономияле – Абхаз республикасының конституцияләрендә дәүләт теле хакындагы маддәләр урын ала. Башка респуб-

ликаларның конституцияләрендә исә мондый маддәләр билгеләнми [Ханазаров, с. 57–58].

Күренгәнчә, җирле халык телен дәүләт теле итеп игълан итү процессы 1920 елларда барлык республикаларда киң рәвештә җәелеп китә һәм Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы да әлеге агымнан читтә калмый: 1921 елның 25 июнендә, ягъни ТАССР төзелүнең бер еллыгы көнендә татар теле беренче тапкыр рәсми рәвештә дәүләт теле дип игълан ителә. Нәтиҗәдә 1920 елларда татар телен иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә гамәлгә кертү буенча киң эш җәелдерелә: татар теле дәүләт оешмаларында да, мәгариф эшендә дә, барлык шәһәр, район һәм авыл җирлекләрендә дә дәүләт теле сыйфатында кулланыла башлый [Кириллова, 2019, б. 76].

ТАССРда татар телен гамәлгә кую эшләре белән гомуми җитәкчелек итү вазифасын 1921 елның 12 сентябрендә төзелгән Үзәк комиссия башкара. Комиссия республикадагы дәүләт оешмаларында һәм районнарда татар телен гамәлгә кую эшләрен оештыра. Җитәкчелек итү, законнар чыгарудан тыш, Үзәк комиссия татар хезмәткәрләрен исәпкә алу һәм эшкә урнаштыру, курслар оештыру, татарча шрифтлы язу машиналары әзерләү, башка республикалардагы телне гамәлгә кую комиссияләре белән бәйләнеш урнаштыру һ.б. бурычларны да үти.

Үзәк комиссиянең 1921–1924 еллардагы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, татар телен гамәлгә куюның юнәлешләре, бурыч һәм максатлары билгеләнә. 1925–1927 еллардагы күп санлы съезд һәм киңәшмәләрдә татар телен төрле тармакларда тормышка үткәрү мәсьәләләре һәрьяклап тикшерелә. 1927 елдан исә оешмаларга татарларны күбрәк җәлеп итү иң әһәмиятле мәсьәләгә әверелә. Моның өчен барлык дәүләт оешмаларының хезмәт урыннары исемлеге төзелеп, шул урыннарның кайсыларын ике дәүләт телен дә белүче хезмәткәрләр белән алмаштырырга кирәклеге билгеләнә. 1927 елдан соң татар телен гамәлгә кую процессы шактый сүлпәнләнә һәм ул 1930 елда тәмамланган дип әйтергә мөмкин булыр иде, чөнки шуннан соң Үзәк комиссиянең хисап һәм докладлары бирелми, хөкүмәтнең бер генә съезд яки сессиясендә дә татар телен гамәлгә кую эше аерым алып тикшерелми. Ләкин, документлар буенча, Үзәк комиссия 1932 елга кадәр эшли, ә архивларда саклаганган соңгы чыганак 1936 ел белән билгеләнә [Кириллова, 2000, б. 37]. Шунлыктан татар телен гамәлгә кую процессы, бик акрынлык белән булса да, 1936 елга кадәр дәвам иткән дигән фикергә килергә мөмкин.

ТАССР шартларында татар телен гамәлгә куюның төп бурычлары итеп түбәндәгеләр билгеләнә: 1) барлык дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында татар һәм рус телләренең юридик һәм гамәли тигез хокуклылыгын булдыру; 2) күбрәк татар халкына хезмәт күрсәтүче оешма һәм предприятиеләрдә татар телендә эш башкаруның актив формасын кертү, шул ук вакытта рус телендә пассив эш алып баруны

да саклау; 3) күбрәк рус халкына хезмәт күрсәтүче учреждениеләрдә татар телендә пассив эш алып бару; 4) милли азчылыкка (чуваш, мари, мордва һ.б.) телдән аралашуны ана телләрендә башкарып, язу эшләрен ике дәүләт теленең берсендә алып бару мөмкинлеге бирү; 5) ана телендә эш башкаруны, беренче чиратта, авыл советларында, волость башкарма комитетларында, фабрика-завод комитетларында, җирле оешмаларда, беренчел кооперативларда, суд һәм тикшерү алып бару участокларында, милициядә һәм башка оешмаларда урнаштыру, шуннан соң гына югарырак органнарны тәэмин итү. ТАССРның 10 еллыгына, ягъни 1930 елга, татар теле тулысынча гамәлгә куелып бетәргә тиеш дип санала [За 5 лет..., с. 39–40].

Ләкин бу чараларны тормышка ашыру үз чиратында башка бурычларны үтәү белән тыгыз бәйләнгән була: 1) аппаратка татар хезмәткәрләрен күпләп җәлеп итү; 2) яңаларын төрле белгечлекләр буенча кыска сроклы курсларга, уку йортларына татарларны күпләп кабул итү юлы белән әзерләү; 3) рус хезмәткәрләренә һәм югары уку йортларында укучы русларга татар телен өйрәтү; 4) волость, район һәм аерым ведомстволар линиясе буенча участокларның чикләрен мөмкин булганча теге яки бу телнең территориаль таралышы чикләре белән туры китерү; 5) барлык мәдәни-икътисади пунктларны (мәктәп, китапханә, хастаханә, агроном һәм ветеринар пунктлары, элемтә оешмалары, кооператив берләшмәләр һ.б.) татар массаларына якынлаштыру; 6) татар телен техник яктан дәүләт теленә яраклы итү (терминология һәм эш башкару формаларын эшләп чыгару, нәшер итү эше, язу машиналарын хәзерләү һ.б.) һәм 7) татар пролетариаты үсеше өчен шартлар тудыру [За 5 лет..., с. 40].

Квалификациясез эшчеләр мәсьәләсен хәл итү, ягъни аларга төрле белгечлекләр буенча белем бирү максатында, Үзәк комиссия карамагында 1922 елның июлендә Татар телен гамәлгә кую үзәк курслары төзелә. Бу курсларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә, унбишкә якын белгечлек буенча татар хезмәткәрләре әзерләнә.

Шулай ук русларны да татар теленә өйрәтү һәм моның белән ике дәүләт телен дә белүче хезмәткәрләр әзерләү максатында, 1921 елдан башлап төрле үзәк оешмаларда, комиссариатларда һәм кантоннарда русларга татар теле өйрәтү буенча курс-түгәрәкләр эшли башлый. Бу түгәрәкләр үз чоры өчен гаять әһәмиятле эш башкаралар.

1920–1930 елларда Мәгариф комиссариаты карамагында булган төрле типтагы уку йортларында татар телен укыту һәм моңа татарларны күбрәк җәлеп итү буенча зур эш башкарыла. Бу елларда мәктәпләр иң элек ике төргә бүленә: I баскыч һәм II баскыч мәктәпләр. I баскыч мәктәпләрдә уку вакыты 4 елга сузыла, шул ук вакытта ТАССР өчен 3 еллык мәктәпләрнең күпчелекне тәшкил итүе хас була [Татарстан Республикасы Милли архивы (алга таба – ТР МА), 3682 ф., 1 тасв., 997 эш, б. 770]. Моннан тыш, мәсәлән, 1925 елда татар авылларындагы барлык I баскыч мәктәпләрнең яртысын бер комплектлы, ягъни бер генә еллык мәктәпләр алып торуы мәгълүм [За 5 лет..., с. 105].

I баскыч мәктәпләр күтәренке тип мәктәпләрне тәшкил иткән һәм чагыштырмача яңа күренеш саналган II баскыч мәктәпләргә караганда күбрәк була. II баскыч мәктәпләр үзләре ике төргә аерыла: 7 еллык һәм 9 еллык. II баскыч мәктәпләр арасында 7 еллыклары зуррак урынны алып тора, бу төр мәктәпләр бигрәк тә кантоннарда күп төзелә, ә 9 еллык мәктәпләр исә шәһәрләр һәм аеруча Казан өчен хас була [За 5 лет ..., с. 105).

Дәүләт уку йортларыннан тыш, ТАССРда ата-аналар һәм крестьян җәмгыятьләре акчасына эшли торган мәктәпләр дә була. Мәсәлән, 1925 елда аларның саны 200 дип күрсәтелә [За 5 лет..., с. 105].

Гадәттә 1920 еллардагы хисапларда революциягә кадәр 35 кенә татар мәктәбе булган дигән фикер үткәрелә [За 5 лет..., с. 103; ТР МА, 732 ф., 1 тасв., 766 эш, 52; Доклад, б. 4], ләкин әлеге мәгълүмат дөреслеккә туры килми, бу күренеш, беренчедән, тарихта татар мәдрәсәләренең исәбе алынмау һәм аларны мәктәпкә санамау, икенчедән, 1917 елга кадәр булганнарны фәкать тискәре яктан гына сурәтләргә омтылу нигезендә барлыкка килә. Мәсәлән, 1922 елгы Татнаркомпрос докладында «Совет хакимияте вакытында да мәгариф аппараты һәм аның җитәкчеләре татарларга караганда русларны мәгърифәтле итүгә күбрәк әһәмият бирәләр», – дип ачыктан-ачык күрсәтелә [ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 288 а эш, б. 103]. Дөрес, совет хөкүмәтенең ярдәмен, яклавын сизгән татарлар, башка халыклар кебек үк, революциядән соң зур күтәренкелек белән мәктәпләр ачу эшенә керешә, бу хәл 1921 елга кадәр гаять зур көч белән, ләкин стихияле рәвештә дәвам итә. Мәсәлән, ТАССРда 1920 елга I баскыч мәктәпләрнең гомуми саны хәтта 2996 ны, ә дәүләт хисабындагы татар мәктәпләренең саны шуларның яртысын диярлек – 1215 не тәшкил итә. II баскыч мәктәпләрнең гомуми саны 125 булып, шуларның 26 сын татар мәктәпләре алып тора. Олылар өчен мәктәпләр: русларныкы – 50, татарларныкы – 27 [ТР МА, 732 ф., 1 тасв., 120 эш, б. 197].

1921 ел мәктәпләр өчен дә авыр сынау елы була, алар, ничек барлыкка килгән булсалар, шундый ук тизлек белән ябыла да башлыйлар. Мәсәлән, 1922 елга Татарстандагы барлык I баскыч мәктәпләр 2996дан 1741 гә, ә II баскыч мәктәпләр 125 тән 63 кә кала [ТР МА, 732 ф., 1 тасв., 120 эш, б. 198]. Бу кимү 1924 елга кадәр дәвам итә, чөнки бюджетның коточкыч ярлылыгы, укытучыларның җитешмәве, булганнарына да хезмәт хакы түли алмау, дәреслекләрнең, кулланмаларның булмавы – болар барысы да күпсанлы мәктәпләр тотуның реаль чынбарлыкка туры килмәвен дәлилли. Татар үзәк башкарма комитетының 2 нче сессиясендә ясаган чыгышында Мәгариф халык комиссары Солтанов мәгариф хезмәткәрләренең коточкыч авыр хәлен тасвирлый. Аның тарафыннан әйтелгән бер җөмлә генә дә күп нәрсәне аңларга ярдәм итәр: «Мы работали в такое время, когда работать было нельзя» [ТР МА, 732 ф., 1 тасв., 8 эш, б. 91]. Авыр хәлгә түзә алмыйча, күп укытучылар акча күбрәк түләнә торган эшкә күчәргә

мәҗбүр булалар [ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 501 эш, б. 9]. Чагыштыру өчен мисал: укытучылар 1922 елда гражданнар сугышына кадәр алган хезмәт хакының уннан бер өлешен генә алганнар [ТР МА, 732 ф., 1 тасв., 200 эш, б. 327]. Шулай да, хисаплардан күренгәнчә, укытучыларның хезмәтенә түләү елдан-ел аз булса да арта барган.

1920 еллар укытучылары эшләре азлыктан һич тә зарлана алмыйлар. Бигрәк тә авылларда бер мәктәптә гадәттә бер укытучы гына эшли. Ул елларда бер укытучыга иң кимендә – 40 укучы, ә күпчелек очракта хәтта 70 укучы туры килә [За 5 лет..., с. 105]. Мондый хәл, билгеле, укытуның нәтиҗәлелеген бик нык киметә, укытучыга бөтен булган белемен эшкә җигәргә мөмкинлек бирми. Ул көненә 10 ар сәгать эшләргә мәҗбүр була [ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 628 эш, б. 82]. Җитмәсә, бу вакыттагы мәктәп биналарын да хәзерге берничә катлы, бөтен уңайлыклары булган мәктәпләр белән һич тә чагыштырып булмый. Бигрәк тә татар мәктәпләре бик кечкенә йортларда, хәтта мунчаларда урнаша [Третья сессия..., с. 38]. 1925 елның февраль-март айларында 17 инспектор катнашында барлык мәктәпләрне тикшереп чыгу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, татарлар һәм милли азчылыкның мәктәпләр белән тәэмин ителеше бары 10% кына тәшкил итә [ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 628 эш, б. 83]. Тәтеш кантоны буенча бирелгән мәгълүматларда хәтта мәйданы бишкә биш аршынлы, ягъни 12,64 кв. метрлы, ә биеклеге бары ике аршынлы (1,42 м) мәктәпләрнең очравы күрсәтелә [ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 628 эш, б. 85]. Башка кантоннарда да татар мәктәпләренең гаять начар хәлдә булуы ассызыклана.

Татарстандагы I баскыч татар мәктәпләрендә укыту татарча алып барыла, һәм балаларны үз ана телләрендә укыту өчен кирәкле дәреслекләр, уку кирәк-яраклары, мәктәп биналарыннан башка проблемалар булырга тиеш түгел кебек. Ләкин шул вакытта ук безнең өчен бик тә таныш булган мәсьәлә бөтен авырлыгы белән көн үзәгенә килеп баса: II баскыч мәктәпләрдә, профессиональ-техник уку йортларында укыту рус телендә алып барыла, вузларга кергәндә, русча белергә кирәк – нәтиҗәдә, татар балалары белем алуны дәвам итә алмыйлар. Бу авыр хәлдән чыгу юллары хакында мәгариф эшчеләре, укучылар арасында һәм, гомумән, матбугатта фикер алышулар һәм бәхәсләр дә булып ала. Бигрәк тә «Мәгариф» журналы 1924–1925 елларда әлеге бәхәсләрнең үзәгендә тора. Фикерләр нигездә икегә аерыла. Беренче фикер буенча, Татар республикасының I баскыч мәктәпләрендә, татар теленнән тыш, икенче сыйныфтан ук рус теле бик нык укытылырга тиеш. II баскыч мәктәпләрнең беренче сыйныфыннан укыту рус телендә алып барылып, татар теленең исә фән булып кына калуы тәкъдим ителә [Мәгариф, 1925, № 9, б. 3]. Шулай итеп, беренче фикер нигезендә, нәтиҗәдә рус теле генә чын дәүләт теле хокукына ия булып кала.

Бәхәстә катнашучы икенче якның фикере тормышка ашкан булса, бәлки, күп дистә еллар буе татар теле бары урам теле генә булып

калу язмышына дучар булмас иде. Татар телен чын дәүләт теле итеп күрергә теләүчеләр арасында мәсьәләгә артык җиңел караучылар да була. Алар уйлавынча, шәһәрләрдә һәм авылларда бик яхшы эшләүче татар мәктәпләре бар һәм алар үсәләр. Бөтен татар мәктәпләрен бик яхшы итеп кую өчен, мәктәп биналары, яхшы укытучылар хәзерләргә кирәк. «Һәм бер вакыт килер: берәү русча биш югары мәктәп бетерсә дә, әгәр татарча яхшы хәзерләнгән булмаса, татар дигән паспорты белән аны бер җиргә дә эшкә алмаслар, һәм ул кеше файдалы да булмас. Мәсьәлә шуңа таба бара бит», диләр [Мәгариф, 1925, № 9, б. 4]. Мәсьәләгә мондый артык җиңел карауны тәнкыйтьләп, Ш. Әхмәдиев «татар теле Татарстанның барлык I һәм II баскыч мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында булырга тиеш» дип билгели, «әгәр бөтен уку йортлары, ашыгып, кирәк булган гыйльми көчләрне чыгара-хәзерли алмасалар, Татарстан хөкүмәтендә татар телен гамәлгә кую планы аксарга мөмкин» [Әхмәдиев, б. 3–8], – дип чаң суга. Г. Максуд та үзенең мәкаләсендә татар теленә рус алынмаларын кертү белән генә канәгатьләнмичә, мәктәпләрне дә I баскычтан ук русчалаштыру, гомумән, мәгарифкә рус теле аркылы бару кирәклеген алга сөргән рус агымына бик нык каршы чыгып, «Татарстан җөмһүриятенең андый юл белән барганы юк һәм моннан соң да барачак түгел!» [Максуд, б. 338] дип ассызыклый. Ләкин, кызганыч, тарихтан билгеле булганча, 1930 елларда рус агымы бу яктан да җиңеп чыга.

1921 елның 25 июнендәге татар телен гамәлгә кую буенча беренче декретта «барлык II баскыч мәктәпләрдә теләгәннәр өчен татар телен кертергә» дигән кечкенә генә пункт та урын ала [Сборник..., с. 6]. Ләкин татар телен өйрәнергә атлыгып торучылар булмаганын күреп, хөкүмәт башка юлга күчәргә мәҗбүр була. 1922 елның 8 маендагы Татарстан үзәк башкарма комитеты карарында Мәгариф комиссариатына 1922/1923 уку елыннан башлап, Татарстанның барлык урта, югары һәм профессиональ-техник уку йортларына татар теле укытуны кертергә тәкъдим ителә [Сборник..., с. 9]. Ә 1922 елның 21 декабрендәге инструкциядә инде, алдагы карарны кабатлап һәм тагын да тирәнәйтеп, барлык II баскыч, профессиональ-техник уку йортларында, партия мәктәпләрендә, эшче факультетларында һәм вузларда, ә шәһәрләрдә шулай ук I баскыч мәктәпләрнең соңгы сыйныфларында да барлык укучылар өчен татар телен өйрәнү мәҗбүри итеп куела [Сборник..., с. 13].

Әлеге карарларның, кабул ителеп кенә калмыйча, үтәлә дә башлаулары күп чыганакларда раслана [ТР МА, 732 ф., 1 тасв., 154 эш, 15–17; Известия ТЦИКа, 1923, № 131; Доклад..., б. 38]. Мәсәлән, 1922/1923 уку елында барлык кантоннарда да диярлек II баскыч мәктәпләрнең уку планына татар теленең махсус предмет итеп кертелүе һәм, татарлар белән бергә, аны рус һәм башка милләт балаларының да өйрәнүе билгеләнә [ТР МА, 732 ф., 1 тасв., 154 эш, 16]. 1927 елгы мәгълүматларда да татар теленең карарда саналган мәктәпләрнең

төрле уку елларында бер-бер артлы кертелеп баруы, якын елларда күрсәтелгән уку йортларының һәр сыйныфында урын алачагына ышаныч белдерелә [II баскыч..., б. 3].

Уку йортларында татар теле рәсми рәвештә укытылса да, эшнең нәтиҗәләре гаять начар була. «Татар телен уку йортларында дәрес итеп укытуда тәҗрибәләрнең юк дәрәҗәсендә аз булуы, укытучыларның хәзерлекләре җитмәү, белгечлекләре ягыннан чуар булулары» [II баскыч..., б. 3], дәреслекләр, программалар булмау кебек һаман шул бер үк проблемалар күрсәтелә. Бигрәк тә рус балаларына татар теле укыту эше авыр бара. Хәтта 1929 ел ахыры – 1930 ел башында комиссия тарафыннан үткәрелгән тикшерүләрдә татар булмаганнарга татар теле өйрәтүнең һаман башлангыч этаптан уза алмавы билгеләнә. I баскыч мәктәпләргә татар теле бары 1930/1931 уку елыннан гына кертелергә уйлана [Харисов, б. 30]. II баскыч мәктәпләрдә татар теле 1922/1923 уку елыннан ук укытыла башласа да, рус мәктәпләре өчен татар теле программасы бары 1927 елда гына басылып чыга [II баскыч...].

Мәктәпләрдә татар теле гадәттә иң соңгы дәрес булып куела, моңардан исә дәресләрнең сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге дә кими, укучыларның кызыксынучанлыгы да азая [Харисов, с. 30–31]. Рус балаларына татар теленең ни өчен укытылуы хакында аңлату эшләре дә начар алып барыла. Мәсәлән, Татарстан үзәк башкарма комитетының 3 нче сессиясендә ясаган чыгышында М. Борындыков (Үзәк мөселман хәрби коллегиясе җитәкчесе, Мәгариф халык комиссары булып эшли, 1930 елда репрессияләнә. – *З.К.*) китергән мисал: «II баскыч мәктәптә укучы бер җиткән кыздан татар телен ни өчен өйрәнүләрен сорагач, ул, бераз икеләнеп торганнан соң: «Татарлар арасында яшибез; берәр кантонга барып, татар йортына туктарсың, синең тирәңдә ни сөйләшкәннәрен белергә кирәк бит, бәлки: «Бу кешене суярга кирәк!» – дип сөйләшәләрдер», – дип җавап биргән» [Доклад..., б. 25].

Рус мәктәпләрендә генә түгел, Татарстандагы милли азчылык мәктәпләрендә дә татар теле укытыла башлый. 1923 елның 19 мартында Мәгариф комиссариатының Милли азчылык бүлеге коллегиясе утырышында татар теле өйрәтүне I баскыч мәктәпләрнең өченче уку елыннан башлап, ике ел дәвамында укыту, моңа атнасына 2–4 сәгать вакыт бирү, ә II баскыч мәктәпләрдә исә татар телен гамәлгә кертүне башка мәктәпләрдәге кебек үк уздыру хакында карар кабул ителә. Татар телен укыту ике юнәлештә: җанлы сөйләм теленә һәм татар язуына өйрәтү рәвешендә алып барылырга тиеш була. Шулай ук халык арасында бу карарны татарлаштыру дип аңлап, каршы чыгу очраклары да булу мөмкинлеге искәртелә, сак булырга чакырыла [ТР МА, 3682 ф., 1 тасв., 410 эш, б. 35].

1920 еллардагы программа, уку планнары һәм дәреслекләрнең күпчелеге комплекслылык системасына, табигый (натураль) һәм тәрҗемә-грамматика методларына нигезләнеп төзелә. 1932 елгы про-

граммада исә конкрет методлар күрсәтелми, идеологиягә гаять зур урын бирелә. 1920–1930 елларда М. Корбангалиевның үзе генә яки Р. Газиз, Х. Бәдигый, З. Бәдигуллин белән берлектә руслар өчен чыгарган татар теле дәреслекләре зур уңыш казана.

1920 елларда татар телен чит тел буларак укытуның яңа эш булуы сәбәпле, бер үк дәреслекләр башлангыч сыйныфларда, урта мәктәптә, хәтта югары уку йортларында һәм зурлар өчен оештырылган курсларда кулланылалар, нәтиҗәдә аларның яшь үзенчәлекләрен, татар телен белү дәрәҗәләрен исәпкә алып эшләү өчен авырлыклар туа. Бары 1930 елларда гына татар телен системалы рәвештә укытуга юнәлдерелгән дәреслекләр языла килә, әмма алар өчен яңа идеология һәм сәясәткә кагылышлы текстларның гаять зур урын алып торуы хас.

Йомгак ясап әйткәндә, ТАССР төзелгәннән соң, татар теле беренче тапкыр рәсми рәвештә рус теле белән тигез дәрәҗәдәге дәүләт теле итеп игълан ителә һәм аны иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә гамәлгә кертү буенча киң эш җәелеп китә.

**Әдәбият**

*Әхмәдиев Ш.* Татарстанда тел мәсьәләсе // Мәгариф. 1925. № 9. Б. 3–8.

*Беликов В.И., Крысин Л.П.* Социолингвистика. М.: РГГУ, 2001. 440 с.

За 5 лет. К 5-й годовщине провозглашения ТССР. Казань: Изд. ТЦИК, 1925. 208 с.

Доклад Центральной Комиссии по реализации татарского языка при ЦИК Тат. АССР «О положении дела по РТЯ и перспективах» на 3-ей Сессии ЦИКа Татарской АССР 12–13 марта 1927 г. (Стенограмма). Прения и постановление по докладу. Казань: Изд. ЦК РТЯ при ТЦИК-е, 1927. 68 с.

II баскыч (9 еллык) рус мәктәпләре, шулай ук, вакытлыча, югары мәктәпләр өчен татар теле программасы. Наркомпрос басмасы, 1927. 33 б.

*Кириллова З.Н., Калганова Г.Ф.* Применение татарского языка в вузах Татарстана 1920–1930-х гг. // Вестник Челябинского государственного университета. Филологические науки. 2019. № 6 (428). Вып. 117. С. 71–76.

*Кириллова З.Н.* Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20–30 нчы еллар). Казан: Мастер Лайн, 2000. 208 б.

*Кириллова З.Н.* Татарстанда латин алфавитына күчү мәсьәләсе (1920 нче еллар) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2019. № 2. Б. 75–84.

КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. Т. 2. (1917–1922). М.: Политиздат, 1983. 606 с.; Т. 3. (1922–1925). М.: Политиздат, 1984. 494 с.

*Максуд Г.* Тел турында (Гыйльми мәркәзнең тел турындагы карарларына сүз башы һәм изах урынына) // Мәгариф. 1924. № 5. Б. 330–338.

Сборник Декретов, Постановлений, важнейших Циркуляров и других материалов в области реализации татарского языка. Казань: Изд. Центр. комиссии по реализации татарского языка при ЦИК ТАССР, 1925. 88 с.

Советская политика за 10 лет по национальному вопросу в РСФСР. Систематический сборник действующих актов правительств Союза ССР и РСФСР по делам национальностей РСФСР (октябрь 1917 г. – ноябрь 1927 г.). М.: Госиздат, 1928. 499 с.

Третья сессия ЦИК 5-го созыва (с 3-го по 5-е дек. 1925 г.). Стенографический отчет. Казань: Изд. ЦИК ТССР, 1926. 159 с.

*Ханазаров К.Х.* Решение национально-языковой проблемы в СССР. М.: Политиздат, 1982. 224 с.

*Харисов Ф.Ф.* «Учредить единожды навсегда...». Социально-исторические условия обучения татарскому языку русских и других народов: Учеб. пособие. Казань: Таң-Заря, 1995. 57 с.

***Кириллова Зоя Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең*
*гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты*

УДК 35.082.23

***Ш.Н. Асылгәрәев,***
***Г.Ф. Гайнуллина***

# ТАССР ОЕШУНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ БЕЛЕМЕНЕҢ ТОРЫШЫ

В статье представлен обзор тенденций развития татарской лингвистической науки в период становления Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К обзору привлечены лингвистические взгляды видных татарских языковедов, как Г. Ибрагимов, Дж. Валиди, Г. Алпаров, деятельность которых сыграла определяющую роль в дальнейшей истории развития татарского языкознания. Так же акцентируется роль Академического центра в институализации татарской лингвистики как науки.

**Ключевые слова:** татарское языкознание, татарский язык, литературный язык, Академический центр, письменность, реформа графики и орфографии, грамматика.

The article presents an overview of trends in the development of Tatar linguistic science during the formation of the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic. Linguistic views of prominent Tatar linguists, such as G. Ibragimov, J. Validi, G. Alparov, whose activities played a decisive role in the further history of the development of Tatar linguistics, are involved in the review. The role of the Academic Center in the institutionalization of Tatar linguistics as a science is also emphasized.

**Keywords:** Tatar Linguistic, Tatar Language, Literature Language, Academic Center, Orthjgraphy, Reform of Graphics and Orphography, Grammar.

1920 елның 27 маенда, моннан нәкъ йөз ел элек, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советы М.И. Калинин, В.И. Ленин һәм А.С. Енукидзе тарафыннан имзаланган «Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасы төзелү турында» декрет кабул итә. 1920 елның 25 июнендә Татарстан җөмһүриятендә идарә эшләре тантаналы рәвештә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Вакытлы революцион комитетына тапшырыла. Яңа төзелгән республиканың беренче җитәкчесе итеп РКП(б) ҮК Политбюросы Сәхибгәрәй Сәидгалиевне раслый. Нәкъ шушы көн тарихта республикага нигез салынган көн дип билгеләнә. Автономияле республика статусы алу белән, фән-мәгариф, мәдәният өлкәсендә яңа чор башлана: вакытлы матбугат, китап бастыру җайга салына; татар сәнгате һәм музыкасы үсеш ала, Дәүләт театры ачыла; төрле фән юнәлешләре алга китә.

ТАССР оешуның башлангыч чорында республика Советлар Союзының иң зур фән үзәкләренең берсенә әверелә: астрономия, химия, физика, математика, механика, машина төзелеше, медицина [Бу турыда: http://100tatarstan.ru/structure/profile/1920-1930-nchy-ellarda-tassrda-mdniyat-m-fn] фәннәре үсеш кичерә. XIX йөздән И. Хәлфин,

Г. Фәезханов, К. Насыйриларның фәнни нигезле, фундаменталь хезмәтләре белән килгән татар теле белеме дә 20 нче еллар башында яңа үсеш чорына аяк баса. Төрле юнәлештәге фәнни-тикшеренү үзәкләре, җәмгыятьләр барлыкка килә. Шундый үзәкләрнең берсе – 1921 елның 3 декабрендә Мәгариф халык комиссариаты каршында оештырылган Гыйльми үзәк (Академүзәк). Ул «төбәктәге барлык фәнни, фәнни-оештыру һәм мәдәни-оештыру эшен үз җаваплылыгына ала. Аның эшчәнлегендә методик (уку-укыту планнары һәм программалары эшләү, методик мәсьәләләр хәл итү), укыту (укытучылар әзерләү һәм аларның белемен күтәрү), тел белеме (татар телендә фәнни терминология булдыру, сүзлекләр төзү, тәрҗемәчеләр әзерләү), сәнгать (татар театрларының репертуарын контрольдә тоту һәм баету, татар музыкасын үстерү һәм популярлаштыру, музейлар, китапханәләр, түгәрәкләр эшчәнлеген актилаштыру, китап палатасы оештыру), фән (төбәк тарихын, монда яшәгән төрле милләтләр мәдәниятен, төбәкнең табигатен, иҗтимагый, икътисади үсешен өйрәнү, археология, тарих, этнография, филология кебек фәннәрне үстерү), борынгы һәйкәлләрне, мәдәни мирасны саклау һәм өйрәнү юнәлешләре аерылып чыга [Миңнуллин, 2017, б. 23]. Төрле елларда Гыйльми үзәкнең рәисе вазифаларын Г. Максудов, Г. Ибраһимов, Р. Таһиров, С. Атнагуловлар башкара. Үзәкнең чәчәк аткан вакыты исә 1921–1924 елларга – татар мәдәниятен һәм әдәбиятын, фәнне, милли үзаңны үзгәртүгә зур өлеш керткән, эшчәнлеге бәһаләп бетергесез шәхес Г. Ибраһимов җитәкчелек иткән чорга туры килә. Галим, җәмәгать эшлеклесе, киңкырлы эшчәнлеге бүген дә игътибарга лаек галим Г. Ибраһимов бер үк вакытта Татар төбәкне өйрәнүчеләр бюросын да җитәкли, фәнни-гамәли конференцияләр оештыру эшләрен башлап йөри, терминология, лексикология, тел тарихы, грамматика, төрки телләр үсеше, хәреф һәм имля мәсьәләләрен тикшерә. «Иҗат эшчәнлеге барышында, әдәби әсәрләр, халык, әдәбият, мәдәният тарихына караган хезмәтләр язуы белән бергә, төрки-татар язма әдәби теленең имля-орфография, лексика-терминология, сарыф вә нәху, бәлягать-стилистика, тәрҗемә теориясе һ.б. тармакларын, автор үзе әйткәнчә, фәнни нәзарият-теория югарылыгына күтәрү дәрәҗәсендә яктыртып, күпсанлы мәкаләләрендә, дәреслекләрендә, гамәли-практик яктан эшкәртеп, киң даирә укучыларына тәкъдим итә» [Бәширова, 2017, б. 27].

1921 елда Татарстан Республикасы Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы тарафыннан татар телен Татарстан территориясендә рус теле белән беррәттән тигез хокукта йөртү (ул вакыттагыча әйткәндә, дәүләт теле итеп санау) [Хаков, 2003, б. 242] турында декрет кабул ителә. Конференция һәм җыелышларда телнең үсешен, фонетик, лексик, морфологик һәм синтаксик нормаларын эшкәртүгә багышлаган мәсьәләләр төп урын ала бара. Бу чорда Г. Ибраһимов белән беррәттән, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, Г. Шәрәф, Х. Бәдигый, М. Корбангалиев, Г. Нугайбәк кебек күренекле

тел галимнәренең тикшеренүләрен атарга кирәк. Нигездә, әдәбият галимнәре һәм язучылар булсалар да, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Ф. Сәйфи, Г. Толымбайларның да тел белеменә караган хезмәтләре игътибарга лаек.

Мәгълүм булганча, XX йөзнең икенче унъеллыгында имля, хәреф мәсьәләләре иң җитди мәсьәләләргә әверелә. Алфавит һәм имляның үзгәрешсез кала алмавын аңлаган галимнәр, журналистлар, әлифба һәм дәреслек авторлары бу өлкәдә зур эшчәнлек җәелдереп җибәрәләр. «Алар язуның төзек, хәрефләрнең сүздәге тавышларга тәңгәл булырга тиешлеген һәрвакыт искәртә килгәннәр. <...> XX гасыр башындагы язуыбызның нинди хәлдә булуын Һ. Максуди, Г. Шәрәф, М. Корбангалиев, Ә. Мостафа, Г. Нугайбәк, Г. Алпаров һәм башка зыялыларыбызның язмалары бик ачык күрсәтә» [Асылгәрәев, 2005, б. 19]. Татар теленең сузык авазлары санын билгеләү мәсьәләсендә татар зыялылары берничә төркемгә берләшә: бишчеләр, фәнни алтычылар, гамәли алтычылар, тугызчылар һәм унчылар. Бу агымнар арасында туган бәхәсләр (гарәп хәрефләренә нигезләнгән әлифбага сузык аваз хәрефләре өстәү; гарәп теленә генә хас булган, татар телендә кулланылмый торган тартык аваз хәрефләрен төшереп калдыру; татар имлясын камилләштерү) мөселман укытучыларының съездларында берничә тапкыр каралып, XX гасырның 20 нче елларында да дәвам иттерелә. 1920 елның 19 декабрендә Татарстан Халык Комиссарлары Советы Г. Ибраһимов җитәкчелегендә Гыйльми үзәк тарафыннан эшләнгән проект нигезендә Хәреф вә имля турында декрет кабул итә. Әлеге декрет татар сүзләрен язу өчен 6 сузык, 24 тартык – барысы 30 аваз хәрефен рәсмиләштерә. Бу алфавит татар халкының бердәм алфавиты буларак, яңалиф кабул ителгәнче – 1927 елның 3 июленә кадәр гамәлдә йөри.

Әлеге чорда үсеш алган өлкәләрнең берсе – терминология тармагы. Гыйльми үзәк составында оештырылган терминологик комиссия терминнар төзү һәм куллануның төп принципларын, методологиясен эшли. Әлеге принциплар нигезендә яңа терминнар төзү эше киң җәелдерелә. «1920 ел ахырына ул комиссия 15 мең яңа термин тәкъдим итә» [Татар лексикологиясе, т. 2, 2016, б. 184]. Бу эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак XX гасырның 20–30 нчы елларында күпсанлы сүзлекчәләр дөнья күрә (Сәяси лөгать / төз.: Г. Нигъмәти, М. Мөхәммәдов, С. Шәрәфетдинов, 1925; *Максутов Х.* Фәнни камус – русча, татарча һәм төркичә фәнни мәҗмугалар буенча тәгъриф кылынган фәнни, әдәби вә сәнәгый ихтиляхлар камусы, 1927; *Максутов Х.* Физика атамалары, 1927; *Максутов Х.* РСФСР кодексларында очрый торган атамалар лөгатьнамәсе, 1927; *Гали М.* Газета укучыларның кесә сүзлеге, 1928; *Гали М.* Русча-татарча атамалар сүзлеге: физика, математика, астрономия буенча, 1931; *Гали М.* Русча, латинча һәм татарча атамалар сүзлеге: кеше морфологиясе, анатомия, гистология, 1931; *Гали М.* Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары, 1931; *Валитов Г.* Химия атамалары, 1931 һ.б.)/ Бу сүзлек-

чәләрне тикшерү, бастыру эшләре Г. Ибраһимов һәм Г. Максуди тарафыннан оештырылган.

Гыйльми үзәк эшчәнлеге кысаларында әдәби телне камилләштерү, аны бердәм нормаларга салу мәсьәләләре дә алгы планга чыга. 1924 елда Г. Ибраһимов, татар әдәби теленең халыкның җанлы сөйләм теле нигезендә үсәргә тиешлеген ассызыклап, «Татар телен җиңеләйтү турында тезислар» дигән темага чыгыш ясый. Галим сөйләмдә татар теленең үз сүзләрен кулланырга, телнең эчке ресурсларының барлык мөмкинлекләрен файдаланырга, телебездә сүз булмаган очракта башка төрки телләргә мөрәҗәгать итәргә, телне мәгънәләре аңлашылмаган гарәп-фарсы сүзләре белән чуарламаска кирәк дигән принципларны нигез итеп алырга чакыра. Бу фикерләр, әлбәттә, хәзерге татар телен, аның сүз байлыгын һәм терминологиясен, кулланылышын өйрәнү, системага салу һәм үсеш юнәлешләрен билгеләү өчен нигез булып тора.

1926 елда Бакуда Беренче тюркология корылтае уза. Корылтайның көн тәртибендә телләр тарихы һәм үсеше мәсьәләсе дә карала. Г. Ибраһимов бу хактагы гомумтюркологик характердагы иң әһәмиятле фикерләрен «Төрек халыклары арасында әдәби-мәдәни федерация нигезләре» (1926) исемле мәкаләсендә яктырта. Галим фикеренчә, «...әдәби телләр <...> үскән саен якынлашуга баралар. Шуңа күрә имляда, аталмаларда, әдәби тел төзүдә бу телләр арасындагы гомуми булган уртак хасиятләр күз алдында тотылырга тиешледер» [Ибраһимов, 1987, б. 289]. Гомумән, тел белеменең татарларда чын мәгънәсендә фән булып формалашуында Г. Ибраһимовның роле искиткеч зур.

Татар тел белемендә кабатланмас эз калдырган галим, инде 1911–1912 елларда ук графикага нисбәтле идеяләрен «Хәреф вә имлямыз», «Татар әлифбасы» китапларында чагылдырган, Гыйльми үзәктә хезмәт куйган Гыйбадулла Алпаров та XX йөзнең 20 нче елларында төрки телләр, шул исәптән татар теле гыйлемен фәнни өйрәнүгә үзеннән зур өлеш кертә. Татар, үзбәк, казакъ, кыргыз, уйгыр, төрекмән телләрен яхшы белүче буларак, «бу телләрнең өзлексез баюын, камилләшә баруын күреп, халыкларны бай сүзлек хәзинәләреннән, телләрнең сүз ясау мөмкинлекләреннән, җанлы сөйләшү теленнән, җирле сөйләшләрдән тулы һәм нәтиҗәлерәк файдаланырга өнди, телгә игътибарлы булырга, тел үсешен тәртипкә салырга үгетли» [Асылгәрәев, 2008, б. 10]. 1926 елда Баку шәһәрендә үткән Беренче тюркологик съезд эшендә Г.Алпаров та катнаша. Съездга әзерлек уңае белән «Мәгариф» журналында, «Кызыл Татарстан» газетасында «Бездә хәреф мәсьәләсе» исемле мәкаләсен бастыра. Биредә ул хәреф сүзнең кайсы урынында килүенә карамастан, һәрвакыт бер генә шәкелдә язылa дигән идеясен үстерә.

Г. Алпаровны тел галиме буларак дөньяга таныткан хезмәт – «Шәкли нигездә татар грамматикасы» монографиясе. Аның беренче басмасы – 1926 елда, икенче басмасы 1927 елда дөнья күрә. Бу хезмәт шул чорда ук фәнни җәмәгатьчелектә зур кызыксыну, шул ук вакытта

бәхәсләр дә уята. «Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә» буларак язылган зур күләмле бу хезмәт татар теле фәне үсешенең яңа этабын башлап җибәрә [Асылгәрәев, 2008, б. 12]. Тәнкыйтьнең төп юнәлеше, әлеге грамматикада телнең тик тышкы, ягъни шәкли ягы гына алынып, эчке – мәгънә ягы читләтелгән диюдән гыйбарәт була. Ләкин «тел күренешләренең башта шәкли ягын, формаль якларын өйрәнү аңа соңыннан бу күренешләрнең мәгънәсенә тагын да тирәнрәк, тагын да тулырак төшенү өчен кирәк иде» [Асылгәрәев, 2008, б. 13]. Мәгълүм ки, нәкъ менә узган гасырның 20 нче елларында рус теле белемендә дә грамматикаларны шәкли нигездә төзү юнәлешендә эш башлана. Г. Алпаров үзенең «Шәкли нигездә татар грамматикасы» хезмәтен татар, башкорт, казакъ, кыргыз, төрекмән, үзбәк, уйгыр телләрен чагыштырып яза һәм ул гомуми тюркология күләмендә фәнни грамматика тудыруда иң уңышлы тәҗрибә була. И.Б. Бәширова бу турыда хаклы рәвештә болай ди: Г. Алпаровның «аерым фикерләре: мәсәлән, фонеманың мәгънә аерымлый торган аваз, авазның сөйләм берәмлеге булуы, тел берәмлекләрендә форма һәм мәгънә берлеге. Тел берәмлекләренең үзара ныклы берлек хасил итүе, «...төрле кисәкләрнең бер-берсенә бәйләнешләрен, бер-беренә тәэсирләрен бик нык күзәтергә, аларны да үзара бер-беренә бәйләп өйрәнергә кирәк булу» һ.б. хәзерге гомуми тел гыйлеме өчен актуаль булып яңгырый [Бәширова, 2008, б. 284].

XX йөз башында лингвистик тикшеренүләр үзәгендә кайнаган тагын бер галим – Җ. Вәлиди. «Җамал Вәлиди узган гасырның 20 нче елларында ук инде җәмәгатьчелек тарафыннан атаклы тел галиме, тәнкыйтьче-публицист, фәлсәфәче булып танылган. Моның дәресләге аның шул чор вакытлы матбугатында дөнья күргән күп санлы язмалары белән раслана» [Асылгәрәев, 2007, б. 164–165]. Укытучылык аның эшчәнлегенең беренче тармагы булса, икенчесе – фән. Фәнни хезмәтләренең бер өлеше аны үз заманының көчле әдәби тәнкыйтьчесе итеп танытса, икенче зур өлеше – лингвистикага караган тикшеренүләре белән ул укучы күз алдына тюрколог булып килеп баса. Галимнең 20 нче елга кадәрге эшчәнлеге, нигездә, татар грамматикасы мәсьәләләрен өйрәнү белән бәйле булса, аннан соңгы чорда ул лексикография мәсьәләләрен өйрәнә. Җ. Вәлидинең әдәби тел, аны гыйльми эшкәртү турындагы фикерләре «Татар телен эшләү мәсьәләсе», «Телебезнең үсү тарихыннан», «Төрек-татар телләренең язмышы», «Галимҗан Ибраһимовның тел мәйданындагы хезмәтләре» дигән теоретик хезмәтләрендә чагылыш таба.

20 нче елларда Җамал Вәлиди аңлатмалы сүзлек төзү эшен күтәреп ала. 1927 елда – «Татар теленең тулы сүзлеге»нең беренче томын һәм 1929 елда икенче томының беренче өлешен бастырып чыгара. «Татар теленең тулы сүзлеге»нә язган сүз башында галим шулай ук әдәби тел үсеше, формалашуы мәсьәләсенә дә тукталып үтә, чөнки ул сүзлекнең турыдан-туры әдәби тел культурасын үстерүгә юнәлтелгән фәнни-практик кулланма булуын тирәнтен аңлап эш итә.

Җ. Вәлидинең татар лексикографиясенә керткән яңалыгы – фигыльләрне нинди формада бирү мәсьәләсе. Аңа кадәр фигыльләр сүзлекләрдә *-мак* формасы белән бирелсә, Җ. Вәлиди моны кире кагып, *-у* формасын тәкъдим итә. Шуннан соң *-у* формасы традициягә кереп китә. Җ. Вәлидинең югарыда аталган хезмәтләре татар теленең сүзлек байлыгын – семантик үзенчәлекләрен өйрәнүдә алыштыргысыз чыганак ролен үтиләр.

XX гасырның икенче унъеллыгында фразеология тел гыйлеменең һәм стилистиканың мөстәкыйль һәм мөһим бер тармагы итеп карала һәм танылa башлый. Г. Алпаров тарафыннан төзелеп, 1926 елда басылып чыккан «Әлифба тәртибе, имля кагыйдәләре, атамалар мәсьәләсе. Халык әдәбиятын җыю турында инструкцияләр җыентыгы»ның «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма» бүлегендә фразеологик әйтелмәләр шактый урын алган. Шунысы да игътибарга лаек: Х. Бәдигыйнең 1912 елда дөнья күргән «Борынгылар әйткән сүзләр» җыентыгы 1919 елда янә нәшер ителә, анда да татар теленең бай паремиологик фонды урын ала.

Димәк, XX гасырның 20–30 нчы еллары татар халкы өчен каршылыклы һәм катлаулы дәвер булуга, хокуклары сизелерлек чикләнүгә карамастан, оешу елларында аның автономия статусы татар халкына фән өлкәсендә дәрәҗә күтәрү мөмкинлеген бирә. ТАССР оештырылгач, татар теле республиканың иҗтимагый тормышында активрак кулланыла башлый. Нәкъ менә бу чорда интеллектуаль милли катлау үсеп чыга һәм ныгый. Бу чор галимнәрнең эшчәнлеге татар телен фәнни югарылыкка күтәрү, аның методологик нигезләрен эшләү һәм камилләштерүгә юнәлтелгән. Әлеге киңкырлы эшчәнлек бүген дә әһәмиятен югалтмый, киресенчә, татар тел белеме фәне өлкәсендәге актуаль һәм бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә кыйммәтле чыганак булып тора.

**Әдәбият**

*Асылгәрәев Ш.Н.* Язуыбызны төзәтү өчен барган бәхәсләр (XX йөзнең беренче чиреге) // Фән һәм тел. 2005. Б. 19–25.

*Асылгәрәев Ш.Н.* Җамал Вәлиди – акыл иясе, энциклопедист галим (тууына 120 ел тулу уңае белән) // Тормыш баскычлары. 2007. Б. 163–175.

*Асылгәрәев Ш.Н.* Г. Алпаровның тормышы һәм гыйльми эшчәнлеге // Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 6–19.

*Бәширова И.Б.* Гыйбадулла Алпаров һәм гомуми тел гыйлеме // Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 282–286.

*Бәширова И.Б.* Төрки-татар әдәби тел нәзарияте: Галимҗан Ибраһимов иҗаты // Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Галимҗан Ибраһимов мирасы: Материалы международной конференции / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. 2017. С. 26–34.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. VIII т.

1920–1930 елларда Татарстанда мәдәният һәм фән // URL: http://100tatarstan.ru/structure/profile/1920-1930-nchy-ellarda-tassrda-mdniyat-m-fn (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.06.20).

*Миңнуллин К.М.* Татарларда фәнни-тикшеренү үзәкләре (институтлары) оештыру идеясе һәм Галимҗан Ибраһимов // Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Галимҗан Ибраһимов мирасы: Материалы международной конференции / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. 2017. С. 21–26.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘhСИ, 2016. Т. II. 392 б.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе (татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*2007–2012 елларда ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*

***Гайнуллина Гөлназ Фоат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.51:82-1/-9

*Д.Ф. Заһидуллина*

# 1920 ЕЛЛАР (1920–1934): ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Статья посвящена новым веяниям в национальном литературном процессе и литературоведении, появившимся сразу после образования Татарской республики. В ней прослеживаются изменения, произошедшие в 1920–1934 годы в татарской литературе, литературной науке (формирование истории татарской литературы; поиск нового концептуального фундамента для теории татарской литературы, трансформация поэтики).

**Ключевые слова:** татарская литература 1920-х годов, литературоведение, история литературы, теория литературы, поэтика.

The article is devoted to new trends in the national literary process and literary criticism that appeared immediately after the formation of the Tatar Republic. It traces the changes that occurred in 1920–1934 in Tatar literature, literary science (the formation of the history of Tatar literature; the search for a new conceptual foundation for the theory of Tatar literature, the transformation of poetics).

**Keywords:** Tatar literature of the 1920s, literary criticism, history of literature, theory of literature, poetics.

Татарстан Автономияле Республикасы төзелү тормышның һәр өлкәсендә тотрыклылыкка, тәртип урнашуга өмет уята. Чөнки 1917 елгы февраль һәм Октябрь инкыйлаблары, Гражданнар сугышы китереп чыгарган хаос һәм билгесезлек бер туктарга тиеш: халык шуңа ышана. Татар җәмгыятендә инкыйлабның милли мәдәният зур яңарыш кичергән, гасырлар буе җыелып килгән эчке көченә таянып сикереш ясаган, «алтын чор»ына кергән бер вакытта башлануы – XX йөз башы күтәрелешенең өзелүе кебек кабул ителә. Әмма бу сикерешне башлаган шәхесләр исән-сау: татар халкының интеллектуаль куәте нык. Күрәсең, шуңа да 1920 елларда татар әдәбияты, мәдәнияте, фәне юнәлешләрендә активлык күзәтелә, зур уңышларга ирешелә.

## Татар әдәбияты

Чорның тарихи вакыйгалары чолганышындагы татар сүз сәнгате 1920 елларда юллар чатында калган кебек тоела. «Дүртенче елга кергәндә» (1920) мәкаләсендә Г. Ибраһимов, моны конкретлаштырып, һәр татар зыялысының «буржуазный яки пролетарский» [Ибраһимов, б. 243] юл сайларга тиешлеге дип билгели.

Үзгәрешләр гаять каршылыклы була. 1921 елны татар теле дәүләт теле дип игълан ителә; мәгариф, вакытлы матбугат, китап бастыру җайга салына; Дәүләт театры ачыла. Рус мәдәнияте үрнәгендә, төрле әдәби күмәклекләр оеша башлый («Завод», 1923; «Часовой», «Октябрь», 1924; «Сулф», 1924; ТАПП, 1928; ТатЛОКАФ, 1931) һәм алар

яшь язучылар өчен осталык мәктәбе роленә дәгъва итә. Әмма ныгып китәргә өлгермиләр: татар язучыларының гомум бер оешмасын булдыру идеясе туа, аны бу чорда йогынтылы Г. Ибраһимов аеруча хуплый. 1927 елда «Татар әдәбияты җәмгыяте» төзелә, бераздан ул «Совет язучылары оешмасы» дип атала башлый. 1928 елның язында оештырылган ТАПП (Татар пролетариат язучылары ассоциациясе) рәсми идеологияне актив үткәрүчегә әверелә. Ассоциациянең татар бүлекләре Мәскәүдә, Уралда, Уфада, Себердә, Самарада да оештырыла.

Сыйнфый көрәш тәгълиматы инкыйлабка кадәр иҗат иткән классик әдипләр мирасына карата искелек чагылышы дигән тискәре мөнәсәбәт урнаштыра, язучыларны «пролетар», «крестьян», «буржуаз» төркемнәргә бүлүне китереп чыгара. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, Г. Исхакый, С. Рәмиев кебек классиклар иҗатын да татар әдәбияты тарихыннан алып ташлау өчен «Әдәби суд»лар уздыру, зыялыларны матбугатта, иҗтимагый аренада сүз белән кыйнау гамәлгә керә [Гайнетдинов, Рахимов].

Табигый югалтулар, әдәби активлыгы XX йөз башына туры килгән әдипләрнең бакыйлыкка күчүе (Дәрдемәнд (1921), Ф. Әмирхан (1926), С. Рәмиев (1926), Ш. Бабич (1926), М. Фәйзи (1928), Г. Камал (1933) һ.б.) дә татар әдәбиятының милли эчтәлекле романтик-символик юнәлештәге казанышларын әдәби барыштан ерагайта.

Татар әдәбиятына тискәре йогынты ясаган факторларның иң зурысы, мөгаен, 1927 елның 3 июль карары нигезендә латин алфавитын татар теленең рәсми алфавиты дип игълан итү була: ул гарәп графикасындагы мирасны юкка чыгаруны тизләтә, сүз сәнгатен традицияләрдән аера. Әкренләп милли әдәбиятларның рус мәдәниятенә йөз тотып үсәргә тиешлеге хакындагы фикер алга чыга.

Тарихи вакыйгалар татар әдәбиятын ике капма-каршы чиккә юнәлтә: XX йөз башы мәдәни күтәрелешенең үзәгендә кайнаган күп кенә өлкән язучылар аны традицион эстетик казанышларны саклап үстерү юлын сайлый, иҗтимагый-сәяси хакыйкатьне эзләп бәргәләнә; кайберәүләре, большевиклар юлын кире кагып, мөһаҗирлеккә китә. Инкыйлабны яклап чыкканнар яңа әдәбият тудыруны нигезли. Бу юнәлештә әдәбиятны идеологиянең бер тармагына әверелдерү тенденциясе [Галимуллин, б. 6] үсә бара, иҗат иреге чиктән тыш кысыла. Әйтик, 1921 елны Ф. Әмирхан болай дип яза: «Мин Николай цензурасының иң кара вакытында да, Керенский заманасында да газеталарда эшләгән кеше, ләкин мин һич вакытта матбугат хөрриятенең бу кадәр тапталганын, матбугат һәм фикер хөрриятенә бу кадәр богау салынганын үз өстемдә хис иткәнем юк иде» [Фатих Әмирхан…, б. 55]. Чыннан да, әдәбиятны сыйнфый ноктадан чыгып бәяләү сүз сәнгатендә герой концепциясенең, үзәк идеянең үзгәрешенә алып килә, XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләрдәге рухи башлангычка йөз тоту, милли эчтәлек кире кагыла башлый.

Мөһаҗирлектәге әдипләр иҗаты (Г. Исхакый, С. Гыйффәт, Ш. Келәүле (Илдәр), Х. Габдүш, М. Исмәгыйли, Х. Хәмидулла һ.б.) милли

яңгырашлы булуы, инкыйлабка кадәрге эстетик принципларны дәвам итүе, милләт яшәешенә һәм язмышына караган мөһим мәсьәләләрне яктыртуы белән аерылып тора. Г. Исхакыйның бу чор иҗаты татарларны милләт буларак саклап калу өчен төрки халыкларны бердәмлеккә чакыру идеясе белән сугарыла. «Дулкын эчендә» (1920) драмасы, «Өйгә таба» (1922), «Көз» (1923) повестьлары, «Локман Хәким» (1923) хикәясе, «Җан Баевич» (1923) комедиясе татар әдәбиятының классик хәзинәсенә керә.

Әмма илдә калган, романтик-символик, модернистик-экзистенциаль юнәлешне дәвам итүчеләр тарафыннан да әдәбиятның алтын фондына кергән әсәрләр иҗат ителә, шушы авыр заманда милләтне-халыкны сакларлык-яшәтерлек фикер-идеяләр әйтелә [Загидуллина, 2013]. Инкыйлаби үзгәрешләрне инкяр итү дә башкарыла. Дәрдемәнд аны шайтаный гамәл белән тиңли («Куанды ил...»). Бердәнбер кызларын күмеп кайткан ирнең хатынын юату монологы – «аң агышы» кебек язылган Ф. Әмирханның «Тәгъзия» (1922) нәсере яшәү һәм үлем, өметләр өзелү фәлсәфәсен чор контекстында укырга юл калдыра, нинди генә сынаулар килгәндә дә иманны югалтмау мөһимлеген ассызыклый. Якын кешесен юатып, ир үлемнең – котылгысызлык, табигатьнең бер кануны булуын үзәккә куя. Ул яшәешне ике өлешкә: тормыш-чынбарлыкка һәм танып-аңлап бетереп булмый торган теге дөньяга бүлә, шуның белән кешене иманлы яшәргә өйрәтә. Ф. Әмирхан шул рәвешле диннең кешелек дөньясындагы урыны, әһәмияте мәсьәләсен күтәрә. Хикәяләүче исеменнән әсәр ахырында: «Үлгәннәр өчен кайгы юк. Бары мәңге үлмәстәй булып алданып тора торган сукырлар, идеаллары шул чери, бетә, үзеннән вак хәшәрәтләр тудыра торган рәхәте, шулар тереклегенә багланып калган рухани мещаннар кызганычлар» [Әмирхан, 1984, б. 366] дигән сүзләр тарихи контекстта яңа хакимияттәге имансызлыкны бәяләү булып та аңлашыла.

Хис-фикер көчешен күзәтеп, тирән психологизм белән сугарылган Г. Рәхимнең «Идел» (1921) повесте дөньяны яшәткән ике омтылыш: мәхәббәт һәм ирек; ике хис: ярату һәм үкенеч хакында сөйли. Әсәрдә вакыйгалар 1914 елны бара, каты авырудан соң ялгызы гына табигать кочагына көч җыярга килгән Ильяс Рәбига исемле кызга гашыйк була. Ләкин аны күргәннән алып, яздан көзгә кадәр ара егетнең икеләнүләре кебек уза. Бер яктан, Рәбиганың күзләре, аның янәшәлеге егеткә чиксез бәхет, рәхәт биргән кебек тоела. Ләкин ул бу хисләрне «алтын богаулар» дип саный, әле богауларны өзеп ташлап, ирекле булырга омтыла.

Әсәргә пролог, хикәяләүгә этәргеч итеп бирелгән, күп еллар узганнан соң таныш күзләрне очрату, шул күзләр иясе белән бергә чакның иң кадерле, бәхетле вакыт кебек искә төшерү исә бу фәлсәфәнең дөреслеген шик астына куя һәм укучының үзгә нәтиҗә чыгаруын сорый. Эпилог шулай ук интонацион яктан төп тексттан аерылып тора. Яшьлеге узган кешенең моңсу, үкенечле монологы – югалган мәхәббәте белән дә, милләт ваемын беренче урынга куеп яшәгән гамьле

көннәрнең узуы белән дә бәйле. Чөнки хикәяләүче Иделгә мөрәҗәгать итә һәм әсәргә яңа мәгънә дулкыннары йөгертә. Мәхәббәт шаһите булган елга – милләт анасы булып гомумиләшә. «Менә ул безнең олуг анабыз, Идел, минем аяк астымда… Син безнең туган Иделебез, үз Иделебез идең ләбаса, ник үзеңнең балаларыңны ташладың? Ник безне әллә кемнәр синең шәфкатьле ярларыңнан сөрделәр?» [Рәхим, 2004, б. 279–280]. Мәхәббәтне җуйганга үкенеч милләт өчен үкенү-борчылу хисе белән кушыла. Сюжеттагы кыз-егет мәхәббәте белән янәшә милләткә мәхәббәт дигән хис калкулана. Шуннан соң ук милләт улларының хәленә бәя яңгырый: «Әнә аргы якта олуг Татарстан җәелеп ята. Шунда, тирес оясы төсле, искергән саламга күмелгән авылларда, кечкенә генә өйләрдә хисапсыз күп бәхетсез кешеләр гомер кичерәләр. Бәхетсез халыкның бәхетсез балалары! Аларны бернисез сугышларга илтеп тураталар. Алар, сарык көтүе төсле, ләм-мим димичә, кем өчендер шунда барып, төз җирне түмгәк итәләр. Бәхетсез халыкның бәхетсез балалары!»

Тагын бер сурәт тудырыла. Хикәяләүче халкын канаты сынган акчарлакка охшата. «Кемнәр генә синең көчле канатларыңны имгәтteләр икән соң?!» [Рәхим, 2004, б. 280] дип мөрәҗәгать итә. Һәм канатлары көчсез кошлар: «алга да бармыйлар, артка да китмиләр, нәкъ бер урында туктаган төсле канатларын селкүдә дәвам итәләр». Шул рәвешле, 1921 елдан торып язучы кабат милли теманы әдәбият мәйданына чыгара.

Ф. Әмирханның яңа системаның асылын, идеологик нигезсезлеген аңлап, совет хакимиятенә шарж итеп язылган «Шәфигулла агай» (1924) повесте большевиклар идеологиясенең кешеләрне уйсызгамьсез, гасырлар буе яшәп килгән традицияләрдән аерылган кол дәрәҗәсенә төшерүен раслый. Шәфигулланың аяныч язмышы аша советчыл тәртипләрнең татар халкына рухи-әхлакый характердагы зур югалтулар китерүенә ишарә ясый. Язучы әлеге фикерне халык көлүе формасында, ирония, сарказм алымнарына таянып калкуландыра. Интеллектуаль һәм мәдәни яктан чикләнгән Шәфигулланың, тормыш алып килгән, көн саен радиодан яңгырый торган идеологик чакырулар, яңача яшәү рәвешен мактаулар тәэсирендә, «советча» яши башлавы: 20 ел бергә яшәгән хатыны Сәрвине аерып, кабат советча гаилә коруы, яңа туган улына большевикларча итеп Володя исемен куштыруы, аны кызыл байракка төреп кешеләргә күрсәтүе, демонстрациядә салкын тидереп үлгәч – табут ясатып күмүе, көн саен балаларын «Интернационал» җырлатуы, Мәскәүгә «партийный хаҗ кылырга» китеп баруы һ.б. – укучы тарафыннан акылдан язу буларак кабул ителә. Яңа идеологиянең тышкы билгеләре халык аңында киләчәк матур тормыш хакында миф тудыруга юнәлтелгән булса, Ф. Әмирханның бу идеологик йогынтыны халыкны «акылдан яздыру» буларак бәяләве әлеге рәсми мифны җимерүгә хезмәт итә. Язучы заман алып килгән үзгәрешләрне иҗтимагый яктан да, милли аспектта да бәяләп уза. Әйтик, повестьны тәмамлап, «Кызыл

тел» газетасында басылган хәбәрдән китерелгән өзектә милли сөйләмнең юкка чыгуы бәян ителә: «Рабочий-крәстиянга тагын бер пример. Почти 60 яшенә достигать иткән татарин-рабочий Шәфигулла әле недавно гына партиягә расписаться иткән булса да, религиозный дурманнарны к черту җибәреп, полный сознательность проявить итте. Новорожденный ребенкасына Владимир куштырды...» [Әмирхан, 1991, б. 51]. Шул рәвешле, руслашу сәясәтенең көнитеш рәвешен һәм гореф-гадәтләрне генә түгел, гомумән миллилекне юк итүе билгеләнә.

Мондый әсәрләр татар язучыларының сизгерлеге, кыюлыгы, тарихи ташкын эчендә калган татар халкы язмышына битараф кала алмавы хакында сөйли. Халык тормышыннан алып (Г. Ибраһимов «Алмачуар», 1922), импрессионизм алымнарын тергезеп (Ф. Әмирхан «Беренче ашкыну», 1922), шигърияттә дини-фәлсәфи мотивларны калкуландырып (Ф. Борнаш, С. Сүнчәләй, Т. Ченәкәй, Г. Харис һ.б.) язылган әсәрләр дә традицион яңгырашлы булып, рәсми әдәбият белеме тарафыннан кире кагыла.

Гасыр башы татар әдәбиятында мәйдан яулаган символизм Һ. Такташның романтик шигъриятендә яңадан калкып чыга. Мондый әсәрләрдә мифларга мөрәҗәгать итү, мифологик символлар куллану активлаша (Һ. Такташ «Җир уллары трагедиясе» (1923); М. Җәлил «Кабил һәм Һабил» (1923), М. Гафури «Күк җырлары» (1923) һ.б.), алар еш кына яңа тәртипләргә бәя бирә. Яңа алымнар кулланучылар нигездә гыйсъянчылык фәлсәфәсенә таяна (Һ. Такташ «Гыйсъян», «Нәләт» (1923); К. Нәҗми «Ике ант» (1922) һ.б.), эчтәлек ягыннан тирән, төрлечә укыла алган, образлылык ягыннан катлаулы әсәрләр язылып, күпмедер күләмдә әдәби-фәлсәфи традицияләрне дәвам итә. Бер үк вакытта аларда чор идеологиясенә тәңгәл фикерләрне табу мөмкинлеге тудырыла. Әйтерсең лә әдәбиятта традицияләрне саклау мөһимлеген аңлаган яшь талантлар советчыл идеологиягә каршы килми торган «алтын урталыкны» эзли.

Икенче, «пролетарский» юл шигърияттә салына башлый: ул, инкыйлаби үзгәрешләрне хуплау белән бергә, көнитеш мәсьәләләренә якыная; көнкүрешне иҗадилаштыру омтылышы хезмәт темасын калкуландыра; шигырьләрнең формасы, стильләр ягыннан тәҗрибәләр уздырыла. Лирика һәм эпос синтезында иҗтимагый-әхлакый (Һ. Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) һ.б.) һәм тарихи-инкыйлаби (Х. Туфан «Ике чор арасында» (1927); «Бибиевләр» (1928); Һ. Такташ «Гасырлар һәм минутлар» (1924)) проблематика күтәрелә. Татар поэзиясендә берничә миф формалаша: бәхетле, якты киләчәк турындагы; Ленин, алдынгы эшче образларына бәйле; коммунистик җәмгыять төзү хакындагы мифлар. Чор әдәбиятын иңләп баручы идеологик мотивлар пәйда була: якты киләчәккә бару, изге көрәш юлында корбан булу, көрәш, ил бәхете өчен көрәшкә өндәү, туган илнең матурлыгы. Әлеге мотивлар ил, байрак (әләм), көрәшче, дошман кебек бер төркем яңа мифологик образларны мәйданга чыгара.

Матур киләчәккә бару, кан коюга, ил бәхете өчен көрәшкә өндәү, туган илнең матурлыгы мотивлары, сыйнфый көрәш идеясе революцион рухтагы романтик шигъриятнең үзәген тәшкил итә. М. Гафуриның «Кызыл байрак» (1917), «Изге юлда» (1918) шигырьләре, «Чәчәктән һәйкәл» (1919) поэмасы, С. Сүнчәләйнең «Ихтилал шигырьләре» (1918) җыентыгына тупланган шигырьләре, Ф. Кәримнең «Чайка башыңны», «Көтәм сине» шигырьләре һ.б. әсәрләрдә кешедәге героизм, корбанчылык сыйфатларын данлау, яңа тормыш хакына үзен корбан итүчеләргә соклану үзәктә тора.

Якты киләчәккә бару мотивы белән сугарылган шигырьләрдә үткән һәм бүгенгене капма-каршы куеп гәүдәләндерү хасил була, ил, әләм мифологик образлары уйнатыла. Үткәнне тоташ кире кагу аша яңаны раслау М. Җәлилнең «Үткән көннәрдән» (1924), «Әти үлгәч» (1924), «Ленин туды» (1924), «Безнең авыл», Ф. Кәримнең «Зәңгәр йолдыз», «Без – Җир балалары» кебек бик күп шигырьләрдә күзәтелә. Яшь буын шагыйрьләр Ш. Фидаи, И. Йосфый, В. Җәлал, Д. Гобәйдиләрнең кан коюны хуплаган ярымпублицистик шигырьләре дә идеологик мотивлар белән сугарыла.

Шигърияттә, эчтәлек үзгәреше белән бергә, форманы тамырдан яңарту мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Бу татар әдәбиятында имажинистик һәм футуристик алымнарның (Х. Туфан, Г. Кутуй, Һ. Такташ, К. Нәҗми, Сирин һ.б.) активлашуына китерә [Загидуллина, 2013, с. 130–184]. Х. Туфанның лирик герое – яңа тормышны төзүче, гыйсъянчыларның берсе («тартышчы»), киләчәккә илтәчәк техника-машиналарга дан җырлый, искелектән котылуның бердәнбер чарасы итеп аны юкка чыгаруны күрсәтә («Татарстанда» (1925) поэмасы). Г. Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» (1925) җыентыгындагы «футурист» лирик герой: «Безнең кояш – ВКП, – дип, / Коммунарлар язлыгында үләрмен», дип белдерә. Аларга килеп кушылган К. Нәҗми, үзен «символист-имажинист» дип, «канда юган ертык күңел» хисләрен яңгырата.

Газета һәм журналлар битләрендә яшь шагыйрьләрнең аларга ияреп язган әсәрләре күренә башлый. Әкренләп футуристик чакырулар әдәбият мәйданыннан китсә дә, имажинистик сурәт тудыру югалмый: ул татар шигъриятендә катлаулы образлылыкны үстерү чарасы булып яшәп кала.

Сыйфат үзгәрешләре прозаны да читләтеп үтми. Инкыйлабтан соңгы вазгыять әсәр героен иҗтимагый тормышта һәм көнкүрештә тасвирлауны, сыйнфый яссылыкта сурәтләүне таләп итә башлый. Әсәрләрнең үзәгенә, социалистик төзелеш мәнфәгатьләре ноктасыннан якын килеп, пролетариат сыйныфы җиңүен күрсәткән, күпләргә үрнәк булырлык сыйфатларны үзендә туплаган каһарман куела. Нәтиҗәдә, Октябрь революциясеннән соң нигезен эшче һәм ярлы крестьяннар тәшкил иткән коммунистлар җәмгыяте тууын һәм әлеге җәмгыятьнең яңа вәкиле сәхнәгә күтәрелүен сурәтләү башлана. Нәкъ менә шуңа бәйле төстә прозада көрәш романтикасы яңа

кеше концепциясе тууга китерә, авылда күмәкләштерү чоры башлану да прозага яңа геройлар алып килә. Мәсәлән, Ш. Усмановның «Ил кызы», «Краском мәхәббәте» (1923), «Митинг» (1928) кебек хикәяләренең үзәгенә яшәү бәхетен көрәштә, яңа җәмгыять төзүдә тапкан герой куела, бу әсәрләр сыйнфый көрәш идеясе белән сугарыла. Аларда, кагыйдә буларак, яңа тормыш кешеләре әхлакый яктан бәяләнә (А. Шамов «Рәүфә», «Днепр буенда»), иске тормыш кешеләре сатирик сурәтләү объектына әйләнә (Г. Газиз «Скрипкачы Хөсәен», «Әхмәт байның тәһарәте» (1922), «Фаҗигале төннәрдә» (1923) һ.б.). Үткән тормышның җимерелүен һәм яңа тормыш төзелү барышын, аның кешеләр аңында һәм язмышында драматик чагылышын күрсәтү (Г. Ибраһимов «Кызыл чәчәкләр» повесте (1922); «Тирән тамырлар» романы (1928)), төрки-татар тарихына мөрәҗәгать итеп, тарихи вакыйгаларның шәхес язмышына йогынтысын ачыклау (М. Галәү «Болганчык еллар» (1931); «Мөһаҗирләр» (1933); Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» (1924)) фонында халык өчен көрәшүчеләр, үз тормышларын корбан итүче геройлар тергезелә. Инкыйлабка кадәрге тормышка мөрәҗәгать итү (Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» (1923), М. Гафури «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1927)) аны хәзергегә каршы куеп, тоташ кара буяуларда сурәтләү төсен ала.

1921 елгы ачлык вакыйгалары татар әдәбиятында натуралистик буяуларның куеруына сәбәп була, үлем һәм кешелекне җуеп яшәп калу чигенә куелган кешене сурәтләү гомумән кеше фәлсәфәсен читләтеп узмый (Г. Ибраһимов «Адәмнәр» (1923) повесте, К. Нәҗми «Тукран даласы» (1923) хикәясе һ.б.).

Егерменче елларда драматургиядә ике: 1) тарихи-инкыйлаби (М. Галәү «Пугач явы» (1926), Г. Кутуй «Казан» (1927); 2) романтик (М. Фәйзи «Асыльяр» (1928), К. Тинчурин. «Ил» (1928) юнәлешләре формалаша. Чор вакыйгаларын сурәтләгән тарихи-революцион (Ш. Усманов «Канлы көннәрдә» (1919), гражданнар сугышы вакыйгаларын яктыртучы (Г. Ибраһимов «Яңа кешеләр» (1920)) драмалар иске тормыш белән яңа тормыш бәрелешен үзәккә куя, хәтта сыйнфый көрәшне ачыктан-ачык данлау (Ф. Сәйфи-Казанлы «Дошманнар» (1921) күзәтелә. Инкыйлабларның кеше язмышына тәэсирен күрсәтү (К. Тинчурин «Җилкәнсезләр» (1926), Н. Исәнбәт «Һиҗрәт»); инкыйлаб тудырган яңа геройның рухи дөньясын ачу (Һ. Такташ «Камил»), җәмгыятьтәге аерым кешеләрнең тарихи агымга каршы килгән әхлак сыйфатларыннан көлү (К. Тинчурин «Американ» (1923), «Хикмәтле доклад» (1928), Н. Исәнбәт «Портфель» (1928)) үзәктә тора. Романтик драмаларда мәхәббәт өчен көрәш сыйнфый тигезсезлек белән бәйләп аңлатыла башлый (М. Фәйзи. «Урал суы буенда» (1917), «Асылъяр» (1918) мелодрамалары, «Ак калфак» (1922) драмасы), эчтәлекне символ ярдәмендә тәкъдим итү яки баету (Ф. Борнаш «Хөсәен мирза», К. Тинчурин. «Зәңгәр шәл», «Ил», «Зар» (1923) һ.б.) XX йөз башы әдәбияты белән бәйләнешләр өзелмәгән икәнлекне күрсәтә.

Шулай итеп, татар әдәби барышында 1920 еллар – иҗади күтәренкелек дәвере, милли мәдәниятнең алтын фондына кергән әсәрләр иҗат ителү, традицияләрдән өзелмичә яңа тәҗрибәләр уздыру вакыты буларак бәяләнә ала. Кызганычка каршы, булган ныклы нигездә түгел, бәлки аны җимереп яңаны төзү шигаре мәдәни барышта югалтуларга китерә. Әдәбиятның үзендә барган процесслар: өлкән буын иҗатчыларның элекке традицияләрне җуймыйча дәвам итү омтылышы, тематик тармаклану һәм милләт проблематикасын кеше проблематикасы белән алмаштыру, өр-яңа әдәбият тудыру вакытында рус әдәбияты һәм идеологик ихтыяҗның гына түгел, татар әдәбиятының эчке закончалыкларын да игътибарга алу әдәбият турындагы фәнгә дә йогынты ясый.

### Фән: әдәбият белеме

1921 елның 3 декабрь карары белән ТССР Мәгариф Халык комиссариаты каршында иң югары фәнни оешма – Гыйльми Үзәк оештыру турында карар кабул ителә һәм татар әдәбияты тарихын, әдәбият белемен фәнни нигездә әзерләү эше, мәдәниятнең киләчәк үсеш юллары хакында бәхәсләр башланып китә (Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Г. Гали, Г. Нигъмәти һ.б.). 1925 елның 7 гыйнварында җитәкче булып Г. Ибраһимов килгәннән соң, Үзәк «Татарстанда мәдәният һәм фәннең барлык юнәлешләрендә тикшеренүләр башлап җибәрә» [Академический центр…, с. 10–11].

Гомумән алганда, Гыйльми Үзәк төбәктәге барлык мәдәни мәсьәләләрне, гуманитар фәннәрне үз канаты астына ала: уку-укыту планнары һәм программалары, методик мәсьәләләр, укытучылар әзерләү һәм аларның белемен күтәрү дә, татар телендә фәнни терминология булдыру, сүзлекләр төзү дә, татар театрларының репертуары, татар музыкасын үстерү һәм популярлаштыру, музейлар, китапханәләр, түгәрәкләр эшчәнлеге дә, төбәк тарихын, монда яшәгән төрле милләтләр мәдәниятен, төбәкнең табигатен, иҗтимагый, икътисади үсешен өйрәнү дә, археология, этнография, татарны өйрәнү кебек фәннәрне үстерү дә төп бурычлардан санала. Үзәк төрле юнәлешләрдә Җәмгыятьләр оештыра, алар аерым фәнни институтлар кебек эши башлыйлар. Мәсәлән, 1925 елдан Татарны өйрәнү җәмгыяте республиканың аерым кантоннарына экспедицияләр (елга 10) оештыра башлый, үз журналын – «Татарны өйрәнү җәмгыятенең хәбәрләре»н («Вестник научного общества татароведения», елга 4 сан) булдыра, китаплар бастыра, конференцияләр, төрле чаралар уздыра, экскурсияләр оештыра, халык өчен ачык лекцияләр укыла һ.б. Гыйльми үзәкнең эшчәнлеге һәм планнары хакында Г. Ибраһимовның 1925 елның 13 мартында ясаган докладына, 1926–1927 елларда эшләнгән эшләргә хисапка караганда [Академический центр…, с. 77–80; 96–108], ул, чыннан да, республикада фән, мәгариф, мәдәният, сәнгать, идеология ягыннан алдынгы көчләрне берләштергән һәм гаять зур эш алып бара торган бердәм оешмага әверелә һәм татар җәмгыятен, милли

фикерләүне, күзаллауны үстерү һәм камилләштерү өчен әһәмиятле дип тапкан төрле юнәлешләрдә җиң сызганып эшкә керешелә.

Шуларның берсе – татар әдәбияты тарихы. Әдәбиятның башка тармаклары – әдәби тәнкыйть һәм әдәбият теориясе – белән чагыштырганда мөстәкыйль фән буларак әдәбият тарихы соңарып, 1920 еллар уртасында гына мәйданга чыга. Бу эштә Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим, Г. Газиз, Г. Сәгъди хезмәтләре зур роль уйный [Гыйләҗева, б. 45].

1922–1924 еллар аралыгында Гыйльми үзәкнең әгъзалары да булган Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллиннар «Татар әдәбияты тарихы» томнарын, 1923 елда Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» хезмәтен, 1926 елда Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы»н бастыру нәкъ шушы дәүләти оешма җитәкчелегендә башкарыла. Әмма бу өлкәдә дә ике якка аерылу килеп чыга.

Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллинның фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы» – төрки халыклар тарихын, фольклорын, күпсанлы чыганакларны өйрәнеп, борынгы кулъязмаларны барлап язылган хезмәт милли сәнгать тарихын чишмә башыннан алып күзәтеп, бәяләп чыгуны күз алдында тотып уйланыла. Хезмәтнең әһәмиятен аңлау өчен, иң беренче чиратта, ул заманда татар әдәбияты тарихының, хәтта, кайсы дәверләрдән башланырга тиешлеге расланмаганлыкны әйтергә кирәк. Бу юнәлештә авторлар – беренче, һәм аларның татар әдәбияты тарихын гомумтөрки мәдәният кысаларында өзлексез барыш итеп тезә алуы гаять зур ачыш, казаныш була. Мондый концептуаль нигезне, әлбәттә, чын мәгънәсендә гыйлем ияләре, һәм Европа, һәм Шәрык фәненнән мәгълүматлы шәхесләр генә булдыра алуы шиксез.

Хезмәтнең фактик материалга бай, концептуаль төзек, теоретик нигезле булуын аерып күрсәтергә кирәк. Авторларның Монголия, Кытай, Алтай, Урта Азия, Европа тарихларын белүе, дин тарихын һәм төрки мәдәният тарихын яхшы аңлаулары аларга татар мәдәниятенең барлыкка килүен һәм үсешен Евразия тарихы фонында язарга мөмкинлек биргән. Кытай чыганакларын, Европа сәяхәтнамәләрен, В. Радлов, В. Бартольд, А. Самойлович, В. Томсен, С. Малов, Ф. Корш һ.б. рус телле фундаменталь хезмәтләрне дә, шәрык-мөселман һәм татар галимнәре, мәгърифәтчеләренең (аерым алганда, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, З. Вәлиди) карашларын да яхшы белү, чагыштыра, шулай ук борынгы текстларны укый, аңлый, анализлый алу аның чыганакчылык-историография ягыннан көчле, ышанычлы, дәлилле булуын тәэмин итә.

Авторлар сүзне бик борынгы төркиләрнең тарихы, дөньяга карашы турында сөйләүдән үк башлап китәләр. Татар әдәбияты тарихына Идел буенда туган әсәрләр дә, гомумтөрки әдәбиятта мирас булып килгән җәүһәрләр дә, Мәвараэннәһердә, Урта Азиядә, Алтайда яки Иран-Төркия җирләрендә язылып та, кардәш халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә татарларга килеп ирешкән, шулай ук чыгтай яки уйгыр, госманлы әдәбиятының татарлар тарафыннан кабул ителеп, аларның тәмам үз әсәрләре булып киткән мирас та кертеп карала.

Хезмәт татар дөньясында зур шау-шу тудыра. Г. Ибраһимов «Татарстан» газетасының 1923 ел 6 февраль (28) санында «Татар әдәбияты тарихына материаллар» дигән күләмле язма-рецензия белән чыга һәм әлеге хезмәтләрнең ерак тарихтан башлануын хуплый: «Бу, шөбһәсез, тарихи яктан да дөрест һәм, астында реаль тормыш булганга, буның гыйльми нигезе дә бардыр» [Ибраһимов, б. 311–367]. Г. Ибраһимовның хуплавы әлеге концепциягә рәсми юл ача.

Шуның белән бергә, әлеге язмада Г. Ибраһимов яңа заман әдәбияты тарихын марксизм ысулы кулланып язу кирәклеген мәсьәлә итеп куя. Әлеге бәхәс Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» – татар мәдәнияте тарихында мәгърифәтчелек, яңарыш хәрәкәтләрен җентекләп өйрәнгән хезмәт басылып чыгу уңае белән дәвам итә. Аңа бәяләмә төсендә «Кызыл байрак» газетасының 1923 ел 4 апрель (11) санына Г. Ибраһимов «Татар әдәбияты хакында тагын бер әсәр» дигән рецензия яза. Китап әдипне канәгатьләндерми: ул аның әдәбият тарихының төрле дәверләренә тигез карамавын, мәгърифәтчелек әдәбиятына игътибар җитмәүне (!), аерым авторларның (Г. Камал, Г. Чыгтай һ.б.) телгә алынмавын, әдәбиятта революция хәрәкәтләренең йогынтысы дөрес яктыртылмауны аерып тәнкыйтьли.

Г. Газиз һәм Г. Рәхим хезмәтен Җ. Вәлиди татар өчен генә түгел, бәлки бөтен төрки халыклар әдәбияты тарихын өйрәнү өчен үрнәк дип атый. (Рецензия «Безнең юл» журналының 1924 елгы 4–5 санында дөнья күрә.) Чыннан да, китап басылып чыгуга, күп кенә төрки халыкларның югары уку йортларында дәреслек итеп кулланыла башлый.

Әдәбият тарихы концепциясе бер канаты белән мирас мәсьәләсенә килеп кагыла. Г. Ибраһимов һәм Җ. Вәлиди арасындагы бәхәс шул яссылыкта 1922 елда ук башланган була. Җ. Вәлиди үткән мәдәниятне, аның идеологик асылына карамыйча, өйрәнергә һәм белергә кирәк дигән фикер уздыра, Г. Ибраһимов мираска сыйнфый якын килү таләбен яңгырата. Әйтик, «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елгы 7 март (56) санында басылган «Татар әдәбиятында өченче дәвер (Аңларга тырышыгыз!)» мәкаләсендә Г. Ибраһимов инкыйлаби әдәбиятның кыйммәтен элеккеге мирастан югарырак куя. Җ. Вәлиди «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елгы 10 март (59) санында басылган «Аңларга тырыштык, аңлый алмадык (Галимҗан иптәш Ибраһимовка җавап)» мәкаләсендә, чын сәнгать әсәрләре дөньяга караш үзгәрү белән әһәмиятен югалтмый, «бу әсәрләрнең революционныймы, түгелме икәнлеген тикшермичә, фәкать сәнгать таләпләрен үтәгәнме, юкмы икәнлеген күздә» [Җамал Вәлиди…, б. 416] тоту хакыйкать дип ассызыклый. Әдәбият тарихыннан китаплар басылып чыгу бәхәсне гамәли мәйданга күчерә.

Шушы шартларда, 1925 елның көзендә Г. Ибраһимов Г. Сәгъдине, татар әдәбияты тарихы мәсьәләләре белән шөгыльләнү өчен, махсус Казанга чакырта. 5 ел эчендә, югары уку йортларында тыгыз график белән эшләве өстенә, Г. Сәгъди утызлап гыйльми хезмәт яза.

Алар арасында иң зурлары – «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» (1926), «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» (1930), «Символизм турында» (1929 елда язылып төгәлләнә) [Гыйләҗева, б. 24–26]. Әлеге хезмәтләре белән Г. Сәгъди татар мәдәнияте яңарышы – XX гасыр әдәбияты тарихын язучы булып таныла.

Галимнең «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» хезмәте үз чоры әдәби барышын – әдәбият тарихы таләпләреннән чыгып бәяләве, күп кенә яңа күренешләрне беренче булып фәнни әйләнешкә кертүе белән үзенчәлекле була. Аерым алганда, ул К. Нәҗми, Х. Туфан, Г. Кутуй иҗатында футуристик һәм имажинистик образлылыкны тикшерә, «октябрь тудырган» яңа күренешләрнең татар әдәбиятындагы милли традицияләрне дәвам итү икәнлеген билгели. Әйтик, М. Максуд иҗатына анализ ясап, ул аның «лирик-романтик» Әхнәф Тангатаров һәм «лирик-символист» М. Хәнәфи [Сәгъди, 1930, б. 87] тарафыннан нигезләнгән лиро-эпик үзенчәлекләрне дәвам итеп, эпик иҗатта фәлсәфилек, эмоциональлек-хислелек кебек сыйфатларны киләчәк буынга тапшыруын күрсәтә [шунда ук, б. 92], «Такташ шигыре»нең үзенчәлекле хасиятләрен барлый [шунда ук, б. 121] һ.б.

1920 еллар әдәбият белеменең иң олы казанышы – шиксез, әдәбият тарихын фән буларак мәйданга чыгаруда була. Бу эштә татар галимнәренең гыйлеме һәм әзерлеге – дәүләти таләп, ихтыяҗ белән кушылып, гаять матур симбиоз килеп чыга. Татар әдәбияты тарихы – асылда, Россиядә яшәүче төрки халыклар әдәбиятларының тарихы концепциясен хасил итә. Фикри яктан ике якка аерылу вакытлы матбугат битләрендә шау-шу төсен алса да, әдәбият тарихы фәне әдәбиятка сәнгать әсәре итеп карап мәйданга чыга.

**Әдәбият нәзариясендә эзләнүләр һәм бәхәсләр**

Татар әдәбият нәзариясе фән буларак XX йөз башында формалаша [Загидуллина, 2011]. Мәктәп-мәдрәсә дәреслекләреннән башлап, бу чорда нәзари мәктәпләр-юнәлешләр булдыруга ирешкән фәнни фикердә Г. Сәгъди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди һәм башка күп кенә тынгысыз җаннарның роле зур була [Заһидуллина, 2000].

1920 елларда әлеге фән юнәлешендә концептуаль нигезне үзгәртү эше – аны марксистик эстетика белән алыштыру башлана. «Матур әдәбият эше – партия эше» дигән шигарь-лозунг рус әдәбият белеме аша татар дөньясына да үтеп керә. Аның асылы әдәби күренешләргә идеология мәнфәгатьләреннән чыгып якын килүдән гыйбарәт була. Мәсәлән, Г. Ибраһимов 1920 елда: «Фикерләр тормыштан туа, тормыш теләгән калыпка коелалар. Икътисади мөнәсәбәтләр – һәммә нәрсәнең нигезе, тамыры. Башка әйберләр – бу тамырдан чыккан үсемлекләр, гөлләр, җимешләр» [Ибраһимов, б. 241] дип раслый, 1922 елны «Өч җавап» дигән мәкаләсендә аның карашы тагын да ачыклана төшә: «Әдипләр-шагыйрьләр күктә яшәми, талантлар

күктән рухланмый, болар мәгълүм дәвернең, мәгълүм иҗтимагый-икътисади зәминнәрнең җимешләре булганга, шуңа карап, аларның безгә ача торган дөньялары, тормышлары, җанлы картиналар төрлечә була» [Ибраһимов, б. 311]. 1924 елны «Пролетариат әдәбияты турында» исемле китап язып, Г.В. Плеханов хезмәтләре нигезендә һәр язучының билгеле бер сыйныф вәкиле булып, үз иҗатында шул сыйныф идеологиясе һәм психологиясен чагылдыруын аңлата. Шуның белән әдәбиятта кешене иҗтимагый тормышта һәм көнкүрештә тасвирлау шартын калкуландыра.

Күп кенә тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр, язучылар бу мәсьәләдә дә «алтын урталыкны» таба: пролетариат әдәбиятының кыйммәте ике сыйфатны: сыйнфый карашлар белән шигъри матурлыкны берләштерүдә дип билгеләнә. Мәсәлән, Ф. Борнаш «Алтынчы елга каршы» мәкаләсендә әдәбиятның хис, эстетик зәвык тәрбияләрлек булуын сәнгатьлелек билгесе итеп күтәрә, ә инде «Матур әдәбият тирәсендә» дигән мәкаләсендә әдәби әсәрне фән яки публицистикадан аерып торучы төп шарт дип атый. 1924 елда Г. Рәхим, эстетизм һәм социологизмны аерып, әдәбиятны тикшерүнең «фикер вә идеология тарихын гына өйрәнүдән гыйбарәт» түгеллеген ассызыклый. «Әдәбиятның бу ягын өйрәнү, аны эстетика (нәфасәт) һәм форма ягыннан да өйрәнүне читтә калдырмый. Ул һәр ике яктан тикшерелергә тиеш» [Рәхим, 1924, б. 290].

Нәзария мәйданына, әдәбиятка килүче яшь буын, аерым бер төркем өчен сәнгатьлелек, образлылык, сыйнфый эчтәлек белән чагыштырганда, вак мәсьәләләрдән күрелә. Төп бәяләү критерие итеп күтәрелгәндә дә, форма тулысынча эчтәлеккә буйсындырыла. Татар матбугатында Г. Толымбайский, Ф. Мөсәгыйть, А. Шамов һ.б. әдәбиятның матурлыгы-сәнгатьлелеге анда социализм төзелеше өчен яраклы күренешләр сурәтләнүдә дип чыгышлар ясый.

1925 елны Г. Нигъмәтинең «Әдәбият мәйданында» китабы басыла, ул вакытлы матбугат битләрендә барган, әдәбиятның асылы һәм вазифасы хакындагы сөйләшүләрне йомгаклап, фәнни кагыйдәләр белән «нокта куя». «Әдәбият – матур сәнгатьләрнең бер өлеше» [Нигъмәти, 1925, б. 5], «шагыйрь нинди иҗтимагый хәләттә, кайсы сыйныфтан булса, аның ясаган-язган әсәре щул мохитнең, сыйныфның фикер-карашларын белдерә» [шунда ук, б. 18].

Татар әдәбият нәзариясендә метод һәм агымнарга хас сыйфатларны тулы билгеләп алган беренче зур хезмәт була бу. Г. Нигъмәти реализмның бердәнбер метод булып калырга тиешлеген раслый, романтизмны аңа каршы куя, символизм, имажинизм, футуризм кебек агымнарга да махсус бүлекләр багышлый. Ләкин агымнарның килеп чыгышын, үзенчәлекле билгеләрен формацияләр, сыйныфлар тарихы белән бәйләп куеп, реализмнан кала барысына да «идеалистик» ярлык сугыла. Мәсәлән, татар әдәбиятында символизм күренешен тәфсилле күзәткәннән соң, Нигъмәти символизм турында гаять тискәре нәтиҗә чыгарып куя: «Буржуа дөньясы пычракка батып, капиталның

хезмәтне изүе соң чигенә җиткән һәм буржуа дөньясы тирә-ягындагы эшчеләр-крестьяннарның авыр тормышын күрмәскә теләп, аларны алдаган һәм дини ялганнарга өстери башлаган бер вакытта сәнаигъ нәфисә дә аңа ярдәмгә килде: символизм туды. Символизм буржуазиягә колачын җәеп, мин чын тормыштан күз йомам, укучыларны да шулай итәргә өйрәтәм дип, халыкны динле булырга чакыра һәм бу юлда динне иң соңгы фән нигезләре белән яклыйм, аклыйм, диде» [Нигъмәти, 1925, б. 49]. Шул рәвешле, методларны күзәтү яңа бер кагыйдәгә юл ача: тормыш-чынбарлыктан ераклашкан әсәр сәнгатьле түгел!

1920–1930 елларда әдәбият нәзариясен бөтен, тулы бер фәнни юнәлеш итеп колачлаган хезмәтләр язылмый. Бу аңлашыла да. Әдәбиятның асылы һәм вазифалары, ягъни әдәбият нәзариясенең төп законы хакында бәхәсләр бара. Чор әдәби барышын җентекле тикшергән Ф. Галимуллин сүзләре белән әйткәндә: «Бу шартларда әдәбият фәне һәм тәнкыйте дә үз сүзен әйтүдә ирекле түгел иде» [Галимуллин, б. 219]. Шулай милли әдәбиятны тикшерә торган милли әдәбият кануннары булдыру ихтыяҗы үзеннән-үзе юкка чыга. Яңа төзелә торган тормыш барлык милләтләр өчен уртак булган кебек, әдәбиятлар да бер, уртак «олы юлга» аяк баса. 1920 еллар уртасыннан «совет әдәбияты» дигән термин кулланыла башлый, марксизм методына туры килә торган гомум бер поэтика тудыру эше алып бару хакындагы фикер әдәби җәмәгатьчелеккә җиткерелә. 1932 елны әдәбияттагы яңа иҗат методына «социалистик реализм» дигән исем бирелә. Нәзари фикер социалистик реализм методы белән язылган әсәрләргә хас сыйфатларны барлау, методның үзенчәлекләрен билгеләү эшенә тартыла.

Әдәбият нәзариясеннән беренче зур хезмәт булып дөньяга чыккан, Галимҗан Сәгъдинең «Әдәбият теориясе» (1939) социалистик реализмны пропагандалый, аннан башка методларны кире кага, әдәбиятның барлык закончалыкларын шушы метод белән бәйләнешле аңлата. Милли нәзари фикерләр исә әдәбият тарихына һәм поэтикага «күчә».

## Әдәби әсәр кануннары һәм поэтика мәсьәләләре

XX йөз башында мөстәкыйль фән булып калыплашкан әдәбият кануннарын [Заһидуллина, 2000] камилләштерү эшенә 1917 ел алып килгән үзгәрешләр ничек тәэсир итә соң? Яңа концепция өчен җирлек әзерләү эше киң җәелә, аның барлыкка килүе исә яңа әдәбият тудыру омтылышы белән бәйле була. Көчле шагыйрьләре булган татар шигърияте бу эзләнүләрдән баеп, шигырь нәзариясе чикләре киңәеп чыга.

Әлеге хәрәкәт иске әдәбиятның формасын кире кагып, чорга тиң шәкел табарга чакыру кебек башлана. Беренче карлыгачлардан, 1923 елда Һ. Такташ «Иҗадиятем турысында» мәкаләсендә «Иске шигъри өслүб (...) ялкынлы йөрәкләр өчен тар», классик поэтика иҗатны чикли дип белдерә: «татарның иске шигъри өслүбе җимерелергә тиеш», искергән өслүбне яңа өслүб алыштырыр; шигырьдә үгет-нәсыйхәт урынына тасвир булсын; әдәбият кануннары «халәте

рухиянең иркен агуына җайлаштырып язылсын; такмаклап язу урынына «сөйләп» язу кертелергә тиеш» дигән автор, шулар белән янәшә «шигырьдә матур сүзләр уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде»; «шигырьдә шагыйрь күңеленең музыкасы яңгырарга тиеш» дигән тәкъдим белән чыга [Такташ, б. 10–11].

Яшьләрчә кызулык белән «әдәбият кануннары»ннан баш тарткан, шигырьдә рифма-ритм саклану әһәмиятле түгел дип белдергән Такташны хак юлга төшерергә теләп, Г. Рәхим «Нәләтләр шагыйре» дигән күләмле мәкаләсенең икенче бүлеген нәзари мәсьәләләргә багышлый. Галим фикеренчә, сөйләм шигыре (нәсер) дә, көйләм шигыре (нәзым) дә – табигый язу юллары. «Ничек туры килде – шулай язуны «табигый сүз агымы» дип атап та, шигырьне мәгълүм бер вәзен кагыйдәсенә туры китереп (Такташ әйткәнчә «такмаклап») язуны гайре табигый бер юл дип әйтү катган ярамый» [Рәхим, 1923, б. 54].

Нинди юл белән язылса да гармония сакланырга тиеш дигән Г. Рәхим яңа форма эзләүнең җитешсезлек-кимчелекләр калдыру, гармония, аһәң, яңгыраш бозу хисабына булырга тиеш түгеллеген ассызыклый. «Нәзымның маһияте инде синең өстеңә мәгълүм кануннардан чыккан таләпләр йөкли, бер композитор ничек үзенең иҗатында билгеле музыка вә аһәң кануннары белән чикләнгән булса, шагыйрь дә шигырь язганда шундый ук кануннар белән чикләнгән; чөнки шигырь ул – шул ук музыка, тик аның сүзләргә татбикъ ителгәне генә; музыка өчен такт һәм гармониягә буйсыну ничек лазем булса, шигырь язучыга да вәзен һәм аһәңгә игътибар итү шулай ук тиеш. Киресенчә булганда, пешмәгән һәм өйрәнчек әйберләр килеп чыга» [Рәхим, 1923, б. 54].

Шулай Г. Рәхим яңа әдәбият хакында сөйләшүнең чикләрен киңәйтү омтылышы ясый. Лирик герой образы, әсәрдәге хис-кичереш бирелеше һәм аны көчәйтүче чаралар, конфликт, табигать сурәте һәм башкалар да форма элементлары, форма яңалыгы булуын искәртә.

Һ. Такташ мәкаләсе яшь каләм әһелләрендә теләктәшлек таба. 1923 елны К. Нәҗми «Әдәби адымнар һәм тәнкыйть» исемле язма бастыра. Әдәбиятны «икътисади нигез өстенә торгызылган идеология корылышының бер кисәге» санап, «җәмгыятьнең икътисади-иҗтимагый төзелешенә һәм әдипләрнең сыйнфый халәтләренә карап» әдәбият та үзгәрә дип белдерә [Нәҗми, б. 11]. Шуңа күрә иске шигърият «үзенең чикләнгән кануннары, музыкасы, вәзеннәре, кафияләре һәм башка хосусиятләре белән үзен тудырган иске җәмгыять, иске тормыш белән бергә бетәргә тиеш» [шунда ук, б. 20].

Яңа әдәбиятка килсәк, «әдәбияттагы нәзым яки нәсер рәвешләре дә әкрен генә бер-берсенә якынлашып, яңа бер форма төзү юлында тәрәккый итәләр» [шунда ук, б. 18]. «Шигырьнең яңа рәвеше күбесенчә кафиягә дә, вәзенгә дә мохтаҗ түгел. Анда билгеле бер кануннарга буйсынган юллар (мисрагълар) һәм иҗек саны да юк» [шунда ук, б. 18]. Алар урынына хәрәкәт, үзгәреш, кәеф тудыручы сүз-алымнар алга чыгар дип фараз кылына.

Х. Туфан, традицион шигырь нәзариясен ӘБИЗМ – әдәбиятта борынгылыкка ияруче законнар мәктәбе дип атый һәм чор шәкелен булдырырга чакыра [Туфан, 1928, б. 16]. 1928–1929 елларда яңа шигырь формасын вәзен һәм кафиядән [Вәли], вәзеннән [Гөлсем] эзләгән мәкаләләр языла.

Х. Туфанның «Яңа шигырь техникасы турында» исемле мәкаләсен яңа шигырь формасының үзенчәлекләрен аңлатучы кануннар җыентыгы дип тә атарга мөмкин. Форма белән эчтәлекне игезәкләр дип атаган Туфан, аларның бер-берсенә яраклы булырга тиешлекләреннән чыгып, болай яза: «Октябрь мөндәриҗәсе форманың да үзе кебек яңа һәм үзе белән яшьтәш булуын сорый» [Туфан, 1928, б. 16].

Формага нигезләнеп, Туфан әдәбиятны «иске» һәм «яңа» шигърияткә аера. Иске әдәбият кагыйдәләрен тәнкыйтьләп, андагы форма кимчелекләрен – рифманың бер төрле ишетелә торган авазлар чиратлашуы кебек аңлануын, соңгы иҗектә сузыклар гармониясе булу шартын – кире кагып, автор моны татар әдәбиятында каламбур бетемнәр белән бәйләп исбатлый.

Рифма теориясендә алгару (прогрессив) һәм арткару (регрессив) көч дигән ике төшенчәгә таянып, Туфан шаблон рифмалар файдаланганда алгару көче югала дигән закончалык тәкъдим итә. Шулай ук исемгә – исем, фигыльгә – фигыль килү кебек рифмалар, җөп бетемнәр дә алгару һәм арткару көчен киметүче үзенчәлекләр итеп күрсәтелә. Туфан яңа форма тудыруны яңа рифма законын эзләүдән башлый.

Шунысы кызык, Туфан әдәбият тарихын тулысы белән «иске әдәбият» буларак бәяләми: аның фольклор материалында ясаган кызыклы күзәтүләре бар. Мәсәлән, халык җырларында рифмаларның аһәң, яңгыраш-көй тудыруга хезмәт итүен ачыклау шундыйлардан. Туфанча, гарәп-фарсы шигърияте тәэсирендә кризиста – ӘБИЗМ коллыгында булган әдәбиятка Тукай килеп, иске кагыйдәләрне җимерә, соңрак шул ук миссияне Бабич үз җилкәсенә ала. Автор Тукайның иҗекләр саны ягыннан туры килмәүче рифмаларны гамәлгә куюын, Бабичның исә тартык авазлар гармониясенә нигезләнгән рифмалар куллана башлавын алар шигърияткә алып килгән яңалык рәвешендә шәрехли.

Х. Туфан, Г. Кутуй, К. Нәҗми, Һ. Такташ һ.б. үз иҗатларында да яңа форма элементларын тәкъдим итәләр. Ирекле шигырь Һ. Такташ һәм Г. Кутуй әсәрләрендә юл ярган кебек, Х. Туфан яңа рифмалар сыный. Мәсәлән, Х. Вәли татар әдәбиятында берсе тартыкка, берсе сузыкка беткән рифмаларны башлап Х. Туфан гамәлгә куйганлык хакында язып чыга.

Бу чорда яңа форма эзләүгә багышланган мәкаләләр зур бер хәрәкәт төсен ала. Эчтәлек – форманың психологик халәте, аңа тәэсир итүче, үзгәртә алучы берәмлек кебек аңланыла, шуңа да татар әдәбиятында форма матурлыгына гына корылган, мәгънә ягын инкяр иткән әсәрләр язылмый диярлек.

Хәрәкәтнең кульминациясе төсендә 1929 елда Х. Вәлинең «Татар шигыре төзелеше (метрикә)» китабы дөнья күрә. Автор татар шигырь

төзелешенең бер элементын – вәзенне аерып ала. Әдәби әсәр телен лингвистик методлар ярдәмендә анализлый башлавы белән ул татар шигырен җитди өйрәнүләр өчен юл башын күрсәтә. Ләкин вәзенне формацияләргә бәйләп күзәтү ялгыш юлга этәрә: Х. Вәли татар шигырь төзелеше саф силлабик булмыйча, силлабо-тоник вәзенгә корылган, киләчәктә тоник үлчәү әйдәп баручы булыр дип фаразлый.

Кызганычка каршы, хәрәкәтне әйдәп баручылар үзләре үк 1931 елдан әдәбиятка карашларын үзгәртәләр һәм форма хакындагы сөйләшү, башланган вакытында ук, читкә тибәрелә. Ә инде «форма» сүзен кулланган һәр авторга «формалист» дигән тискәре ярлык ябыштырыла башлый. Социологик поэтика мәйданга керә.

К. Нәҗми 1931 елда басылган «Иҗатым тарихыннан» мәкаләсендә элеккеге ышануларыннан ваз кичә. 1931 елны Һ.Такташның «Партиясез һәм партияле шигырьләр турында (иҗат хатлары)» исемле зур мәкаләсе «Яңалиф» журналында басыла. «Әдәбият нинди булырга тиеш?» дигән сорауга автор мондый җавап юллый:«Бүгенге пролетариат әдәбияты ул – безнең уйларыбызның хәрәкәте, идеяләребезнең омтылышы булырга тиешле» [Нәҗми, б. 87]. Нәкъ марксистларча, Такташ әдәбияттагы форма эзләүне сыйнфый көрәштән читләшү буларак тәнкыйтьли. Әдәби әсәр бәяләүнең өч билгесен күрсәтә: әсәр бүгенге көрәш хакындагы актуаль идеягә корыла; әсәр сюжеты идеягә буйсына; идеяне тирәнәйтү өчен махсус алымнар кулланыла.

1935 елны «Кызыл яшьләр» газетасы Х. Туфанның яшь язучылар иҗат бригадасы җыелышында сөйләгән докладын бастыра. Плехановча итеп, автор әдәби әсәрнең эчтәлеге тормыштагыча, типик характерларны типик материалда тасвирларга тиешлекне әйтә. Хәзер ул рифмадагы гармонияне боза торган кечкенә элементларны, хәтта басымнар туры килмәүне кимчелек саный, ягъни элек ӘБИЗМ билгеләре төсендә тәнкыйтьләнгән критерийлар яңадан сәнгатьлелек тудыру чаралары кебек аңлатыла [Туфан, 1935].

Әсәрдә образлылык мәсьәләсе шулай ук иң мөһим мәсьәләләрнең берсенә әверелә. Бу өлкәдә әдәбият теориясе герой холкындагы сыйнфый сыйфатларны калкытудан алып гомумән кеше массасын төп герой буларак сурәтләүгә кадәр юл үтә. Махсус хезмәтләрдән, 1929 елда Х. Вәлинең «Әдәби типлар механизмы» китабын күрсәтергә кирәк. Дөрес, хезмәт тип төшенчәсен сыйнфый көрәш идеологиясенә бәйли. Әмма әсәрдә төп рольне идея түгел, тормыш-чынбарлык уйный дигән автор тормыш күренешенең укучы өчен «психик» яктан кызык булуын исбатларга алына. Димәк, әдәби әсәр фикерләр яки идеяләр җыелмасы гына түгел, психик яктан төрле типлар, образлар җыелмасы кебек аңлатыла. Х. Вәли әдәбиятның яшәүчәнлеген әсәрдәге типлар системасының сурәтләнеше, урнаштырылышында күрә, әсәрнең эстетик кыйммәтен дә шушында таба. Шул рәвешле, тип, кеше образы тормыш-чынбарлыктан өстен куела һәм автор сәнгатьнең эстетик ягын да әһәмиятле дип белдерә. Бу очракта да татар нәзари фикере урталыкны сайлый.

1931 елны Г. Нигъмәтинең нигездә нәзари мәсьәләләргә багышланган «Әдәбият һәм тормыш» исемле китабы дөнья күрә. Анда марксистик әдәбият теориясенең кануннары тәкъдим ителә, яшәп килүче карашлар анализлап үтелә. «Сәнгать һәм шуның бер тармагы әдәбият та иҗтимагый бер күренеш. Ул идеологиянең үзенә хас сыйфатларга ия булган тармагы» [Нигъмәти, 1931, б. 8] дип, Нигъмәти әдәбиятның да, әдәбият фәненең дә диалектик материализм нигезенә таянырга тиешлеген әйтә. Ләкин әдәбиятның сәнгатьлелек сыйфатын да кире какмый, ике якны килештерү-яраштыру омтылышы ясый: әдәбият җәмгыять кануннарына буйсына, ләкин аның үзенә генә хас сыйфатлары бар [шунда ук, б. 8], дип яза.

Шул сыйфатлар нидән гыйбарәт соң? Г. Нигъмәти сәнгатьлелек нәзариясен образ тирәсенә җыя һәм аның ярдәмендә сыйнфый эчтәлек белән эстетик форманы берләштерә. Сәнгатьлелекнең, дөрес, сыйнфыйлык белән янәшә, әсәр төзелеше, теле, язучының индивидуаль язу рәвешендә күренүе искәртелә. Турыдан-туры әйтелмәсә дә, тормыш-чынбарлыкның, әдәбият өчен сурәтләү объекты булудан бигрәк, сурәтләү чарасы икәнлеге сиземләнә.

1932 елны тагын бер мөһим хезмәт – Г. Сәгъдинең «Символизм турында»сы басылып чыга: үткән чорлар әдәбиятын да, заман сүз сәнгатен дә әдәби-эстетик яктан тикшерү-бәяләү үрнәге бирә. Шәрык әдәбиятының өслүбләр үзгәрешен күздән кичереп, бөтен көнчыгыш һәм татар әдәбиятын бәйләнештәге система итеп карарга омтыла һәм төрки әдәбиятлардагы стильләр тарихын «тезеп куя» [Сәгъди, 1932, б. 7–10], аны чорның иҗтимагый һәм көнитеш, психологик торышы, халәте белән бәйли, аерым әдәбиятларда милли, талант иясе алып килгән хосусый үзенчәлекләр белән баетылуын искәртә. Г. Сәгъди стиль элементлары буларак образ, пейзаж, интонация һәм, иң мөһиме, автор мөнәсәбәте, кичереше кебек төшенчәләргә мөрәҗәгать итә.

Шул рәвешле, никадәр генә сыйнфыйлык, партиялелек кебек төшенчәләр мәйданга уздырылса да, поэтика өлкәсендә дә элекке фәнни традицияләрнең көче үзен нык сиздерә. Болар яшь татар шагыйрьләрен һәм язучыларын да сәнгатьлелек юлын сайларга этәрә, татар әдәбиятының сыйфат дәрәҗәсен сакларга ярдәм итә.

1920 еллар татар әдәбияты, әдәбият фәне турында сөйләгәндә, әлбәттә, бу өлкәләрдә чикләүләрнең, ясалма канун-кагыйдәләрнең иҗади фикерләүгә мәҗбүри урнаштырылуын күрми мөмкин түгел. Әмма гомуми контекстта милли мәдәниятне үстерүгә юнәлтелгән казанышларның зуррак булуы да бәхәссез. 1920 еллар, күпмедер күләмдә, XX йөз башының милли-мәдәни сикерешен дәвам итә. Кызганычка каршы, 1934 елдан бөтенләй үзгә тарихи дәвер башланып китә.

**Әдәбият**

Академический центр Наркомпроса ТААССР: документы и материалы. Казань: ИЯЛИ, 2015. 224 с.

*Әмирхан Ф.* Шәфигулла агай // Әдәби мирас. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 74–101.

*Әмирхан Ф.*Тәгъзия // Әсәрләр: 4 томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

*Вәли Х.* Яңа шигырьләрдә вәзен һәм кафия // Безнең юл. 1928. № 10. Б. 31–34.

*Гайнетдинов М., Рахимов С.* Н. Исанбет: «В Казани литературно-общественная атмосфера нездоровая» // Гасырлар авазы. 1997. № 3–4. С. 139–171.

*Галимуллин Ф.* Эстетика һәм социологизм: 20–30 нчы еллар татар әдәбиятында эстетика кануннарының һәм социологизм таләпләренең үзара мөнәсәбәте. Казан: Мәгариф, 1998. 222 б.

*Гөлсем М.* Шигырьләребездә вәзен мәсьәләсе // Безнең юл. 1929. № 9–10. Б. 24–27. (81)

*Гыйләҗева Ч.М.* Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Казан: РИЦ, 2012. 206 б.

Җамал Вәлиди: әдәби-тарихи һәм тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

*Загидуллина Д.Ф.* История науки о литературе у татар: учеб. пособие. Казань: Казан. ун-т, 2011. 132 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 207 с.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман: Татар әдәбияты нәзариясе барлыкка килү һәм үсеш этаплары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 614 б.

*Нәҗми К.* Әдәбият дөньясында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 176 б.

*Нигъмәти Г.* Әдәбият мәйданында. М.: СССР хал-ң үзәк нәшр., 1925. 109 б.

*Нигъмәти Г.* Әдәбият һәм тормыш. Казан: Яңалиф, 1931. 107 б.

*Рәхим Г.* Нәләтләр шагыйре // Безнең юл. 1923. № 10–11. Б. 62–82.

*Рәхим Г.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 279–280.

*Рәхим Г.* Урта мәктәпләрдә әдәбият укыту турында // Мәгариф. 1924. № 5. Б. 280–290.

*Сәгъди Г.* Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты («Татар әдәбияты тарихы»ның икенче бүлеге урынында). Казан: Татиздат, 1930. 200 б.

*Сәгъди Г.* Символизм турында. М.: Центр. издат., 1932. 132 б.

*Такташ Һ.* Әсәрләр: 3 томда. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 478 б.

*Туфан Х.* Шигырь язу үзенчәлекләре турында // Кызыл яшьләр. 1935. 8 март.

*Туфан Х.* Яңа шигырь техникасы турында // Безнең юл. 1928. № 6–7. Б. 16–20.

Фатих Әмирхан: традицияләр һәм заманчалык: Ф. Әмирханның тууына 120 ел тулуга багышланган республика фәнни гамәли конференция материаллары. Казан, 2006. 163 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты*

УДК 784.6

***К.М. Миңнуллин***

# ТАТАР ПРОФЕССИОНАЛЬ ҖЫРЛАРЫНЫҢ ЖАНР БУЛАРАК ФОРМАЛАШУ ЧОРЫ

Статья посвящена истории фомирования татарской профессиональной песни как жанра. Автор статьи отслеживает историю развития татарской песни в начале XX века и приходит к выводу, что основные характеристики татарской профессиональной песни сформировались именно в 10–30-е годы XX столетия. В этом процессе участвуют разные музыканты и поэты, отличающиеся друг от друга и направлениями творческой мысли, и эстетическими принципами. На взгляд автора, татарское песенное искусство является продолжением и народной музыки, и татарской советской музыки со всеми их недостатками и достижениями.

**Ключевые слова:** татарская песня, музыка, татарская музыка, история татарской профессиональной песни

This article is devoted to the history of shaping the Tatar professional song as a genre. The author of the article traces the history of the development of the Tatar song at the beginning of the 20th century and concludes that the main characteristics of the Tatar professional song were formed precisely in the 10-30s of the 20th century. Different musicians and poets participate in this process, differing from each other both in the directions of creative thought and aesthetic principles. According to the author, Tatar song art is a continuation of both folk music and Tatar Soviet music with all their shortcomings and achievements.

**Keywords:** Tatar song, music, Tatar music, history of the Tatar professional song

Бүгенге кебек үк, моннан нәкъ йөз ел элек тә Россия кыска гына вакыт эчендә гаять зур һәм катлаулы тарих кичерде. Бу вакыйгаларның әдәби-идеологик хәрәкәткә дә йогынтысы зур булды.

1905–1907 еллардагы беренче рус революциясе милли мәдәният һәм әдәбият үсешенә юл ачты. Россиянең төрле төбәкләрендә татар телендә күпләп вакытлы матбугат барлыкка килде. Ул чордагы газета-журналлар аша татар җәмгыятенең төрле катлаулары үз фикер-теләкләрен әйтергә омтылды. Матбугат битләрендә шул чорның алдынгы демократик карашлары, иҗтимагый һәм мәдәни тормыш, әдәби хәрәкәтнең җанлануы яктыртылды. Күпләгән мәкалә, рецензия, белдерү, хәбәрләрдә татар дөньясында булып узган төрле әдәби-музыкаль вакыйгаларга да зур игътибар бирелде.

Иҗтимагый тормыштагы прогрессив үзгәрешләр милли музыкаль мәдәният үсүгә дә тәэсир итә. Татарларның башка халыклар, Көнбатыш Европа көйләре белән кызыксынуы арта. Ярминкәләрдә еш кына татар музыка осталары рус һәм украин бию көйләрен уйныйлар, ә яшьләр гармун һәм фортепиано кебек музыка коралларын үзләштерергә тырышалар. Татарлар яшәгән күп кенә төбәкләрдә әдәби-музыкаль кичәләр уздырыла башлый.

Билгеле булганча, Казан шәһәренең Иске Татар бистәсе берничә йөз еллар буена Россиядәге бөтен төрки мөселманнарның танылган рухи мәркәзе булып тора. XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында әлеге милли берлек татар халкы тормыш-көнкүрешенең ул чактагы бөтен өлкәләрен чолгап алган сәяси, икътисади, мәдәни-идеологик үзгәрешләрнең төп чыганагына әверелде. Нәкъ менә Казанда – данлыклы җәдиди уку йортлары, эре нәшриятлар һәм вакытлы матбугат тупланган үзәктә, көчле иҗади мөмкинлекләре булган, шактый актив зыялылар җәмгыяте (Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Гобәйдуллин, Ф. Агиев, Г. Кариев, Г. Кәрам, В. Апанаев, Х. Ямашев һәм башка бик күпләр) барлыкка килде. Алар, буржуазия һәм руханиларның алдынгы карашлы вәкилләре белән бергә, Казандагы татар зыялыларының үзенә бертөрле элитасын тәшкил иттеләр. Бу элитаның төп максаты милләтнең алгарыш юнәлешләрен, аның дини һәм мәдәни үзенчәлекләрен саклау юлларын эзләү-билгеләү иде.

«Шәрык клубы»ндагы әдәби-музыкаль кичәләрдә катнашучылар халыкның уйнау осталыгы традицияләрен, аның кабатланмас милли үзенчәлеген саклауга һәм үстерүгә зур әһәмият бирделәр. Ф. Әмирхан, К. Мотыйгыйның концерт эшчәнлеген анализлап, аны татар халык җырларын «инде таушалып беткән урыс җырлары рәвешендә җырларга» омтылуы өчен кискен тәнкыйтьли. Һәм шунда ук, халык җырлары белән сак эш итү аеруча матур тәэсир калдыра, дип күрсәтә. Г. Тукай да шундый ук карашта торган. Ул халыкчан башкара белүне табигый һәм аһәңле дип билгеләгән, чын мәгънәсендә талантлы җырчыларга гына хас дип санаган. Шул чорда җыр фольклорын баетуда Г. Тукайның үз иҗаты да зур роль уйный. Халык аның шигырьләрен көйләргә салып җырлый. Еш кына шигырь исемнәрен дә үзгәртә. Мәсәлән, хәзер халкыбыз гимны булып әверелгән «Туган тел» җырының көе «Сәлим бабай» исеме белән йөргән. Г. Тукай замандашларының «Бәйрәм бүген» шигырен – «Ком бураны» көенә, «Мәхбүсне» борынгы «Тәфтиләү» көенә башкарулары билгеле. Бөек шагыйрьнең шигырьләре дөньяга «Пар ат», «Анам кабере янында», «Ишек бавы» кебек җырлар да бүләк итте.

Әлеге музыкаль кичәләрдә халык җырлары белән беррәттән шул чорның танылган җырчылары һәм музыкантларының беренче композиторлык тәҗрибәләре дә яңгырый башлый. Алар арасында К. Мотыйгыйның җырлары һәм музыкаль-драматик монологлары, Ф. Латыйпов әсәрләре, Г. Зайпин һәм Г. Ижбулдинның скрипка өчен пьесалары, Х. Әхмәдуллинның «Ак кош» маршы, З. Яруллинның «Җәмилә» җыры, «Тукай маршы» һ.б. була.

Гасыр башында барлыкка килгән мәдәни-агарту җәмгыятьләренең, бигрәк тә «Шәрык клубы»ндагы сәхнә эшчәнлеге үзенчә бер иҗат лабораториясе булды, киләчәктәге профессиональ сәнгать өчен плацдарм формалаштырды, дисәк тә арттыру булмас, чөнки анда татар композиторлары үзләренең беренче адымнарын ясадылар, анда музыкаль театрның, шигъриятнең, җырлау һәм уйнау осталыгының

бердәмлеге туды. Г. Зайпин оркестры чыгышын тыңлап, Ф. Әмирхан көнчыгыш стилендә опера яза алырлык композиторлар үсеп чыгуы турында хыялланган. Соңыннан татар музыкаль драмасының тууы һәм үсүенә җитди өлеш керткән С. Сәйдәшев үзенең иҗат эшчәнлеген шушы клуб оркестрында башлап җибәргән. Шулай итеп, татар халкының милли җыр-музыка иҗатын туплау һәм өйрәнү, җәмәгатьчелектә аңа карата кызыксыну уяту әлеге оешмаларның төп бурычларыннан берсе була. Алар татар халкының актив һәм фикер йөртә торган өлешен берләштерде, музыка сәнгате өлкәсендәге фундаменталь һәм планлы тикшеренүләргә кереш булды һәм XX гасыр башындагы татар мәдәни яңарышы феноменына җирлек тудырды.

XX гасырның 20 нче елларына кадәр туган җырларның шигъри эчтәлекләре һәм көйләре гаять чуар һәм капма-каршылыклы булуы күзгә ташлана. Бу табигый да, чөнки җырлар демократик халык катламының гына түгел, ә хакимлек итүче сыйныфның да ихтыяҗларын, зәвыкларын канәгатьләндерергә тиеш иделәр.

Көнкүрештә трактир кебек күңел ачу урыннарыннан чыккан җырлар да киң таралыш таба. Чөнки анда күбесенчә гаять талантлы, оста музыкантлар, гармунчылар, скрипкачылар эшли. Бу юлга аларны музыкага мәхәббәт һәм, әлбәттә, ярлылык, мохтаҗлык бастыра. Бу күпкырлы талант ияләре үзләре көй чыгарып, гадәттә аны үз исемнәре яки «гонорар» түләгән байлар исеме белән атыйлар. Мисалга «Ижбулдин», «Гармунчы Ярулла», «Баламишкин», «Айтуган көе», «Колаксыз Зариф көе», «Солтанкай», «Пороховой Фатыйх» һ.б. китерергә була. Соңрак аларга исемнәре белән бер бәйләнеше дә булмаган текстлар иҗат ителә. Мәсәлән, «Баламишкин» көенә җырлар хәзерге көндә дә бик яратып җырлана.

Татар профессиональ музыкасының, җырының туу һәм формалашу чоры турыдан-туры С. Габәши иҗаты белән бәйле. Әлеге тарихның беренче битләрен язуда аның роле гаять зур.

Татар профессиональ музыкасын, җырын үстерү нигезләре революция узуга ук салына башлый. 1918 елның ахырында Казанда татарлар өчен музыка курслары ачыла, анда С. Габәши татар мәдәнияте тарихы буенча лекцияләр укый һәм курсантларны музыка теориясе белән таныштыра. 1919 елдан бу курслар Үзәк көнчыгыш музыка мәктәбе дип йөртелә башлый.

1920 елның 25 июнендә ТАССР төзелү турында игълан ителгәч, татар музыка сәнгатен үстерү тагын да активлашып китә. Милли музыкантлар әзерләү төп мәсьәләләрнең берсе булып тора. 1921–1922 елларда Казан музыка училищесы, рус музыка җәмгыяте һәм Үзәк Көнчыгыш музыка мәктәбе базасында Көнчыгыш музыка техникумы оеша. 1921 елда Арчада һәм Чистайда ике айлык музыка курслары ачыла, алар халыкның үз арасыннан чыккан җырчыларны һәм музыкантларны тәрбияләү, авыл клублары һәм мәдәният йортлары өчен хезмәткәрләр әзерләү белән шөгыльләнәләр.

Бу еллардагы вакыйгаларга татар әдәбияты, оператив жанр буларак, бигрәк тә поэзия үз мөнәсәбәтен даими белдереп килә. Революция максатларына хезмәт иткән, шул ук вакытта әдәбиятның гуманистик традицияләрен баеткан татар поэзиясенә инде күптән танылган шагыйрьләр – М. Гафури, Г. Камал, Ф. Бурнаш, С. Сүнчәләйләр янына Һ. Такташ, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, М. Җәлил, Х. Туфан, Г. Кутуй кебек революцион рухлы яшь каләм әһелләре килеп кушыла. Поэзия гаять катлаулы һәм нәтиҗәле юл үтә, эчтәлеге һәм формасы белән яңа яңгыраш алуга ирешә. Шагыйрьләрнең аерым әсәрләре халык көе белән җыр булып тарала (Н. Исәнбәт, «Уракчы кыз»), икенчеләрен композиторлар көйгә сала. Бу урында тагын да С. Габәши иҗатына тукталу сорала.

Октябрьдән соң илебезне чолгап алган давыллы үзгәрешләр, гражданнар сугышы тәмамлану, яңа җәмгыять төзү С. Габәшинең иҗади эшчәнлегендә аеруча көчле чагылыш таба. Азат ителгән шәхесне гәүдәләндерергә, чорга хас революцион пафосны аңлатырга омтылу аның сәхнә музыкасы өчен генә түгел, бәлки җыр жанрындагы эзләнүләренә дә хас иде. Бу күзлектән караганда, музыкантның М. Гафури, Һ. Такташ, М. Крыймов, К. Әмири, Ә. Ганиев һәм башка шагыйрьләр белән нәтиҗәле эшчәнлеге кызыклы.

Революцион, иҗтимагый-сәяси эчтәлекле җырлардан К. Әмири сүзләренә язылган «Комсомол мөнәҗәте», «Эшче кыз», М. Крыймов шигырьләренә язылган «Октябрь», «Октябрь бишегендә», Һ. Такташ сүзләренә язылган «Нәләт», Ә. Ганиев сүзләренә язылган «Оппортунистларга җавап», «Большевиклар язуы», «Колхоз кырлары» җырларын билгеләп үтәргә мөмкин. Композитор, ул елларда актуаль булган темаларга язылган җырлардан тыш, «мәңгелек», гомумкешелек проблемаларын чагылдырган, кешенең матурлыгын, аның рухи байлыгын, туган якның газизлеген, ягъни бөтен яшәешнең бәхетле гармониясен гәүдәләндерә торган башка шигырьләргә дә музыка иҗат итә. Мәсәлән, М. Крыймов сүзләренә язылган «Авылыма», Т. Ченәкәй шигыренә язылган «Салчылар», М. Гафури сүзләренә язылган «Май җыры» шундыйлардан.

С. Габәшинең, композитор буларак, Һ. Такташ шигырьләренә мөрәҗәгать итүе дә игътибарга лаек. Ул – «Җир уллары трагедиясе»нә язган музыканың да авторы. Пьесаның кереш өлешендәге хор өчен язылган «Гайре табигый көчләр» исемле әсәрдән бер өзек сакланган.

С. Габәшинең үзе башлап җибәргән барлык эшләрендә дә сүз осталары белән хезмәттәшлек юлдаш булды. Музыкант белән танылган татар язучысы Ф. Әмирхан арасында олы дуслык урнаша. Композиторның «Фәтхулла хәзрәт» пьесасына музыка язуын хәзер кем генә беләдер. Әдәбият тарихчылары Ф. Әмирханның беренче татар операсы «Сания»нең авторлар коллективы белән дә эшләвен күрсәтәләр. Аны иҗат итүче Г. Әлмөхәммәдов, В. Виноградов, С. Габәшиләр Зур Кызыл урамында ул чагында язучы яшәгән йортта еш җыела торган булганнар. «Сания» либреттосы Г. Әлмөхәммәдовның шул ук исемдә-

ге поэмасына нигезләнгән була. Күрәсең, Ф. Әмирхан редакцияләүгә ярдәм иткән, булачак драма әсәренең төзелеше буенча киңәшләр биргән. 1925 елның 25 июнендә узган әлеге опера премьерасы турында матбугатта беренчеләрдән булып ул үз сүзен әйткән.

Г. Әлмөхәммәдов, В. Виноградов һәм С. Габәшиләрнең шагыйрь М. Гафури белән бергәләшеп эшләүләре татар мәдәнияте тарихында аерым сәхифә булып тора. Бу хезмәттәшлек нәтиҗәсендә икенче милли опера – М. Гафури либреттосына «Эшче» операсы язылa. Бу берлекнең рухландыручысы Г. Ибраһимов була.

М. Мәһдиев бу турыда болай дип яза: «Дүрт кешелек берлек бик уңышлы булып чыга, М. Гафури текст өстендә эшли, аңа, композиторлар һәм башкаручылар киңәшен тотып, үзгәртүләр кертә. В. Виноградов, С. Габәши, Г. Әлмөхәммәдов... композициясен төзиләр. Татарстанның 10 еллыгы «Эшче» операсының премьерасы белән тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. Ул 1930 елның 22 июнендә Г. Камал исемендәге театр бинасында була. Композиторларны һәм Уфадан килгән М. Гафурины һәр пәрдәдән соң кабат-кабат сәхнәгә чакыралар. Кул чабулар бөтен залны дер селкетәләр» [Мәһдиев, 1980].

1931 елда «Яңалиф» редакциясе журналның 3–11 нче саннарында татар музыкасы үсеше мәсьәләләренә карата фикер алышу оештыра. Моның өчен иҗат интеллигенциясенең танылган вәкилләренә унике сораудан торган анкета таратыла. Сораулар татар музыкасының үзенчәлекләрен, бу өлкәдә «европачылык» күренешен ачыклауга, музыкаль фольклор һәм этнографияне фәнни өйрәнүнең торышы, татар операсы, пролетар культура мәсьәләләренә караган була. Журналда композитор һәм фольклорчы А. Ключарев, дирижер А. Литвинов, җырчы Н. Сафин җаваплары урын ала. Биредә укучылар татар профессиональ музыка сәнгатенең башында торган композитор, фольклорчы һәм педагог С. Габәшинең милли музыкага караган теоретик карашлары белән дә танышалар. С. Габәши үзенең җавапларында пролетар музыканың үсеше турындагы мәсьәләгә шактый киң тукталa. «Октябрьдән соң гына аякка баса башлаган һәм бөтен композиторлык составы ике кул бармагы белән санарга да җитмәгән бер музыка өчен бу үсешне юк, дип әйтергә мөмкин түгелләр дип исәплим», – ди ул. «Шуның белән бергә бу үсештә бик зәгыйфь бер участокның барлыгын да яшерер хәл юк, – дип дәвам итә С. Габәши. – Ул да булса, һәр җирдә, һәркем тарафыннан дигәндәй, җиңел үтәлә торган, концерт һәм эстрадаларда соло (ялгыз) җырлау өчен заманыбызның теләвенә каратылган сүзләргә махсус язылган әсәрләрнең булмавы». Мондый хәл өчен ул композиторларны гына гаепләми, ә композитор белән шагыйрь элемтәләренең, иҗади хезмәттәшлекнең, тәнкыйтьнең тиешле хәлдә булмавын, шагыйрьләрнең шигырь белән музыка бергәлеге мәсьәләсенә әһәмият бирмәүләрен ассызыклап уза. Шунда ук С. Габәшинең 1915 елдан бирле Казанда яшәвенә, шагыйрьләр аның музыка белән шөгыльләнүен белүгә карамастан, Ф. Бурнашның «Таһир – Зөһрә»сенә музыка язуны соравыннан башка, үзенә

мөрәҗәгать итүчеләрнең булмавын әйтә. Дөрес, композитор бу хәлнең объектив сәбәпләрен дә ачыкларга омтыла һәм иҗат кешеләренең җыр язуга артык игътибар бирмәүләрен иҗат ителәчәк әсәрнең тиз генә басылмаячагына, түләү мәсьәләсенең билгеле булмавына да бәйле икәнен искәртә.

Шунысын да билгеләп үтү кирәк, җәмгыятьтәге идеологик үзгәрешләр музыка дөньясына да үтеп керә: сәнгать әһелләрен төркичелектә, исламчылыкта, пролетар музыкага каршы эшләүдә гаепләүләр башлана, матбугат битләрендә каршылыклы материаллар басыла. «Кызыл Татарстан» газетасында (1930, 28 ноябрь) «Татар музыкасында “габәшичелекк”» каршы» исемле А.П. имзасы белән чыккан язма шундыйларның берсе.

Кызганычка каршы, 20 нче еллар азагында С. Габәшигә, идея һәм сыйнфый чисталыкны саклаучыларның аны буржуаз милләтчелектә гаепләп, нахакка бәйләнүләрен кичерергә туры килә. Шуңа күрә С. Габәши 1932 елда Башкортстанга күчәргә мәҗбүр була һәм ул тормышының соңгы ун елын шунда уздыра. Анда ул педагогик, фәнни һәм музыка башкару эшчәнлеге алып бара. Ләкин аның музыкаль иҗаты инде элеккеге кебек киң колачлы була алмый.

Бу елларда аерым шагыйрьләр дә җыр жанрына игътибар итә башлый. Мәсәлән, 1925 елда Мәскәүдә М. Крыймовның «Комсомол җырлары» дип исемләнгән җыентыгы дөнья күрә. Биредә төп урынны авторның халык җырларына, «Мы – кузнецы», «Проводы» кебек рус революцион җырларына ияреп язылган әсәрләре урын алган. «Без – тимерчеләр», «Озату», «Без – комсомоллар» исемле әсәрләргә «шул рус җырлары көйләренә башкарырга» дигән искәрмәләр дә бирелгән. Һ. Такташ үзенең «Авыл яшьләре» (1925, № 4) журналына язган рецензиясендә автор иҗатына, әлеге җыентыкка шактый тулы бәя бирә, кайбер тәкъдим-теләкләр белдерә. «Крыймов иптәш – безнең шагыйрьләр арасында эшче-крәстиянгә якын торган шагыйрьләрнең берсе. Соңгы көннәрдә ул күптән эшләнергә тиешле булган “Комсомол җырлары»н язып чыгарган… Бездә комсомоллар һәм пионерлар арасында күмәк йөрүләр, күмәк эшләр вакытында бер көйгә салып җырлана торган җырлар юк иде әле», – дип, автор иҗатына уңай бәя бирә. 1928 елда М. Крыймовның әлеге җыентыгының тулыландырылган басмасы дөнья күрә. Ни сәбәптәндер шагыйрь аларда шигырьләренең С. Габәши тарафыннан көйгә салынуы хакында бернинди дә мәгълүмат бирми.

Шушы рәвешле, XX йөзнең 10 нчы елларында татар профессиональ җыр-музыка сәнгате дөньяга аваз сала, төрле жанрлар буенча беренче әсәрләр иҗат ителә, 20 нче елларда ул яңа эчтәлек белән байый. Әмма бу этапта күпчелек шигырьләр җыр булып китә алмыйлар әле. З. Яруллин, Ф. Латыйпов, Г. Әлмөхәммәдов кебек җырчы-музыкантлар да бу чорда яңа көйләр иҗат итмиләр, алар күбрәк башкаручы буларак чыгыш ясыйлар һәм яңа тормыш коруга багышланган җырларны пропагандалыйлар.

Өлкән буын музыкантлар нигез салган традицияләрнең заманча таләпләр белән чын мәгънәсендә нәтиҗәле синтезы композитор С. Сәйдәшев иҗатында гына үзенең якты чагылышын тапты. Бу иҗат тулысы белән диярлек театр сәхнәсенә бәйле иде. 1920 елда Казанда, театр сәнгатен үстерү максатында, «Күрсәтмә труппа» оештырыла. Ул ике елдан соң Татар дәүләт театры дип үзгәртелә. Театр каршында оешкан оркестр музыкаль бизәлешле спектакльләр куярга мөмкинлек бирә. Ә музыка бүлегенә җитәкче һәм дирижер сыйфатында С. Сәйдәшевнең килүе спектакльләрдә музыканың ролен шактый көчәйтә.

1922 елда К. Тинчурин чакыруы буенча Казанга кайтып, Татар драма театрында музыка бүлеге мөдире һәм дирижер булып эшли башлаганчы, С. Сәйдәшев кыска вакыт эчендә шактый бай эчтәлекле, нәтиҗәле тормыш юлы уза. Җизнәсе, заманының күренекле журналисты Ш. Әхмәров белән «Шәрык клубы»нда оештырылган әдәбимузыкаль кичәләргә, «Сәйяр» труппасы куйган спектакльләргә йөрү, күренекле әдәбият-сәнгать әһелләрен күреп-ишетеп үсү булачак композиторның күңелендә якты эз калдыра. Ул үсмер чагыннан ук төрле музыкаль ансамбль, оркестрларда уйный, алар белән җитәкчелек тә итә. Казан музыка училищесы, Оренбург Шәрык музыка мәктәпләрендә махсус белем ала.

Театрга килүнең беренче елларында С. Сәйдәшев К.Тинчуринның «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», М. Фәйзинең «Галиябану» әсәрләрен музыка ярдәмендә бизәү, баету максатында халык җырларын һәм көйләрен эшкәртә. 1926 елдан башлап аның К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1926 ел), «Ил» (1929), «Тургай» (1932), «Кандыр буе» (1932), Т. Гыйззәтнең «Наемщик» (1928) кебек әсәрләренә язган җырлары һәм көйләре әлеге әсәрләрнең идеясен тагын да тулырак ачуга хезмәт итә.

С. Сәйдәшевнең бу әсәрләрендәге вокаль номерлары – җырлар, романслар, ариозолар, дуэтлар, хор партияләре, җыр-маршлар – күпчелек очракта стиль ягыннан төрле-төрле һәм яңалыкка бай сәнгать әсәрләре булып тора иде. С. Сәйдәшевнең әлеге вокаль әсәрләренең үзенчәлеге шунда ки, алар театраль спектакль язу барышында туа һәм тәэсирле, мәгънәви, драматик эчтәлеккә ия була. Биредә композиторның үз дәвере өчен аеруча әһәмиятле һәм драма әсәре кысаларында да, театрдан тыш та яшәвен дәвам итә торган, киң популярлык казанган түбәндәге әсәрләрен искә алу да җитә: К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» пьесасыннан Булат башкара торган «Кара урман» ариясе, «Туган ил» пьесасыннан «Сандугач» ариясе, «Кандыр буе»ннан «Монтерлар җыры», Т. Гыйззәтнең «Наемщик» пьесасыннан «Гөлйөзем» ариясе, Ф. Бурнашның «Хөсәен мирза» пьесасыннан «Бибисара» җыры һ.б.

Соңрак Җ. Фәйзи композиторның бу иҗат этабын болай бәяләде: «С. Сәйдәшев музыкасы белән бара торган бик күп әсәрләр күрдем… Тик ул әсәрләр үзләренең көйләре, җырлары белән миндә тирән хисләр кузгата алмаганнар иде кебек. Дөрес, оркестр дә әйбәт,

җыр-биюләр дә ярыйсы гына, ә көйләр, сүзләр халыкныкы бит. Күрәсең, драматурглар шулай уйлаган, режиссерлар кабул иткән. «Зәңгәр шәл»дә исә мин Салих абыйның композиторлык талантына ышандым. Монда, халык көйләреннән тыш, Сәйдәшев үзе язган җыр-биюләр дә күп: «Кара урман», «Качкыннар җыры», «Мәйсәрә җыры», «Качкыннар биюе», «Шахтер җыры» һәм башкалар» [Фәйзи, 1987, б. 392].

Татар җыр сәнгатен, шулай ук профессиональ музыкасын үстерүдә Т. Гыйззәтнең 1928 елда куелган «Наемщик» драмасы аеруча зур роль уйнады. Зур-зур арияләр, вокаль дуэтлар белән бергә, автор күптавышлы хорлар да куллана. Мәсәлән, Батырҗан җырларында җыр куплеты соло белән, кушымта күп тавышлы хор ярдәмендә башкарыла. Музыка белгече З. Сәйдәшева раславынча, моңа кадәр спектакльләрдә хор бер генә тавыш белән җырлаган була.

Драматург Р. Ишморат С. Сәйдәшевнең бу чор иҗатын: «“Наемщик” спектакле, “Галиябану”, “Зәңгәр шәл” кебек музыкаль спектакльләр рәтенә яңа көчле агым булып кушыла һәм театрыбыз, музыкаль культурабыз үсешендә зур роль уйный. Үзенең дәртле, ашкын моңы, гүзәл аһәңе белән “Наемщик”тагы музыка Сәйдәш иҗатында иң югары ноктаһарның берсе булып тора», – дип бәяләде [Ишморат, 1988, б. 66–70].

С. Сәйдәшев 1922–1932 елларда үзе өчен яңа авторлар Ф. Бурнаш, Г. Кутуй, Г. Минский, Х. Ибраһимовлар белән дә иҗади хезмәттәшлек итә һәм барлыгы 40 тан артык спектакльгә музыка яза.

Композиторның иҗат юлын өйрәнүче Ф. Салитова хаклы рәвештә күрсәтеп үткәнчә, «Музыкаль драма татар совет җырындагы барлык жанр төрләренең дә формалашу һәм үсеш процессын иңләп алды. Анда 20–30 нчы еллар массакүләм совет җыр иҗатына хас стильләр һәм образлылыкның гомум билгеләре бик ачык чагылдылар» [Салитова, 1985].

С. Сәйдәшев иҗат иткән музыкаль драмаларында музыканың төрле формаларын куллануы (инструменталь увертюралар, интермедияләр, бию күренешләре, вокаль номерлар: арияләр, дуэтлар, ансамбльләр, хорлар, җырлар) тыңлаучыларны өлешчә 20 нче, бигрәк тә 30 нчы елларда барлыкка килгән күпкә катлаулырак жанрларны кабул итәргә әзерләде.

Театр сәхнәсендә туган бу җырларны пропагандалау, аларга мөстәкыйльләшү көче бирүдә һәм, гомумән, татар халкының мәдәни тормышын баетуда 1927 елда Казанда ачылган «Октябрьның 10 еллыгы» исемендәге радиостанциянең дә роле зур була. Монда С. Айдаров, Г. Кайбицкая, С. Садыйкова, М. Рахманкулова, Г. Камаева, Н. Сафин кебек танылган җырчылар, Ф. Биккинин, М. Яушев, Х. Әхмәдуллин кебек халык музыкантлары спектакльләр өчен язылган әсәрләрне тыңлаучыларга ирештерәләр. Болар йогынтысында татар халык һәм профессиональ музыкасын пропагандалауга һәм үзешчән сәнгатьне үстерүгә шартлар тудырылды.

Күргәнебезчә, бу чорда татар сәхнәсендә музыкаль әсәрләр куюның саны арта. Музыкалы драма башкаручылардан яңа сыйфатлар – җырлау өчен тавыш, музыкаль сәләт таләп итеп, театрның үз эчендә дә революция ясый. Беренче планга артистлык сәләтенә ия булган җырчы чыга. Шуңа да драма һәм комедияләрдә, уйнау осталыгы белән бергә, җырлау сәләтенә дә ия булган, бу җәһәттән зур уңышларга ирешкән С. Айдаров, Г. Әлмөхәммәдов, С. Садыйкова, Г. Кайбицкая, Р. Кушловская кебек артистларның иҗаты нәкъ шушы елларда башлана. Музыкаль драма жанры үзе дә бер урында тормый, үсүен дәвам итә. Аның төрләре үзгәрә, эчтәлеге яңара, ул тормышчанрак була бара.

Әмма музыкаль драма жанрының үсеше каршылыкларсыз гына бармый. Матбугатта әледән-әле бу теманы яктырткан материаллар басыла, чыгышларда жанрның сыйфатын яхшырту юнәлешендәге фикер-тәкъдимнәр белән бергә кискен, вакыты белән нигезсез тәнкыйть ишетелә. Мәсәлән, Һ. Такташ «Безнең байрак» (1923, 10 апр.) газетасында шагыйрь Ә. Сәгыйдинең «Сак-сок» драмасы буенча куелган спектакльгә карата үзенең «Оперетта каһарманнары» исемле тәнкыйди рецензиясен бастыра. Ул анда әлеге әсәр авторын һәм спектакльне куючыларны татар театрын «балаган дәрәҗәсенә китерү»дә гаепли. Бер очтан Һ. Такташ шул чорның «Башмагым», «Галир тәңкә», «Йосыф – Зөләйха» кебек халыкта популярлык казанган музыкаль әсәрләрне дә тәнкыйть утына тота.

Соңрак М. Җәлил дә «Совет драматургиясе яңа чорда» исемле чыгышында бу музыкаль драмаларга карата җитди тәкъдимнәр белән чыга. «Әсәрдә музыка мәсьәләсе – шулай ук мөһим мәсьәлә, – ди ул. – …Музыка уенга каяндыр механически китереп ябыштырылган әйбер булырга тиеш түгел. Ул халыкның күңелен ачу, уяту өчен генә уйланган әйбер булмасын. Музыканың үзенең содержаниесе бар. Ул, артист уены шикелле үк, әсәрдәге идея һәм сурәтне ачарга хезмәт итсен… Бездә күбрәк Тинчурин тәҗрибәсендә кулланылган музыкалы пьесалар моның киресен күрсәтеп килделәр» [Җәлил, 4 т., б. 85].

К. Гыйззәтов драматург Таҗи Гыйззәт иҗатына багышланган хезмәтендә бу мәсьәләгә кагылып болай ди: «Музыкаль драмага кырын караулар 30 нчы елларның башында ук сизелә башлаган иде… Әйтергә мөмкин, музыкаль драмага чырай сытулар башта Академия театрының үз җирлегендә (артистларның кайбер төркемнәре арасында) барлыкка килде. Биредә аларның иҗат принциплары (әйтик, берәүләрнең күбрәк рус һәм Көнбатыш классикасына ориентир тотуы, ә кайбер режиссерларның конструктивизм һәм башка шушындыйрак «изм»нарга иярүләре) белән бергә турыдан-туры практик интереслары да (музыкаль спектакльләрдә үзләренең актерлык сәләтен тулы рәвештә ачалмаудан шикләнүләре) чагылгандыр. Шушы чорда (30 нчы еллар башы) татар академия театрының музыкаль спектакльләр белән «мавыгуы» үзәк пресса тарафыннан да тәнкыйтьләнгән иде. …Тора-бара (30 нчы еллар азагына таба) музыкаль драмага кире карашның җирлеге киңәеп тә китте» [Гыйззәтов, 2000, б. 265].

Ничек кенә булмасын, музыкаль драма татар милли сәхнә сәнгатендә мөһим тарихи функцияне башкарды. Ул, беренчедән, профессиональ җыр жанрын формалаштыру һәм үстерүдә зур роль уйнаса, икенчедән, драма һәм яңа туып килә торган милли опера жанрын тоташтыручы буын хезмәтен үтәде, шушы ике сәнгать төре арасында күчешле этап тәшкил итте.

20 нче еллар ахыры татар сәнгатендә театр сәхнәсенә бәйләнеше булмаган мөстәкыйль җырлар үсешендә дә яңа этап башлануы, яңа буын җырларның яңгыраш алуы белән игътибарга лаек. Әлеге күренеш композитор Л. Хәмиди һәм М. Җәлил исемнәре белән бәйле. 1927 елда Л. Хәмиди Мәскәүгә килә һәм музыка техникумының композиция бүлегендә укый башлый, шул ук вакытта татар мәктәпләрендә дәресләр дә алып бара. Бу вакытта балалар өчен махсус җырлар булмаганлыктан, яшь композитор аларны язу эшен дә үз өстенә ала. Иҗат эшендә аңа Казанда яшәү чорында ук дуслашып өлгергән М. Җәлил зур ярдәм күрсәтә. Балалар өчен күп иҗат иткән, балалар һәм яшьләрнең матбугат органнарында автор буларак та, редколлегия әгъзасы буларак та актив катнашкан шагыйрь Л. Хәмиди тәкъдимен хуплап кабул итә. Аларның «Күрсәт әле», «Куян» дип исемләнгән тәүге иҗат җимешләре кече яшьтәге балаларга багышлана. Бераз соңрак «Октябрь җырлары», «Көз җитте», шактый популярлык казанган «Юнгштурм» һәм әлеге авторларның иң уңышлы, бүгенге көндә дә халык күңелендә, җырчылар репертуарында яшәп килгән «Беренче вальс» (икенче исеме «Уңыш бәйрәмендә») һәм «Күңелле яшьләр» җырлары иҗат ителә.

Әлеге иҗади дуслык нәтиҗәсендә 1929–1932 елларда ун җыр языла. Аларның күбесе балалар һәм яшьләр өчен Мәскәүдә нәшер ителүче «Октябрь баласы» һәм «Ударниклар» журналында басыла.

Октябрь революциясе һәм аннан соңгы елларда илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр, бер яктан, әдәбият-сәнгать өлкәсен, югарыда күреп узылганча, яңа иҗади эзләнүләргә китерсә, икенче яктан, җәмгыятьтәге кискен борылыш бу өлкәне мәгълүм бер бушлыкка да дучар итә: җыр җыентыклары һәм, гомумән, китап бастыру эше сүлпәнәя, вакытлы матбугатта да бу мәсьәләгә караган язмалар сирәгәя, гасыр башында актив эшләгән авторларның күбесе иҗаттан читләшә.

20 нче еллар ахырына таба, 30 нчы елларда һәм татар, һәм рус телләрендәге вакытлы матбугатта җыр-музыкага караган язмалар ешрак дөнья күрә башлый. «Совет әдәбияты», «Кызыл Татарстан», «Кызыл яшьләр», «Азат хатын», «Пионер каләме» кебек басмаларда музыкаль чараларга караган хәбәрләр, җыр текстлары басыла. Аларның күбесе – яңа тормыш коруга, Кызыл Армия, колхозлашу, Ленин һәм Сталинга багышланган әсәрләр. Дөрес, арада татар музыкаль-поэтик сәнгатен анализлау, аның бүгенге торышын бәяләү, яңа социаль шартларда милли культураның ролен ачыклау, халык иҗатын туплау һәм бастырып чыгару мәсьәләләренә караган язмалар да очрый.

Әлбәттә, профессиональ җыр өлкәсендәге беренче тәҗрибәләр генә яңа идеологиягә корылган җәмгыять таләпләренә җавап биреп бетерә алмыйлар иде әле. Бу хәл иҗат интеллигенциясен борчый, алар җыр сәнгатенең мондый торышына үз мөнәсәбәтен белдерә, матбугат битләрендә, чыгыш-докладларда төрле тәкъдимнәр белән чыга.

Беренчеләрдән булып, бу мәсьәләгә А. Алиш игътибар итә. Ул үзенең «Яңа илгә яңа җырлар кирәк» дип исемләнгән язмасында («Кызыл яшьләр», 1930, № 9) массовый җырлар иҗат итү эшенең бик сүлпән баруын, авыл сәхнәләре, шәһәр клублары, пионер, комсомол, гаскәри оешмалар өчен җырлар булмауны искәртә. «Чыгып килә торган вакытлы матбугат та, яшь язучылар секциясе дә һәм башка оешмалар да бу эш белән кирәгенчә кызыксынмыйлар. Бу эштә “Октябрь баласы” журналы нәни омтылышлар ясаса да бу гына җитәрлек дип әйтеп булмый, ә “Яшь ленинчы” газетасы бу мәсьәләне әле исенә дә кертеп чыгарганы юк. Җыр мәсьәләсе ул композиция мәсьәләсе белән дә бәйләнгән. Бездә композиторлар ике-өчтән артмыйлар…», – ди автор һәм үзенең кайбер тәкъдимнәрен бәян итә. Аларда ул яшь язучылар секциясендә хәзерге җырлар турында доклад куярга, язучылар арасында җыр тудыруга социалистик ярыш ачарга, җыр иҗат итүгә композиторларны газета аша чакырырга, җырларның массалашуын белү өчен клублар белән бәйләнештә булырга, массовый җырлардан җыентыклар чыгарырга кирәклеген искәртә.

Шул ук көннәрдә әлеге газетада (1930, 22 февраль) Г. Кәбир дә «Җырлар турында минем фикер» исемле язмасын бастыра. Автор язмада «Әлеге дәвердә берәүләр җыр мәсьәләсенә өстән генә карап, “әле җырлар белән маташа торган вакыт түгел” дип әйтәләр. Шунлыктан иске җырларны эшләп бергә туплау, яңа җырлар тудыру эше беркем тарафыннан да башкарылганы юк», – дип, җыр сәнгатенә караган ике зур проблеманы көн тәртибенә чыгара. Алга таба ул җыр китапларын нәшер итү мәсьәләсенә бәйле рәвештә җырларның тематик төркемнәренең эшләнмәвен, шуның аркасында хезмәт коллективларында «бөек төзелеш» өчен әһәмиятсез җырлар яшәп килүен искәртә.

Болардан тыш сәнгать әһелләренең «Яңалиф» журналы сорауларына җаваплары (1931, № 3–6), М. Җәлилнең «Татар совет музыкасы һәм композитор Ключарев» («Коммунист», 1933, 30 ноябрь), «Совет балалар әдәбиятына иң нык игътибар!» («Кызыл яшьләр», 1934, 12 июнь) исемле язмаларында да профессиональ җырга бәйле җитди мәсьәләләр күтәрелә.

30 нчы елларда поэзия халык тормышын үсештә, хәрәкәттә күрсәтү, хезмәт кешесенең рухи дөньясын, характерын һәм әхлагын сурәтләү юлында җитди уңышларга ирешә. Яңа җәмгыять төзү, кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәт, яңа проблемалар поэзиядә тирән эз калдыра, халык батырлыгын, яңа төзелешләр, удар хезмәт, колхозлашу, шул ук вакытта мәңгелек хакыйкать, тормыш фәлсәфәсе дә уйландыра. М. Җәлил, Ә. Ерикәй, Ә. Фәйзи кебек шагыйрьләр лирик шигырь белән халык җыры арасындагы якынлыкны эзлиләр.

Халыкчан интонация, лирик аһәңле, формасы белән халык җырларына якын композицияле шигырьне үстерүгә зур көч куялар.

Бу еллар татар музыкасы, җыр сәнгатенең зур үсешкә ирешүе белән дә тарихка кереп калды. Югыйсә, 30 нчы еллар башында бу өлкәдә мәгълүм бер сүлпәнлек хөкем сөрә башлаган иде. Театр сәхнәсендә 1932 елда К. Тинчурин белән С. Сәйдәшевнең «Кандыр буе» драмасы куелганнан соң, вакыйга булырлык музыкаль әсәрләр килүдән туктый. Тормыштагы табигый сәбәпләр аркасында, Мәскәүдә яшәгән М. Җәлил белән Л. Хәмидинең дә иҗади хезмәттәшлеге акрынлап тәмамланугa бара. С. Габәши Башкортстанга күчеп китәргә мәҗбүр була. 20–30 нчы еллар аралыгында сәнгатькә килгән композиторлар иҗади эзләнү этабы кичерәләр, күбрәк халык көйләрен эшкәртү, күләмле музыкаль әсәрләр иҗат итү өстендә эшлиләр. Дөрес, җырлар язу да дәвам итә. Шагыйрьләрнең аерым әсәрләре йә композиторлар, йә халык тарафыннан көйгә салына. Мәсәлән, Мәскәү консерваториясен тәмамлап кайткан М. Мозаффаров төрле жанрдагы музыкаль әсәрләр белән беррәттән шагыйрьләр иҗатына да мөрәҗәгать итә. Аның бу елларда төрле темаларга язылган «Безнең җыр» (М. Җәлил сүзләре), «Карт диңгезче» (М. Әсфәндияров сүзләре), «Корыч адымнар» (Г. Мөхәммәтшин сүзләре), «Металл җыры» (Ф. Кәрим сүзләре) һәм башка күп кенә җырлары билгеле. Авторларның аерым әсәрләре киң яңгыраш ала, популярлык казана. Алар арасында Һ. Такташның «Урман кызы» (Җ. Фәйзи көе), Х. Туфанның «Ак каен» (халык көе), Ә. Ерикәйнең «Кәккүк» (С. Габәши көе) җыры аеруча игътибарга лаек.

Әмма бу әсәрләр генә җыр жанрын тулы канлы яшәешкә китерә алмый. Югары художестволы милли музыкаль әсәрләр иҗат итү квалификацияле кадрлар тәрбияләүне таләп итә. Шул максат белән 1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе ачыла. Студиянең төп бурычлары урта белем алган композиторларга, иҗатка һәвәс яшь музыкантларга, җырчыларга композиция һәм башкару осталыгы буенча профессиональ музыкаль белем бирү һәм татар опера театрын ачуга әзерләнүдән гыйбарәт була. 1934–1938 елларда эшләгән бу студиягә композиторлар С. Сәйдәшев, З. Хәбибуллин, Җ. Фәйзи, Л. Хәмиди укырга җибәрелә. Бу вакытта Мәскәү консерваториясендә укыган Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, М. Латыйповлар да шушы иҗат атмосферасында кайныйлар. Барлыгы 30 га якын җырчы, алар арасында У. Әлмиев, Г. Кайбицкая, С. Садыйкова, М. Булатова, Ф. Насретдинов, М. Рахманкулова һәм А. Измайлова шунда белем ала.

20 нче елларда сәхнә музыкасына, масштаблы әсәрләр күләгәсендәрәк булган җыр жанрына яңа сулыш бирәләр. Профессиональ җыр мөстәкыйль рәвештә, үз ирегендә яши һәм җәмгыятьтә барган вакыйгаларга, үзгәрешләргә бәйле рәвештә яңа темалар һәм образлар белән байый, махсус җыр җыентыкларында ныклы урын ала башлый. Шулай итеп, татар авторларының җырлары халык җырлары белән бердәй таралыш ала.

Нәтиҗә ясап шуны әйтә алабыз: татар профессиональ җырының төп билгеләре XX гасырның 10–30 нчы елларында формалаша. Бу процесста бер-берсеннән, сәнгати фикерләү юнәлешләре белән генә түгел, төрле эстетик принциплары белән дә аерылып торган музыка һәм шигырь осталары үзара актив бәйләнештә иҗат итәләр. Татар җыр сәнгате үзенең күпчелек яклары белән революциягә кадәрге милли музыканың да, татар совет музыкасының да, аларның кимчелек һәм казанышларының да дәвамы булып тора.

**Әдәбият**

*Мәһдиев М.* Мәҗит Гафури. Тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 31 б.

*Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре. Күңелем кыллары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 392 б.

*Ишморат Р.* Дусларым, остазларым. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

*Салитова Ф.* Роль музыкальной драмы С. Сайдашева в становлении татарской профессиональной музыки: автореф. дис. ... канд. искусствоведения. Ташкент, 1985.

*Җәлил М.* Әсәрләр: 4 томда. 4 т. 1976.

*Гыйззәтов К.* Таҗи Гыйззәт: Фикерләр. Истәлекләр. Хатлар. Бәхәсләр. Казан: Мастер Лайн, 2000. 512 б.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институты директоры*

УДК 398

***И.И. Ямалтдинов***

# ТАССР ОЕШУЫНЫҢ ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫ ҮСЕШЕНӘ ЙОГЫНТЫСЫ: 1920–1930 елларда фәнни проблемалар һәм аларны тикшерү

Статья посвящена раскрытию научных проблем и исследованию татарского фольклора – развитию татарской фольклористики в 20–30-х годах XX века после образования ТАССР.

**Ключевые слова:** ТАССР, татарская фольклористика, народное творчество, фольклор, развитие фольклористики.

The article is devoted to the disclosure of scientific problems and the study of Tatar folklore, the development of Tatar folklore in the 20–30s of the twentieth century after the formation of the TASSR.

**Keywords:** TASSR, Tatar folklore, folk art, folklore, the development of folklore.

Татар халкының гасырлар дәвамында барлыкка килгән авыз иҗаты гаять бай һәм төрле. Милли фольклор әсәрләрен җыю, системалаштыру, өйрәнү, аларга характеристика бирү һәм классификация ясау һәрвакыт татар фольклористикасының мөһим бурычларының берсе булып тора. XIX гасыр урталарыннан татар фольклорын җыю һәм өйрәнү эшен татар мәгърифәтчеләре дәвам иттерә. XX йөз башында татар халык иҗатын фольклорчылардан Х. Бәдигый, Ф. Туйкин, Г. Рәшиди, әдәбиятчы галимнәрдән Г. Баттал һәм Г. Рәхим, шулай ук шагыйрь һәм язучылардан Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан өйрәнә. Алар фольклор проблемалары белән шөгыльләнәләр, үзләренең оригиналь фикерләрен әйтәләр, халык иҗаты һәм аның аерым жанрларының үзенчәлекләре турында күзәтүләр ясыйлар, мәкаләләр бастыралар, җыентыклар нәшер итәләр һәм шуның белән милли фольклористиканың үсешенә шактый зур өлеш кертәләр [Урманчеев, б. 20; Бакиров, б. 12]. Болар барысы да XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар халкының иҗтимагый-сәяси һәм милли-мәдәни тормышының җанлануы фонында була.

Гомумән, XIX–XX йөз башында, бихисап татар фольклоры әсәрләрен җыю һәм бастыру эше белән беррәттән, беренче фәнни хезмәтләр языла.

1920 елларда ТАССР төзелүгә бәйле рәвештә татар фольклорын пропагандалау һәм фәнни өйрәнүгә булган кызыксыну күп тапкыр арта. 1921 елда Татар Мәгариф халык комиссариаты каршында беренче фәнни оешма – Академик үзәк төзелү республиканың мәдәни-фәнни тормышында яңа этапның башы һәм зур вакыйгасы булып тора. Ул үзенең эшчәнлеген 1933 елга кадәр туктатмый.

Аның составында рус һәм татар редакцион коллегиясе, фәнни-педагогик комиссия, баш архив һәм музейлар белән җитәкчелек итү, өлкәне өйрәнүче бюро эшли. Беренче рәисе – Гаяз Максудов, ә гыйльми сәркәтибе Заһидулла Нуркин була. Г. Ибраһимов Академүзәкнең илһамчысы була. 1922 елдан ул – редакцион коллегия әгъзасы, татарларны өйрәнү җәмгыяте рәисе урынбасары; 1925 елда Татар Мәгариф халык комиссариаты утырышында Академүзәкнең рәисе итеп билгеләнә. Ул Үзәккә күренекле галимнәрне җыя. Г. Ибраһимов, җитәкче буларак, фольклорны җыю һәм өйрәнү эшенә гаять зур игътибар бирә. Бу чорда үзәк каршында «Халык әдәбиятын эшләү комиссиясе» төзелә. Ул татар халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм бастыру мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлый. Татарлар компактлы яшәгән төбәкләргә фольклор җыю буенча махсус кулланма җибәрә. Әлеге документ фәнни даирәләрдә билгеле булган Г. Рәхим һәм М. Васильев тарафыннан шул чорда татар әдәбиятында барлыкка килгән культура-тарих мәктәбе принципларына таянып, шулай ук киң планда төп халык иҗаты жанрларын өйрәнү максаты белән Г. Ибраһимов тарафыннан билгеләнгән проблемалар нигезендә төзелә [Ямалтдинов, б. 23].

Шулай итеп, халык авыз иҗатын җыю, бастыру һәм өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлек дәүләт оешмасы планына кертелеп, системалы рәвештә алып барыла башлый.

1920 елларда татар фольклористикасы буенча эшчәнлек моның белән генә чикләнми. Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм өйрәнү эше буенча башка мөһим адымнар ясала. Академик үзәк составына кермәгән фольклорчылар да (Фазыл Туйкин, Фатыйх Сәйфи (Казанлы)) була. Аларның тикшеренүләре Үзәк планына кертелми, ләкин алар аның белән тыгыз бәйләнештә торып эшли. Аерым алганда, Ф. Туйкин бик күп материалларын халык әдәбиятын эшләү комиссиясенә тапшыра.

Шушы чорда татар фольклоры Казанның югары уку йортларында предмет буларак укытыла башлый, һәм аны фәнни яктан өйрәнү өчен шартлар тудырыла.

Көнчыгыш педагогика институты доценты Г. Рәхим берничә ел татар фольклоры курсын укыта. Үзенең лекцияләрендә борынгы гомумтөрки катламнарга басым ясый. Халык әдәбияты иң борынгы төркиләрнең күзаллауларын дәлилләү чыганагы дигән фикерне алга сөрә. Текстның төзелеше һәм язылу стиленнән чыгып, фольклор әсәрләрен «көйле һәм көйсезләргә» бүлә. Мәдрәсә фольклорына аеруча зур игътибар бирә, Казан ханлыгы турындагы легендаларга һәм тарихи бәетләргә аерым туктала [Толымбай, б. 94–95].

1924 елда Г. Рәхим һәм Г. Газиз «Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер» басмасының беренче томыннан ике бүлеген бастыралар. Культура-тарих мәктәбе вәкилләре буларак, авторлар әдәбият тарихын яктыртуга системалы якын киләләр, шулай ук эволюцион һәм культура-тарих методларына таяналар. Аерым алганда, фольклорны әдәбиятның нигезе итеп саныйлар һәм «Борынгы төркиләрнең

әдәбиятлары» бүлегендә борынгы авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен, шулай ук фольклор һәм язма әдәбият буенча хезмәтләрне өйрәнәләр. «Идел буендагы борынгы тел һәйкәлләре» бүлегендә шул чор фольклоры һәм Идел буена Шәрык халыклары фольклорының үтеп керүе турында сүз бара. Шул ук елда әлеге авторлар тарафыннан «Татар әдәбияты тарихы. I җилд: Борынгы дәвер: 3 нче бүлек: 17, 18 һәм 19 гасырларда иске әдәбият» китабы бастырыла. Анда да фольклорга шактый зур урын бирелә. «Татар әдәбияты тарихы»нда феодализм чорындагы дастаннар, бәетләр, әкиятләр турында фикерләр әйтелә.

1927–1928 елларда «Безнең юл» журналында Ф. Туйкинның «Халык әдәбиятын тикшерү юлында» һәм Г. Толымбайның «Татар фольклоры турында кайбер фикерләр», «Тукай һәм әдәби фольклорыбыз» мәкаләләре дөнья күрә. Әле хезмәтләрдә халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү өлкәсендәге җитешсезлекләр күрсәтелә, фольклорны «рухи атмосфера» һәм иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнештә комплекслы тикшерү тәкъдим ителә.

1929 елда «Татарстан» журналында Н.И. Воробьевның «1929 елның җәендә Нократ һәм Глазов татарлары янына бару», «Татар җөмһүриятенең Минзәлә кантонындагы халыкны этнографик ягыннан күзәтү» дигән мәкаләләре басылып чыга.

Н. Воробьевның татар этнографиясен өйрәнүгә карата әйтелгән, фольклорны һәм милли мәдәниятне өйрәнүгә комплекслы якын килү мәсьәләсен күтәргән фикерен яклап, Г. Толымбай болай дип яза: «Казан татарлары культурасын тикшереп караганда, анда борынгы төрки халыкларының, Урта Азия мөселман культурасын, шулай ук фин, рус халыклары йогынтысын күрергә була. Без фольклорны тикшергәндә культураларның бәйләнешен күрәбез. Безгә мифологиядән пәри, дию, шайтаннарны тикшергәндә, Урта Азия аркылы килгән культураны истә тотарга кирәк була, әкиятләрне чагыштырганда рус әкиятләренә бик нык игътибар итәргә туры килә, угыз сөте, багучы кебекләрне тикшергәндә, иске күчмә төрекләргә үк кайтмый хәл юк» [Тулумбайский, б. 58].

1920 еллардагы яңа сәяси шартларда татар фольклорын өйрәнү буенча рус авторларының да тикшеренүләре барлыкка килә (бигрәк тә җырлар буенча). Алар арасында Н.В. Никольскийның «Идел буе халыкларының халык музыкасы тарихы буенча конспект» («Конспект по истории народной музыки у народностей Поволжья», 1920), В. Виноградовның «Татар халык җыры, аны саклау һәм тикшерү турында берничә сүз» («Несколько слов о татарской народной песне, ее хранении и разработке», 1921), А. Симаковның «Татар республикасында музыкаль гыйлем» («Музыкальное просвещение в Татарской республике», 1921), А. Эйхенвальдның «Халык җыры һәм Казан татарлары музыкасы» («Народная песня и музыка казанских татар», 1923) мәкаләләрен билгеләп үтәргә була.

Р. Лахның төрки-татар, Кавказ, һәм шулай ук фин-угор халыкларының музыкасы һәм музыкаль фольклоры (1920), Т. Ковальскийның

төрки халыкларның шигырь төзелешендәге поэтик формалар (1921), Н. Фирсовның Казанга нигез салыну турындагы риваятьләр һәм легендалар (1926), Н.К. Дмитриев белән О. Чацкаяның татар җырларын җыю, өйрәнү, җырларның көйләре, аларның жанр төрләре һәм шигырь төзелеше турындагы мәкаләләрен дә билгеләп үтү зарур. Болардан тыш, Д. Ливитскийның «Татар халык җырлары турында» («О татарских народных песнях», 1928), А. Лининның «Казан-татар поэзиясе: халык поэзиясе формалары турындагы яңа тикшеренүләрдән» («Казанско-татарская поэзия: из новых исследований о формах народной поэзии», 1928), Ф. Маловның «Татар яшьләренең җырлары» да татар халык иҗатын өйрәнеп тикшерүгә багышланган [Миңнуллин, б. 30].

1920 елда Гата Исхакый әдәбият тарихы һәм теориясе буенча «Әдәбият юллары: Рөшди мәктәпләремез өчен дәреслек» китабын бастыра. Аның «Халык әдәбияты» бүлегендә дә татар фольклоры турында кыскача мәгълүмат бирелә.

Фольклорчы Х. Бәдигый 1920 елларның беренче яртысында Казан педагогика техникумында укыта, Академүзәктә эшли, Ленинград Көнчыгышны өйрәнү институтын һәм аспирантурасын тәмамлаганнан соң, 1930 елдан башлап, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасына фәнни хезмәткәр-укытучы итеп билгеләнә, соңрак доцент, аннары профессор вазифаларына ирешә. Аның халык иҗаты өлкәсендәге эшчәнлегенең бер юнәлешен татар фольклоры курсын укыту тәшкил итә. Х. Бәдигый, беренчеләрдән булып, халык иҗаты буенча югары уку йортлары өчен программа төзи [Ярми, б. 63]. Аның фәнни казанышлары, беренчеләрдән булып, мәкальләр һәм табышмакларга классификация ясаудан гыйбарәт, ул аларны «Халык әдәбияты. Мәкальләр һәм табышмаклар» (1926) җыентыгында гамәлгә ашыра. 1912–1913 елларда дөнья күргән җыентыкларында әлеге жанрларның үрнәкләрен алфавит тәртибендә урнаштырган булса, монда ул аларны тематик төркемнәргә бүлә. Соңрак әлеге принципны Н. Исәнбәт куллана һәм мәкальләр, әйтемнәр, шулай ук табышмаклар буенча үзе төзегән җыентыкларда файдалана.

Шуны да әйтергә кирәк, татар фольклоры мәсьәләләре, аларны фәнни яктан өйрәнү белән, нигездә, халык иҗаты үрнәкләрен җыю һәм бастыру эшен башкарган галимнәр һәм язучылар шөгыльләнгән. 1926 елда «Безнең юл» журналында Г. Ибраһимовның «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы» дигән җитди мәкаләсе басыла. Әлеге мәкалә шул вакыттагы әдәбият белгечләре өчен кулланма, татар фольклористикасының үзенә күрә бер программасы да була. Анда Г. Ибраһимов халык иҗатының төп әһәмиятен, асыл мәгънәсен күрсәтә [Ибраһимов]. Бу мәкаләсендә автор халык иҗатын шул халыкның тарихы, аның иҗтимагый тормышы һәм социаль-сәяси процесслар белән бәйләп өйрәнү зарурлыгын күтәрә. Шулай ук фольклор әсәрләренең иҗтимагый аңның аерым һәм үзенчәлекле формасы, халык мәдәнияте, сәнгать, әдәбият һәм тел өлкәләренең

аерылгысыз, мөһим тармагы булып саналуы ассызыклана. Г. Ибраһимовның мондый карашлары, безнеңчә, XX гасырның 20 нче елларында татар әдәбият белемендә рус фәне һәм аның мәктәбе тәэсирендә барлыкка килгән культура-тарих мәктәбенә каравы белән аңлатыла [Галиева, б. 63]. Ул җитәкләгән Академүзәк вәкилләре, шулай ук әлеге фәнни оешма белән хезмәттәшлек иткән әдәбиятчылар һәм фольклорчылар (Г. Рәхим, Г. Газиз, Г. Толымбай, Х. Бәдигый, Ф. Туйкин, Ф. Сәйфи-Казанлы) үзләренең тикшеренүләрендә марксистик идеологиягә туры китереп, культура-тарих мәктәбе принципларына таяналар. Димәк, шул чордагы татар фольклористикасы билгеле бер дәрәҗәдә культура-тарих мәктәбе йогынтысында булган, дип әйтергә мөмкин. Чөнки Академүзәк үз тирәсенә, культура-тарих мәктәбе тарафдарларын һәм фәндә, әдәбият һәм фольклорны өйрәнүдә, җәмгыятьнең рухи тормышында культура-тарих үзенчәлекләренең үсешен исәпкә алган, язма әдәбиятта да һәм халык иҗатында да милли үзенчәлекләрне һәм алар арасындагы аерманы ачыклау принципларына актив таянган әйдәп баручы галимнәрне берләштергән. Ләкин фольклористика шома гына, каршылыксыз һәм көрәшсез генә үсмәгән. Ул хаталардан да азат булмаган (бигрәк тә идеологик һәм методологик характердагылардан). Аерым алганда, хөкем сөрүче иделогиянең исбат ителмичә нигез итеп алынган фикереннән чыгып, традицион һәм заман фольклорын сыйнфый көрәш яктылыгында өйрәнергә омтылыш була. Ягъни, сыйнфыйлык принцибын абсолютлаштыру, дини идеология белән сугарылган аерым жанрларны һәм әсәрләрне танымау һ.б. кебек фәндәге зыянлы тенденцияләргә һәм күренешләргә каршы көрәштә Г. Ибраһимовның алда әйтелгән чыгышы зур роль уйный, һәм татар фольклористикасын яңа дәрәҗәгә күтәрергә ярдәм итә.

1926 елда ук Татарстанның Академик үзәге тарафыннан бастырылып таратылган инструкцияләр җыентыгында әлеге өлкәдәге белгечләр Г. Рәхим һәм А. Васильев тарафыннан нәрсә ул фольклор дигән сорау куела [Васильев, Рахим, б. 24–25]. «Фольклор» терминын кертү һәм аның эчтәлеген ачыклау урынлы була. Әмма фольклорга шактый анык булмаган билгеләмә бирелә.

1927 елны «Безнең юл» журналында Г. Толымбайның «Татар фольклоры турында кайбер фикерләр» мәкаләсе басылып чыга. 1931 елда язучы А. Шамов билгеләгәнчә, халык әдәбиятын «фольклор» термины белән Г. Толымбай беренче булып атый [Шамов, б. 62]. Әлеге вакытка кадәр халык иҗаты «халык әдәбияты» яисә «халык мосаннәфәте» (гарәп термины) ярдәмендә билгеләнә [Ямалтдинов, б. 100–103].

1930 елда Г. Толымбай фольклорның кайбер характерлы якларын күрсәтә һәм нәтиҗә ясый. Шул ук вакытта иҗтимагый-сәяси вазгыять йогынтысында халык иҗатын артык идеологияләштерә һәм аны идеология өлкәсенең турыдан-туры бер тармагы итеп саный. Г. Толымбай татар фольклорының күләменә тукталып, башлап ышанулы (хорафат)

өлеше турында фикерләрен әйтә, аннан фольклорның икенче өлешен руслардагы кебек художестволы фольклор дип атарга тәкъдим итә [Тулумбайский, б. 54].

1930 елда Г. Рәхимнең «Авылны өйрәнү» кулланмасы басыла. Ул төзегән сораулыкларда «байларны талаулар булганмы?», «кеше атулар булганмы?», «авылда сәнәк сугышлары булганмы?» һ.б. шундый продразверстка, байларның малларын, йортларын һәм җирләрен тартып алу, коллективлаштыру чорына караган сораулар бар. Шуңа бәйле рәвештә, Г.Толымбай билгеләп үткәнчә, татар фольклорын җыю һәм өйрәнү өлкәсендә чит идеология хөкем сөрә, бу өлкә сыйнфый дошман кулында була. Алга таба Г. Толымбай вульгар социология рухында буржуаз карашлар бу өлкәгә нык тәэсир иттеләр дигән нәтиҗә ясый [Толымбай, б. 95].

Гомумән, Г. Толымбайны 1920–1930 елларда татар фольклористикасында актив тикшеренүчеләрнең берсе буларак танырга кирәк.

1930 еллар башында үзенең тикшеренүләрендә Г. Толымбай халык иҗатының этник структурасына игътибар итә. Ул «татар фольклоры» төшенчәсе астына, казан татарлары фольклорыннан тыш, татарларның башка этник төркекмнәрнең фольклоры да керүе турында нәтиҗә ясый һәм аларны чагыштыру зарурлыгы турында әйтә [Толымбай, б. 112].

Г. Толымбайның «Татарстан» журналында басылган «Мәдрәсә калдык-постыклары» мәкаләсендә татар халкы тарихында, шул исәптән фольклорны өйрәнүдә мәдрәсәнең роле мәсьәләсе куела. Мәдрәсә фольклорының үзенчәлекле булуы ассызыклана һәм анекдот, әкият, мәдрәсә театры, койрыклар кебек биш юнәлеш (тармак, жанр) мисалында карала. Мәдрәсәдә белем алган яшь шәкертләр, дини кагыйдәләрне өйрәнгәндә, тормышларын мәзәкләр, яшерен театр уйнау, догаларның ахырларын үзгәртеп, койрыклар өстәү, шуннан кызык табып, төрләндерергә тырышканнар. Г. Толымбай фикеренчә, мәдрәсә фольклоры – әлегә өйрәнелмәгән өлкә, шуның өчен фольклорның барлык жанрлары буенча материал җыярга һәм классификация ясарга кирәк. Шушы ук мәкаләсендә автор, совет идеологиясе йогынтысында, шәкертләр фольклорына сыйнфый позициядән якын килә, һәм мәдрәсәдә, нигездә, байлар, муллалар, сәүдәгәрләрнең балалары гына укыган, шуңа күрә шахтер җырларындагы кебек җырларда авыр хезмәт турында сүз юк, анда сөйгән ярлар, уңышка ирешү турындагы хыяллар һәм мәдрәсәне тәмамлаганнан соң танылулар турында сүз бара. Шул ук вакытта ул, реалистларча, бер үк җырны байлар да, ярлылар да җырлавын таный.

Фольклорның тематикасына килгәндә, Г.Толымбай билгеләгәнчә, һәр чорның үз үзенчәлеге бар: берсендә – мифология һәм ислам белән бәйле текстлар, икенчесендә – милли геройлар һәм көрәш, 1917 елдан соң – революция өчен көрәшүче геройлар һәм эшчеләр сыйныфы, һәм 1920–1930 елларда юлбашчылар, Кызыл Армия, колхозчылар турында җырлар өстенлек итә. Ул язганча, буржуаз галимнәр крестьяннар

фольклоры турындагы мәсьәләне генә куялар, соңрак эшчеләр фольклоры барлыкка килә [Толымбай, б. 113].

1934 елның июнендә Г. Толымбай Кызыл профессорлар институтында «Фатыйх Әмирхан иҗаты» темасына диссертация яклый. Хезмәттә татар әдәбияты классигы иҗатында фольклор элементларына да урын бирелә. М.М. (безнеңчә, язучы М. Максуд. – *И.Я.*) «Әдәбият фронтында беренче кызыл профессор» мәкаләсендә билгеләгәнчә, бу – татар әдәбиятында язучы иҗатының фольклор белән бәйләнешенә кагылган беренче диссертация.

1934 елда Әминә Халит үзенең бер мәкаләсендә бәетләрне тикшерү тәҗрибәсе белән уртаклаша. Аның фикеренчә, бәет эчтәлеге белән кыйммәтле, ул фактик материал нигезендә төзелә, сыйнфый көрәш тарихы буенча бай материал бирә. Бу очракта без объектка сыйнфый якын килү белән очрашабыз. Бәетләрдә фантазия һәм көчле лирик мотивлар булу, аларның вакыйгаларга таянып язылган җырны хәтерләтүләре, элек телдән әйтелүләре ассызыклана, русларның былиналарына тәңгәл килүләре хакында әйтелә һәм алар белән чагыштырыла [Халит, б. 56–59].

Шулай итеп, автор татар фольклористикасында беренчеләрдән булып бәетләргә фәнни характеристика бирергә тырыша, чагыштырма планда милли үзенчәлекләрне күрсәтә, татар фольклорындагы урынын билгели.

Ә. Халитова «Суга баткан ялчылар» бәете турындагы мәкаләсендә бәетләрне тикшерүен дәвам итә [Халитова, б. 116–119]. Бәетне анализлый башлаганчы, ул, тулырак күзаллау өчен, сыйнфый мөнәсәбәт, Тархан авылы (Казан губернасы, Тәтеш өязе, 1899) икътисадына туктала. Соңыннан бәеткә тарихи-типологик анализ ясый һәм мәкаләнең ахырында бәет текстын урнаштыра.

Г. Толымбайның «Бәетләр» (1935) китабында *бәет* сүзенең этимологиясе турында сүз бара, аның борынгыдан кулланылуы ассызыклана [Урманчеев, б. 3].

1939 елда Г. Сәгъдинең «Әдәбият теориясе» китабы басылып чыга. 137–151 битләрдә татар фольклоры жанрлары карала. Китапның 1941 елда чыккан тулыландырылган басмасында җиденче бүлек фольклорга багышлана, анда аңа билгеләмә бирелә, жанрлар һәм аларның үзенчәлекләре ачыклана. Фольклор халык күңелендә сакланган, телдән-телгә, буыннан-буынга, бер чордан икенче чорга тапшырылып барган язма булмаган әдәбият буларак билгеләнә. Фольклорның һәм әдәби әсәрләрнең аермалы яклары күрсәтелә.

Шул ук елны Н. Исәнбәтнең күләмле «Татар табышмаклары һәм аларны тикшерү» мәкаләсе басыла. Әлеге мәкаләдә табышмакларга билгеләмә бирелә, аларның функцияләре, язма әдәбият белән бер-берсенә тәэсир итешүе, фольклорның башка жанрлары белән бәйләнеше, халыклар арасында күчүчәнлеге, үзенчәлекләре, җыю һәм өйрәнү тарихы, яңа заман табышмакларының барлыкка килү юллары кебек мәсьәләләр тикшерелә. Н. Исәнбәтнең

татар табышмакларын тикшерү буенча фәнни мәкаләсе алга таба зур адым була.

Халык авыз иҗатын җыю, бастыру һәм өйрәнү эшендә татар язучылары да катнаша. 1930 елларда ТАССР Язучылар берлеге (1934) каршында фольклор секциясе оештырыла. Татарстанның язучылар берлеге фольклор экспедицияләре оештыра, төрле җыентыклар әзерләп бастыра. Аларның керешләрендә, вакытлы мат бугатта чыккан мәкаләләрдәфольклорны өйрәнү буенча фәнни тикшеренүләр үткәрелә. Милли фольклорны тикшерү һәм иң яхшы үрнәкләрен бастыру буенча ТАССР Язучылар берлегенең «Совет әдәбияты» журналы редакциясе җитди эш башкара [Ямалтдинов, б. 32].

Шулай итеп, 1920 еллар башыннан алып 1930 еллар уртасына кадәр татар фольклорын җыю һәм бастыру, пропагандалау һәм популярлаштыру, фәнни өйрәнү мәсьәләләре белән Академүзәктә эшләүче тикшеренүчеләр һәм алар белән тыгыз хезмәттәшлек иткән галимнәр һәм язучылар шөгыльләнә. Совет язучыларының Беренче съездыннан соң бу изге эшкә ТАССР Язучылар берлеге дә кушыла. Татар халык иҗаты үрнәкләре фәнни-популяр хезмәтләргә, дәреслекләргә, махсус җыентыкларга кертелеп, интенсив рәвештә һәм шактый зур тиражлар белән нәшер ителә. Фольклорны популярлаштыру газета һәм журналлар аша да бара.

Гомумән, 1920–1930 еллар башы татар фольклористикасы өчен шактый нәтиҗәле чор була. ТАССР төзелү татар фольклористикасы үсешенә зур йогынты ясый. Бу чорда халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыю, системалаштыру, бастыру дәүләт оешмасы планына кертелеп, системалы рәвештә алып барыла башлый. Бу чорда халык иҗатын фәнни яктан өйрәнү өлкәсендә катлаулы теоретик мәсьәләләр куела һәм кыю рәвештә хәл ителә.

Алга таба татар халык авыз иҗатын җыю, бастыру һәм фәнни яктан тикшерү өлкәләрендәге эшчәнлек 1939 елны Казанда ТАССР Халык комиссарлары советы каршында оештырылган Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты (хәзерге ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) тарафыннан аерым фәнни юнәлеш буларак планлы һәм системалы рәвештә дәвам иттерелә.

**Әдәбият**

*Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008.

*Васильев А., Рахим Г.* Руководство для собирания фольклора и народной литературы. Казань, 1926.

*Галиева Э.Р.* Культурно-историческая школа в татарском литературоведении 1920–1930-х годов: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2003. 63 с.

*Ибрагимов Г.* Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы // Безнең юл. 1926. № 5/6.

*Исәнбәт Н.* Татар табышмаклары һәм аларны тикшерү // Совет әдәбияты. 1939. № 10/11. Б. 162–176.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003.

*М.М.* Әдәбият фронтында беренче кызыл профессор // Совет әдәбияты. 1934. № 6. Хроника.

*Сәгъди Г.* Әдәбият теориясе. Казан: Татгосиздат, 1939. Б. 142.

*Толымбай Г.* Татар фольклоры фронтында // Совет әдәбияты. 1933. № 4/5. Б. 113.

*Толымбай Г.* Татар фольклоры фронтында // Совет әдәбияты. 1933. № 8/9. Б. 94–95.

*Тулумбай Г.* Мәдрәсә калдык-постыклары // Татарстан. 1930. № 4. Б. 15–23.

*Тулумбайский Г.* Татар фольклоры // Татарстан. 1930. № 6/7. Б. 58.

*Урманчеев Ф.И*. Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002.

*Урманчеев Ф.* Халык авазы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

*Фирсов Н.* Казань в легендах // Красная Татария. 1926. 21 марта.

*Халит Әминә.* Бәетләр тикшерү тәҗрибәсеннән // Совет әдәбияты. 1934. № 6. Б. 56–59.

*Халитова Әминә.* «Суга баткан ялчылар» бәете турында // Совет әдәбияты. 1935. № 4/5. Б. 116–119.

*Шамов А*. Фольклор мәсьәләләре // Яңалиф. 1931. № 7. Б. 62.

*Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. 184 с. (Серия «Библиотека журнала «Фәнни Татарстан»; 8-я книга).

*Ямалтдинов И.И.* «Фольклор» терминын фәнни әйләнешкә кертү тарихыннан // Фәнни Татарстан. 2018. № 1. С. 100–103.

*Ярми Х.* Татар фольклористика фәненең күренекле галиме // Совет әдәбияты. 1957. № 12. Б. 63.

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы****,*
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*

УДК 75

***О.Л. Улемнова***

# 1920–1930 ЕЛЛАРДА ТАССРНЫҢ ТАТАР РӘССАМНАРЫ

Статья посвящена первым татарским художникам, получавшим профессиональное образование в 1920-е годы в специализированных художественных учебных заведениях Казани, Москвы и Ленинграда. Рассматривается их вклад в развитие татарского национального изобразительного искусства начального этапа советского периода – живописи, книжной и газетно-журнальной графики, театрально-декорационного искусства. В статье обобщаются сведения об известных татарских художниках, вводятся в научный оборот новые имена татарских художников 1920-х годов на основе архивных данных.

**Ключевые слова:** изобразительное искусство, живопись, графика, скульптура, театрально-декорационное искусство, художественное образование.

The article is devoted to the first Tatar artists who received professional education in the 1920s in specialized art educational institutions of Kazan, Moscow and Leningrad. Their contribution to the development of the Tatar national fine art of the initial stage of the Soviet period – painting, book and newspaper and magazine graphics, theatrical and decorative art – is considered. The article summarizes information about famous Tatar artists, introduces into scientific circulation new names of Tatar artists of the 1920s on the basis of archival data.

**Keywords:** art, painting, graphics, sculpture, theatrical decoration art, art education.

1917 елгы Октябрь революциясенең нәтиҗәсе буларак, 1920 елда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы (ТАССР) төзелү татар сәнгати мәдәниятен үстерүгә көчле этәргеч бирә. Башка мөселман халыкларыннан аермалы буларак, Казан татарларының сәнгате күп гасырлар дәвамында дини чикләүләр – кеше һәм хайван сурәтләрен катгый тыю шартларында үсә. Татар халкының сәнгать потенциалы декоратив-гамәли сәнгать һәм каллиграфия кысаларында үсеш ала.

Татар тасвирый сәнгатенең чишмә башы революциягә кадәрге чорга барып тоташа. Бу заманда исламны яңартуга һәм аны Европа, рус мәдәниятләре белән якынайтуга юнәлтелгән җәдитчелек хәрәкәте татарлар арасыннан беренче рәссамнар туугa булышлык итә. Аларның күбесе үзлегеннән өйрәнгән рәссамнар була. Кайберәүләр генә махсус белем алуга ирешә. Мәсәлән, Ш.Ә. Таһиров 1883 елда Император сәнгать академиясе таныклыгын алып, түбән уку йортларында рәсем укыту хокукы ала [Шакирджан Тагиров..., с. 14], М. Байкиев Петербургта барон А.Л. Штиглицның Үзәк техник рәсем училищесында 7 ел укый [Кривошеева, с. 69], К. Дәүләткилдиев Петербургта барон А.Л. Штиглицның Үзәк техник рәсем училищесын 1914 елда тәмамлый [Художники народов..., с. 307]. Россиянең махсуслаштырылган сәнгать уку

йортларында мөселманнар Алла канунын (Закон божий) тапшыру мәҗбүри итеп куелганга күрә дә, һөнәри белем алу мөмкинлегеннән мәхрүм ителәләр. Чөнки чын күңелдән дин тоткан кеше бу адымга беркайчан да бармый. Мәсәлән, нәкъ менә шул сәбәпле Б.И. Урманче 1913 елда Казан сәнгать мәктәбенә үтми [Новицкий, с. 17], С. Яхшыбаев 1912 елда, барлык имтиханнарны тапшырып та, «вакантлы урыннар булмау» аркасында мәктәпкә кабул ителми [Новицкий, с. 17].

1918 елның 23 гыйнварында (5 февраль) РСФСР ХКС декреты чиркәүнең дәүләттән аерылуын, дин ирегең игълан итә, барлык дәүләт һәм җәмәгать, шулай ук гомуми белем бирү предметлары укытыла торган шәхси уку йортларында дини белем бирү тыела. Әлеге кардиналь үзгәрешләр рәсем сәнгатенә кагылышлы өлкәләрдә үз җимешләрен тиз генә бирми. 1920 елларның беренче яртысында ТАССРда татар рәссамнары бик аз була, шул ук вакытта яшь республика аларга бик зур ихтыяҗ кичерә. Рәссамнар агитация-масса эшенә, яңа дәүләт символларын булдыруга, яңа милли газета һәм журналларны бизәүгә, китап нәшриятларында, театрларда, мәктәпләрдә эшләүгә җәлеп ителә.

Бакый Идрис улы Урманчены (1897–1990) без хаклы рәвештә татар рәсем сәнгатенә нигез салучы дип атыйбыз. Ул башлангыч дәвердә дә, XX гасырның икенче яртысында да татар нәкышен, графика һәм скульптурасын үстерүгә үзеннән бәяләп бетергесез өлеш кертә [Баки Урманче..., 2017]. 1920 елда ул ТАССРның беренче гербының (1922 елга кадәр кулланышта) авторы була. Эшчеләр һәм крестьяннарның какшамас бердәмлеген гәүдәләндергән гербны ясаганда һәм хезмәт ияләре колоннасының бәйрәмчә бизәлешен әзерләгәндә рәссамның эшенә Үзәк хәрби мөселман коллегиясенең сәяси бүлеге башлыгы Ш. Усманов җитәкчелек итә (Б. Урманче шул коллегиянең сәнгать бүлегендә хезмәт куйган) [Султанова, с. 19]. 1919 елның кышында Б. Урманче Казан ирекле дәүләт сәнгать остаханәләренә (элеккеге КСМ)[1] укырга керә һәм параллель рәвештә

[1] 1918 елдан башлап Казан сәнгать мәктәбе (КСМ) берничә тапкыр үзгәртеп корыла һәм башкача исемләнә:

1918, ноябрь – 1920, июль – Казан ирекле дәүләт сәнгать (укыту-сәнгать) остаханәләре (КАСГХУМ);

1920, июль – 1921 – Казан югары дәүләт сәнгать-техника (сәнгати-технологик) остаханәләре (КАХУТЕМАС);

1.01.1922–10.07.1923 – Казан сәнгать-техника (сәнгати-технологик) институты (КАХУТЕИН);

10.07.1923 – 31.12.1925 – Казан Дәүләт Архитектура-сәнгать остаханәләре (АРХУМАС). РСФСР ХКС тарафыннан кабул ителгән Кахутеинны Казан Сәнгать техникумы итеп үзгәртү турындагы карар 1926 елның башында гына гамәлгә ашырыла;

1.01.1926–1927 – Казан сәнгать-педагогика техникумы (Казан сәнгать техникумы) (КХПТ);

1927–1930 – Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы (КОХТТ);

1930–1935 – Татар сәнгать техникумы (Татарский художественный техникум) (ТХИ);

1935 елдан – Казан сәнгать училищесы (КХУ). Текстта без мәктәпнең һәр чорга туры килгән атамасын кулланачакбыз.

ул анда да белем эсти. Биредә аның педагоглары – Казанның әйдәп баручы рәссамнары: рәссам В.К. Тимофеев, скульптор Г.А. Козлов, график Н.С. Шикалов. 1920 елның көзендә Б. Урманче үзенең сәнгати белем алуын Мәскәүдә Югары сәнгать-техника остаханәләрендә (ВХУТЕМАС) дәвам итә, А.В. Шевченко, С.В. Герасимов, Б.Д. Королев, А.Д. Древин, Д.А. Щербиновский, Н.А. Шевердяев һ.б. кебек нәкыш, графика һәм скульптура осталарының һөнәри серләренә төшенә.

1930 елларда Б. Урманче Мәскәүдә яши һәм татар матбугатында – «Коммунист» газетасында (1933), «Сугышчан алласыз» журналында актив эшли, бу басмаларда аның карикатуралары һәм заманча темаларга ясаган рәсемнәре басыла. 1930 еллар азагында Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә Башкортстан АССР, Карелия-Фин АССР, «Терлекчелек» һәм «Механизация» павильоннарын бизәү (монументаль бизәк һәм барельеф фризлары) өстендә эшли [Хисамова, с. 466]. 1939–1940 елларда Татар филармониясе өчен татар милли киемнәре эскизларын әзерли. 1941 елдан Казакъстанда, 1956 елдан Ташкентта яши, әлеге республикаларның милли сәнгатен һәм сәнгати мәгарифен үстерүгә күп көч куя. 1958 елда ул Казанга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр татар сәнгати мәдәниятенең рәсми булмаган лидеры була. Европа мәдәнияте казанышларына нигезләнсә дә, Б. Урманче һәрвакыт тирән милли хисле рәссам булып кала. Аның өчен милли төшенчә сюжет һәм тема сайлау белән генә чикләнми. Ул нәкыштә, графикада, скульптурада файдаланылган ысул, алымнарны татар сәнгатенең төрле төрләре (декоратив-гамәли, каллиграфия, агач архитектура) өчен уртак итәргә омтыла, әсәр структурасына традицион формалашу принципларын, колорит, ритм, көй өсти. Болар милли рух дип атала [Баки Урманче..., 2012, с. 10]. Б. Урманче тормышында Казан чоры җитлегү һәм аеруча актив иҗат дәвере була: оста күпсанлы нәкыш, скульптура, графика әсәрләре тудыра, аларда борынгы татар тарихы вакыйгалары, милли мәдәниятнең күренекле эшлеклеләре образлары, туган як пейзажлары, татар фольклоры образлары чагылыш таба.

1922 елда Казанга килгән Арсланов Госман Вәли улы (1897–1941) ТАССРның беренче ун елында татар графикасын үстерүдә зур роль уйный. Ул сәнгать белеменең нигезләрен Пермь сәнгать-сәнәгать остаханәләрендә үзләштерә. 1920 еллар башында татар матбугатында, татар театрында, татар плакатында Г. Арсланов иҗаты аеруча зур урын алып тора. Аның сәяси һәм социаль темаларга язылган сатирик рәсемнәре күп кенә татар газета-журналлары битләрендә басылып чыга: «Кызыл яшьләр», «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре», «Шобага, «Шаян кыллар», «Кызыл Татарстан» һ.б. 1923–1928 елларда ул «Чаян» журналының бөтен номерларын да бизәүче бердәнбер рәссам була. Милли үзенчәлекне тирәнтен белүе, образларның гротеск рәвештә бирелүе, үзенчәлекле сыйфатларны ассызыклап күрсәтә белүе аның һөнәри әзерлеге җитенкерәмәвен каплый.

Казан нәшриятларының китапларын бизәп, Г. Арсланов татар китабы сәнгатенә дә үзеннән зур өлеш кертә. Алар арасында иң уңышлысы – «Безнең матбугат» китабы (Казан: Татар. Ленин комсомолы матбугат бүлеге, 1925). Аның тышлыгы декоратив рәвештә эшләнгән: ак һәм кызыл вертикаль полосаларның кырыс ритмын чагыштыруга корылган, каймалы ак картуш белән аерып күрсәтелгән исеме гарәп хәрефләре белән бормалап язылган. Татар иллюстратив графикасы үсешенә Г. Арсланов Г. Тукай шигырьләренә һәм поэмаларына иллюстрацияләр сериясен (тушь белән ясалган 43 рәсем) язып, татар иллюстратив графикасы үсешенә үзеннән зур өлеш кертә. Алар 1926 елда Казанда «Гажур» нәшрияты тарафыннан чыгарылган Г. Тукай әсәрләре җыентыгында басыла [Улемнова, 2016, с. 266–267]. Г. Арслановның образлары тирән психологизм белән сугарылалар һәм хиссиятле булулары белән аерылып торалар. Бу Г. Тукай шигъриятен интерпретацияләүдә яңа адым була.

Фаик Шакирҗан улы Таһиров (1906–1978) авангард сәнгате вәкиле буларак танылды. Аның китап бизәү һәм плакат язу өлкәсендәге эшләре бүген Татарстан сәнгатенең классик үрнәкләре булып тора. Ул Казан сәнгать-техника институтында (1922–1925), аннары ВХУТЕМАС/ВХУТЕИНда (1925–1929) белем ала. Ул Казанда татар китапларының бизәлешен эшләү белән 1924 елда шөгыльләнә башлый. 1925 елда Парижда үткәрелгән заманча декоратив һәм сәнәгый сәнгать халыкара күргәзмәсендә Г. Кутуйның СУЛФ остаханәсе тарафыннан нәшер ителгән «Көннәр йөгергәндә» китабы (рәссамы Ф. Таһиров) күрсәтелә. Ф. Таһиров үзе дә Сул фронт лидерларының берсе санала [Улемнова, 2017, с. 138]. Беренче эшләрендә үк Ф. Таһиров үзен җитлеккән рәссам буларак күрсәтә: Европа мәдәниятенең авангард эзләнүләрен татарларның традицион гарәп графикалы борынгы милли чыганаклары белән органик рәвештә тоташтырган конструктивизмның үзенә бертөрле көнчыгыш вариантын тәкъдим иткән үзенчәлекле стилен булдыра. Ф. Таһиров гарәп шрифтын камилләштерә, аңа геометрик төгәллек һәм ачыклык бирә. Еш кына ул иң борынгы саналган куфи язуына таяна. Бу язуның квадрат, почмаклы, җитди формалары конструктивизмдагы гадилек, ачыклык, функциональлек һәм демократлык кебек сыйфатларга бик тә туры килә. Ф. Таһиров тышлыкларны эшләгәндә көнчыгыш китабы өчен традицион симметрияле композицияне дә, конструктивизм яраткан асимметриялекне дә файдалана. Аның эшләрендә төп композицион һәм мәгънәви йөкләнеш гарәп язулы юлларны тиңдәш ияртүгә, ритмик чагыштырмаларны ачыклауга китерә, ә өстәмә элементлар, декоратив вазифа башкарудан бигрәк, эчтәлегенә карап, тышлык конструкциясен ассызыклыйлар һәм көчәйтәләр, логик төзелешен ачыклап, аңа динамика яки статика бирәләр. Ф. Таһиров конструктивизм сәнгати теленең мөһим өлешен тәшкил иткән фотомонтаждан актив файдалана.

Мәскәүгә килгәч, Ф. Таһиров башкаладагы «Нәшрият» татар нәшрияты, «СССР халыклары нәшрияты»ның татар секциясе белән

хезмәттәшлек итә башлый. Алар өчен үзенең сәнгати чаралар арсеналын акцидент җыелма белән тулыландырып, берничә китап бизи. Моннан тыш, ул Мәскәүдә татарча чыккан «Эшче», «Игенчеләр» газеталарында, «Кечкенә иптәшләр» журналында рәссам булып эшли, бизәлештә фотомонтажны актив куллана. Татар теленең латин язуына күчүен энтузиазм белән каршылый, Казан нәшриятлары, шул исәптән «Яңалиф» нәшрияты белән дә хезмәттәшлеген дәвам итә: сеңлесе Суфия Таһирова белән бергә «Безнен алфавит» дигән буяусыз рәсемле әлифба чыгара (Казан, 1929), «Яналиф» журналын һәм латин язуын пропагандалаучы «Укый беләсеңме?» дигән плакатның эскизын эшли (Казань, 1929).

1930 елларда сәнгатьтә экспериментлар үткәрү актуальлеген югалткач, Ф. Таһиров, үзенең сәнгать кредосын үзгәртмичә, сәнгатьне, фәнне һәм җитештерүне тоташтыручы өлкәгә күчә һәм шрифтлар әзерләү белән шөгыльләнә башлый. Үз иҗатында конструктивизмның «рәссам – җитештерә!» дигән төп күрсәтмәсен тулысынча гамәлгә ашыра. РСФСР ОГИЗның Фәнни-тикшеренү полиграфия һәм нәшрият техникасы институты (сугыштан соң – Полиграфия машина төзелеше фәнни-тикшеренү институтының яңа шрифтлар бүлеге) каршындагы Ф. Таһиров җитәкләгән шрифт лабораториясендә СССР халыклары телләре өчен дистәләгән яңа шрифтлар эшләнә, бу безнең илгә 1930 елларда чит ил җитештерүләренә бәйлелектән котылырга мөмкинлек бирә. 1950–1960 елларда Ф. Таһиров Шәрык халыклары (уйгур, корея, һинди (бхилаи), пәнҗаби (гурмукхи)) һ.б. телләр өчен типография шрифтлары эшли [НА ГМИИ РТ..., л. 42–44].

Ф. Таһировтан соң Казанда тагын бер талантлы яшь рәссам – керәшен татары Дмитрий Красильников (1903–1951) пәйда була. Ул Пермь сәнгать остаханәләрендә укый (1922–1923) һәм укуын Казан архитектура-сәнгать остаханәләрендә (1924–1928) дәвам итә, ә 1933 елда Мәскәү полиграфия институтының графика-нәшрият факультетын тәмамлый. 1920 еллар уртасында Д. Красильниковның күп кенә рәсемнәре «Кызыл яшьләр», «Кызыл Татарстан», «Азат хатын», «Авыл яшьләре», «Безнең юл», «Чаян» кебек татар газета-журналларында басыла. Аның рәсемнәре жанр характерында булып, реалистик яктан ышанычлы, үткен күзәтүчәнлек белән һәм халык тормышын белеп язылган. Аларны дөрес линияләр, график фактура һәм үзенчәлекле лирикага ия булу да аерып тора. Ул татар, рус һәм чит ил язучыларының (Максим Горький, Хәсән Туфан, Габдулла Ильяс, Джек Лондон һ.б.) портретларын иҗат итә, алар татар журналлары битләрендә һәм тышлыкларында, китапларда басылып чыга. Шулай итеп, Д. Красильников татар рәссамнары арасында тәүге профессиональ портретчыларның берсе була.

1928 елда Мәскәүгә күчеп килгәч, Д. Красильников Казан нәшриятлары белән актив хезмәттәшлек итә, ә 1930 еллар башында Мәскәүдә татар телендә чыгучы яңа «Ударниклар», «Октябрь баласы» журналлары, «Коммунист» газеталарының әйдәп баручы рәссамына

әйләнә. Әлеге вакытлы матбугат органнарында ул Муса Җәлил белән бергә эшли. Биредә рәссам үзен әдәби текстларның нечкә зәвыклы иллюстраторы һәм талантлы сәяси карикатура остасы буларак күрсәтә. Сугыш елларында һәм сугыштан соңгы елларда Д. Красильников башта «Раздавим фашистскую гадину!» дигән хәрби газетада эшләп, аннан соң шуның нигезендә оештырылган «Вожык» сатирик журналының сәнгать бүлеге мөдире вазифаларын башкарып, Белоруссия сатирик графикасы үсешенә үзеннән зур өлеш кертә [Дмитрий Красильников..., с. 10].

Революция чорында профессиональ сәнгать юлына тагын бер кызыклы рәссам Җәгъфәр Гыйззәт улы Булат (1903–1981) аяк баса. 1919–1921 елларда ул Казан, Мәскәү, Ташкәнт Кызыл Армия театрлары декораторы булып эшли. Рәссам һөнәрен ул КСГХМда (1919–1920) һәм КХПТда (1924–1927) үзләштерә. Соңыннан ул КХУда укыта (1937–1939, 1949–1957). Д. Булат, революция, гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы темаларына берничә буяулы һәм график композиция төзеп, баталия жанрында иҗат иткән тәүге татар рәссамнарының берсе була. Бу эшләрендә ул үзенең шәхси тәэсирләрен дә чагылдыра [Могильникова, с. 482].

1920–1925 елларда Казанда махсус сәнгать уку йорты – югары уку йорты статусына ия булган Казан сәнгать мәктәбе булуга карамастан, бу чорда анда татар балалары аз укый, ә 1928 елга кадәр тулы курсны тәмамлаучылар арасында татарлар бөтенләй булмый [ГАДЛС, ф. 701 (2812), оп. 3л, ед. хр. 96, л. 114]. 1920 еллар уртасында вазгыять үзгәрә башлый. Бу бигрәк тә 1926 елда ВХУТЕМАСны тәмамлап Казанга кайткан Б. Урманче КХПТның уку-укыту бүлегенә мөдир булып килгәч сизелә.

Зур административ һәм укытучылык эше күп вакыт һәм игътибар таләп итүгә карамастан, 1926–1929 елларны үз эченә алган Казан чорында Б. Урманче башы-аягы белән иҗат эшенә дә чума. Рәссам татар нәкыше классикасына әверелгән «Сепарат янында» (1928), «Җилкәнле көймәдә» (1929) һәм башка картиналар яза. Аның каләм һәм тушь белән ясалган, «Укырга килдек» рәсемнәрендә, «Казан типлары» сериясендә замандашларының кыяфәтен чагылдырган эшләре «Безнең юл» журналы битләрендә репродукцияләнә [Баки Урманче..., 2017, с. 459, 460]. Ул К. Тинчуринның «Ил» драмасына (1928) декорацияләр һәм костюмнарның эскизларын эшли, үзен скульптурада сынап карый – балчыктан, бизәк төшереп, «Чиләк тоткан татар кызы» статуэткасын ясый. 1929 елда Б. Урманченың Казандагы иҗади, педагогик һәм иҗтимагый эшчәнлеге көчләп туктатыла: ул 58-11 маддә буенча кулга алына һәм 5 елга ирегеннән мәхрүм ителә (1990 елда реабилитацияләнә) [Баки Урманче..., 2017, с. 129].

Б. Урманче КХПТда эшләгән елларында (1926–1929) талантлы татар яшьләрен сәнгати белем алуга җәлеп итүне иң төп бурычларының берсе дип саный. 1926 елда ул тулы бер реклама кампаниясе оештыра: татар газеталарына һәм журналларына, «Безнең юл»

журналында (1926, № 9) сәнгать телхникумы турында мәкалә урнаштыра [Урманче, 2017, с. 96]. Б. Урманченың актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 1920 елларның икенче яртысында КХПТда татар студентларының саны артканнан-арта бара. Яшьләр ТАССР районнарыннан гына түгел, башка төбәкләрдән дә – Ижау, Оренбург, Самара, Сарапул, Свердловск, Уфа, Чиләбе шәһәрләреннән, өлкә һәм республикалардан да (Казакъстан, Кыргызстан) киләләр.

Мәсәлән, Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы стипендиатларының 1928 елның 1декабренә бирелгән исемлегендә [ГАДЛС, ф. 701 (2812), оп. 3л, ед. хр. 96, л. 55, 55об., 56] 52 кешенең 24 е татар милләтеннән (исемлектә укучының кайдан килүе дә күрсәтелгән):

Абдуллин Мортаза. Башреспублика,
Алмаев Хәмбәй. Оренбург,
Алтынбаев Әхмәт. Уфа,
Арасланов Нури. Күкчетау,
Баһаветдинов Хаб[ибулла]. Сталинград,
Богданов [Әхәт]. Сызрань,
Брондуков [Солтан]. Казакъстан,
Газизова Мөнәвәрә. Ижау,
Галиева Мәүлүдә. АТССР,
Давыдов Исмәгыйль. АТССР,
Дусалинов Заһинур. Башреспублика,
Зайләев Рәфкать. Сарапул,
Кәримов Мөхәммәтша. Свердловск,
Мансуров Газиз. Сарапул,
Мәрдиева Хәдичә. АТССР,
Мусин Госман. АТССР,
Мөхәммәтҗанов Шакир. Кирг.өлкәсе,
Мөхәммәтшин Зәки. Чиләбе,
Рахманколов Морат. Стәрлетамак,
Рәхмаәтуллин Мөкатдәс. Стәрлетамак,
Садыйков Агләм. Башреспублика,
Сутюшев Мәкъмун. Петропавловск,
Урманчиев Каюм. Верхнеудинск,
Йосыпов Гата. Самара.

Бу студентларның күбесе соңыннан театрда, китап бастыруда, вакытлы матбугатта, киноиндустриядә эшләүче рәссамнар буларак танылу ала. Б. Урманче язганча, «Казан сәнгать техникумы татар рәссамнарының беренче буыны иҗат өлкәсендә гаять продуктив һәм күпкырлы талантка ия булып чыкты. Алар татар рәсем сәнгатен илнең төрле почмакларына беренчеләрдән булып китереп тараттылар» [Урманче, 1985, с. 71].

Абдуллин Мортаза Мостафа улы (1910–1946) 1930 елда ТТИны тәмамлап, Ленинград рәсем сәнгате, скульптура һәм архитектура институтында, театр декорациясе остаханәсендә һөнәри белем алуын

дәвам иттерә (1933 елга кадәр). Казанга кайткач, Татар дәүләт академия театрында (1933–1939) һәм Татар дәүләт опера һәм балет театрында (1939–1941) милли драматургия буенча спектакльләр бизәү өстендә эшли. Сугышка кадәрге чорда татар сценографиясен үстерүгә, шулай ук Казан сәнгать мәктәбендә укытып, милли нәкышчеләр һәм сәхнә рәссамнары тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә. Ул «театр сәнгате телендә милли мәдәниятнең мөһим сыйфатларын чагылдыра алган һәм татар этник аңының төрле чикләрен, кыйммәтләрен, образлы структураларын, халыкның эстетик идеалларын күрсәтә алган беренче профессиональ татар сценографы» була [Султанова, с. 186].

Сутюшев Мәкъмун Гали улы (1906–1990) Казанда күренекле театр рәссамы, ТАССРның (1957) һәм РСФСРның (1977) атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы (1970) була. Аңарда «сценограф һәм станокчы рәссам бик яхшы яраша» [Султанова, с. 268]. 1930 елда ТТИны тәмамлаганнан соң, ул татар телендә чыгучы «Атака» журналы белән хезмәттәшлек итә һәм шунда ук үзен театр сәнгате белән бәйли, башта Татар эшче (күчмә) театрында, 1939 елдан башлап 1976 да лаеклы ялга чыкканчы ТДАТта эшли. Татарларның традицион тормыш рәвешен һәм укладын биргәндә, матур задникларда туган якның табигатен сурәтләгәндә милли үзенчәлекләрне оста гәүдәләндерә [Султанова, с. 271].

КХПТга яшьләр генә түгел, үз вакытында һөнәри белем алу мөмкинлеге булмаган өлкән буын кешеләре дә укырга килгән. Әйтик, татар театрының беренче рәссамы (революциягә кадәрге елларда татар театр-декорация сәнгатенең тууы нәкъ менә аның исеме белән бәйле) Яхшыбаев Сабит Габделбасыйр улы (1890–1930) [Султанова, с. 561] 1925–1926 елларда КХПТның төп остаханәсендә белем ала [ГА РТ, ф. Р-1431, оп. 1, ед. хр. 106, л. 68].

Казан сәнгать техникумын тәмамлаган татарларның күбесе милли китап чыгаруда һәм милли матбугатта эшли. Республиканың полиграфия производствосы өчен рәссамнар әзерләү максатында 1928 елда КОХТТның графика бүлеге торгызыла һәм тизләтелгән (еллык) укыту курсы оештырыла. Анда зур практик эш тәҗрибәсе булган белгечләр: ксилограф Ф.С. Быков, полиграфия теориясе буенча белгеч Я.Г. Мейтин, сәнгать белгече һәм рәссам-график П.М. Дульский, литограф С.М. Ефимов була. Интенсив белем бирү нәтиҗәләре йомгаклау күргәзмәсендә күрсәтелә һәм каталогта теркәлә [Дульский].

Әлеге графика бүлеген Х. Алмаев, Ш. Мөхәммәтҗанов, Г. Йосыпов тәмамлый [ГАДЛС, ф. 701 (2812), оп. 3л, ед. хр. 114, л. 3, 4]. Бу чыгарылышта Шакир Нигъмәт улы Мөхәммәтҗанов (1900–1972) арада иң көчле һәм мөстәкыйль оста буларак аерылып тора. Ул конкурс эше сыйфатында Б. Доминовның «Рәсем төшерергә өйрән» дигән китабының тышлыгын эшли. Анда кыска, тәэсирле рәсем һәм китап исеменең кырыс шрифты уңышлы яраша. КОХТТны тәмамланганнан соң, Ш. Мөхәммәтҗанов «Чаян» (1929 елдан), «Атака»

(1930) журналларында актив эшли, ә 1931 елда Татгосиздатка штатлы рәссам булып килә, 1930 елларның беренче яртысында күпчелек китапларның бизәлешен башкара (шул ук вакытта аның исеме китап чыгаруга караган мәгълүматларда күпчелек очракта телгә дә алынмый, ә килешү нигезендә эшләүче рәссамнар, авторлыкны күрсәтү юридик яктан беркетелү сәбәпле, мәҗбүри күрсәтелә) [Лобашева, с. 16]. Ш. Мөхәммәтҗанов, 1960 елда пенсиягә чыкканчы, Татарстан китап нәшриятында эшли, 1930 елда оештырылган графика бюросын җитәкли, аннан соң нәшриятның художество редакторы була, китап рәссамнарының яңа буынын тәрбияли. Ул татар китабын сәнгати бизәү үсешенә генә түгел, техник процессларга рационализаторлык тәкъдимнәре кертеп, полиграфия производствосын камилләштерүдә дә катнаша [Лобашева, с. 18].

1929 елда графика бүлеген тәмамлаучыларның башкалары да башта Казанның, аннары илнең башка шәһәрләренең профессиональ графиклары булып танылалар. Гата Йосыпов (1908–1941) «Чаян» сатирик журналында эшли. Ул журналның 1929 елгы саннары өчен хикәяләргә каләм һәм тушь белән рәсемнәр ясаган. Алар йомшак юмор, нәфис детальләр, тәэсирле линия, график алымнарга байлыгы белән аерылып тора. 1932 елда Г. Йосыпов Мәскәүдә татарча чыгып килүче «Коммунист» газетасында иллюстратор булып эшли, анда аның социаль һәм халыкара сәяси темаларга карикатуралары, чит ил сәясәтчеләренә шаржлары, җитештерү алдынгыларының портрет-зарисовкалары һ.б. бастырыла. Аннан соң ул туган ягына – Самарага (Куйбышев) әйләнеп кайта.

Графика бүлеге конкурсына «Чаян» журналының реклама плакатын [Дмитрий Красильников..., с. 12] тәкъдим иткән Алмаев Хәмбәй Әхмәт улы (1907–?) 1930 еллар ахырында «Татхудожник»ның бизәү цехында эшли. Аннары Сәмәркандка китә, анда аны 1950 елда Б. Урманче каршы ала [Урманче, 2017, с. 98].

Кәримов Мөхәммәтша Зариф улы (1910–1990), ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1982), 1930 елда Казан сәнгать техникумын тәмамлаганнан соң, мөстәкыйль иҗат юлын рәссам-график буларак башлый. Агачта гравюралар техникасында ул берничә портрет ясаган. Шулар арасында иң яхшылары – В.И. Ленин (1929), Хәсән Урманов (1930) портретлары. 1930–1934 елларда М. Кәримов ТАССРның Үзәк музеенда фәнни хезмәткәр булып эшли, Урта Азиягә П.Е. Корнилов (1931) җитәкчелегендәге музей экспедициясендә катнаша. ТАССРның Үзәк музеенда «Капитал илләрендә революцион графика» күргәзмәсен оештыруда катнаша (1934, Яңа Көнбатыш нәкыше музее белән берлектә), анда Казан тамашачысына пролетар хәрәкәткә һәм СССРга теләктәшлек белдергән прогрессив Көнбатыш рәссамнары Стейнлейн, Гросс, Уитца һ.б.ның басма графикасы тәкъдим ителә. 1935 елда Мәскәүгә күченә, Третьяков галереясында, А.С. Пушкин исемендәге Рәсем сәнгате музеенда, СССРның революция музеенда, Кусководагы керамика музеенда фәнни хезмәткәр,

реставратор булып эшли, музей экспозицияләре өчен тарихи документларның күчермәләрен башкара [Улемнова, 2018, с. 225].

1931 елда ТТИ тәмамлаган Мусин Госман Яхья улы (1908–1942) вакытлы матбугатта эшли, Татгосиздат белән хезмәттәшлек итә. Рус һәм татар язучылары А. Пушкин (1940), А. Чехов (1940), М. Җәлил (1940), Т. Гыйззәт (1940), З. Садыйкова (1940), Н. Баян (1940) һ.б. китапларын бизәүче рәссам була. 1939 елда Г. Тукайның шигырьләр китабының (Казан: Татгосизздат, 1940) тышлыгын эшләгәндә, стильләштерелгән үсемлек орнаментыннан файдалана. Г. Тукай шигырьләренә ул ясаган иллюстрацияләр сериясе академик басмага (Казан: Татгосиздат, 1943) кертелгән иде [Улемнова, 2018, с. 236–237].

1931 елда ТТИны тәмамлаган Баһаветдинов Хәбибулла (1910–?) татар телендә чыккан «Пролетариат сәнгате» журналы белән хезмәттәшлек итә (1931), анда аның «Колхозчылар», «Токарьлар цехында», «5 еллыкны 4 ел эчендә» рәсемнәре басыла, алар ирекле манера, тәэсирле һәм лаконик сызыклары белән аерылып торалар [Улемнова, 2018, с. 213].

Рахманкулов Морат Шәрип улы (1907–2003) ТТИны 1931 елда тәмамлый. 1933 елдан башлап аның рәсемнәре татар вакытлы матбугатында басыла: «Авыл яшьләре» журналында, «Кызыл яшьләр» газетасында. 1931–1933 елларда Уфада Башкорт сәнгать техникумында укыта, 1933–1935 елларда Мәскәүдә Хроникаль-документаль фильмнар киностудиясендә эшли. 1935 ел азагыннан – Казанда Хроникаль-документаль фильмнар киностудиясендә бизәүче рәссам һәм мультипликатор, 1942 дән «Татхудожник» ширкәтендә рәссам булып эшли [Улемнова, 2018, с. 243].

Рәхмәтуллин Мөкатдәс (1907–?), 1930 елда ТТИны тәмамлый. Казанда татар телендә чыгучы «Атака» (1931), «Чаян» (1931) журналларында рәссам булып эшли. Бу басмаларда аның авыл хезмәте, шәһәр тормышы темаларына рәсемнәре дөнья күрә [Улемнова, 2018, с. 243–244].

Газизова Мөнәвәрә Габделбәр кызы (1918–1993) ТТИны 1931 елда тәмамлый, берничә елдан В.И. Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтында белем алуын дәвам итә. 1941–1943 елларда Мәскәү югары уку йортын тәмамлаганнан соң, юллама белән Фрунзе шәһәренә (Бишкәк, Кыргызстан) китә. 1944 елдан Оренбургта яши, 1946 елда Совет рәссамнары берлегенә керә, Оренбург оешмасы идарәсе рәисе итеп сайлана. Танылган рәссам, жанр картинасы остасы буларак танылa, аның эшләре Россия һәм Казакъстан музейларында күрсәтелә [Художники Оренбургской..., с. 7].

Казан сәнгать техникумын тәмамлаучыларның кайберләре үзләрен рәсем сәнгатендә генә түгел, әдәбиятта да күрсәттеләр. Мәсәлән, ТТИны 1931 елда тәмамлаган Арсланов Нури Газиз улы (1912–1991) күренекле татар шагыйре, Тукай премиясе лауреаты булды. 1931–1933 елларда Кукмара бистәсендә (ТАССР) татар әдәбияты һәм рәсем укытучысы, бизәүче рәссам булып эшли, аннары Урта

Азиягә һәм Ерак Көнчыгышка юл ала. 1933 елдан Казанда «Пионер каләме» журналы һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакцияләрендә рәссам булып эшли. 1930–1940 елларда Татарстан китап нәшрияты өчен күпсанлы китапларны бизи. Бөек Ватан сугышыннан соң (ул – сугыш ветераны), «Социалистик Татарстан», «Советская Татария» газеталарында рәссам буларак хезмәт куя (1946–1952).

Тагын бер күренекле татар язучысы Әмиров Мирсаяф Мәсалим улы (Мирсәй Әмир) (1907–1980) үзенең иҗат юлын рәссам сыйфатында башлап җибәрә. Ул 1926 елдан КХПТ да укый, 1928 елдан язучылык һәм журналистлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлый, «Авыл яшьләре» журналында, үзе иллюстрацияләгән «Кызыл яшьләр» газетасында хикәяләрен бастыра. Мирсәй Әмир КХПТ да укыган еллары турында кызыклы истәлекләр калдыра [Әмир, с. 108–128].

Казан сәнгать техникумында 1920 елларның икенче яртысында укыган башка күп кенә татар студентларының язмышы әлегәчә билгесез булып кала. КОХТТда әзерлек төп педагогик юнәлештә барганга, мөгаен, бу исемлектәгеләрнең күбесе нәкъ менә шушы юлдан китә. Мәсәлән, 1929 елдан башлап Россиянең төрле уку йортларында – Себер-татар педагогика техникумында (1929–1936), Томск шәһәренең 12 нче урта мәктәбендә рәсем укыткан Мөхәммәтшин Зәки Мөхәммәтша улы (1900–1980) шундыйлардан. 1945 елдан ул Казанда яши, Казан педагогика училищесында рәсем һәм рәсем ясау методикасын укыта.

Бу тыйнак хезмәтчәннәрнең ролен бәяләп бетерү мөмкин түгел. 1920–1930 елларда татарлар өчен сәнгати белем бирүне үстерүнең әһәмияте гаять зур булган – асылда, рәсем сәнгате өлкәсендә ликбез белән шөгыльләнергә туры килгән бит. Татар педагоглары һәм татар телендә дәреслекләр юк диярлек. Һәм менә бу гаять зур педагогик эш катламын Казан сәнгать техникумын тәмамлаучылар күтәрә. Мәсәлән, Бари Доминов ике уку әсбабы чыгара: «Рәсем төшерергә өйрән» (Казан: Татиздат, 1929) һәм «Полиграфия техникасы. Типография, цинкография, литография, офсет, тифдрук) (Казан: Татиздат, 1932). Гата Йосыпов «Кечкенә иҗатчылар» әсбабын чыгара (Мәскәү-Самара, 1933). Зәки Мөхәммәтшин Казан журналларында рәсем ясау методикасы буенча берничә мәкалә бастыра (Мәгариф, 1933, № 5; Совет мәктәбе, 1956, № 5, 6, 8).

КОХТТның төрле документларыннан [ГАДЛС, ф. 701 (2812), оп. 3л, ед. хр. 120, л. 7 об., 8; ед. хр. 121, л. 1, 2, 19] алдагы язмышлары безнең өчен билгесез булып калган студентлар турында тулырак мәгълүмат алырга мөмкин:

Алтынбаев Әхмәт Мөзәммәт улы. 1907 елгы. Эшче гаиләсеннән. 1926 елда укырга керә, 1931 дә тәмамлый;

Богданов Әхәт Гата улы, 1899 елгы. Мәктәп хезмәткәре. Казанда түбәндәге адрес буенча яшәгән: Б. Мещанская ур., 65 [ГА РТ, ф. Р-1431, оп. 1, ед. хр. 106, л. 14];

Брондуков (Брундуков) Солтан-Әхмәт (Солтан Әхмәт улы). 1908 елгы. Крестьяннардан. 1928 елда укырга керә, 1931 дә тәмамлый. Алабугага «производство эшләренә», клубка һәм Техникумга юллама белән җибәрелә. Соңыннан Ташкәнт педагогика институтының сәнгать-графика факультетында укыта [Урманче, 2017, с. 99];

Галиева Мәүлүдә Абдрахман кызы. 1911 елгы. Эшчеләрдән. 1928 елда укырга керә;

Гобәйдуллина Гөлсем Вәлиулла кызы. 1908 елгы. Крестьяннардан. 1926 елда укырга керә, 1931 дә тәмамлый;

Досалинов (Досалимов) Җиһанур. 1908 елгы. Мулла малае. 1926 елда укырга керә, 1931 дә тәмамлый;

Зәетов Идрис. 1910 елгы. Крестьяннардан. 1926 елда укырга керә;

Зайләев Рәфкать (Рәфгать) Әхмәтгали улы. 1911 елгы. Крестьяннардан. 1927 елда укырга керә, 1931 дә тәмамлый;

Мәрдиева Хәдичә 1931 елда Минзәләгә эшкә җибәрелә;

Урманчиев Каюм А. 1908 елгы. 1928 елда укырга керә, 1931 дә тәмамлый;

Үтәкаев Әфләк. 1910 елгы. 1928 елда укырга керә, 1931 дә тәмамлый. Арчага техникумга һәм клубка эшкә җибәрелә.

Кодрәтле интернет Зәетов Идрис Таһир улының (1901–1988) язмышын ачыкларга мөмкинлек бирде. Аны тормыш хәлләре иҗаттан аера: КХПТда укуын аңа 1929 елда өзәргә туры килә, чөнки Имантау (Казакъстан) станицасындагы «Прогресс» коммунасы карары буенча гаиләсе белән бергә ул коммунада эшләргә кала. Шуннан бирле, 1976 елда пенсиягә чыкканчы, ул Төньяк Казакъстан өлкәсендә комсомол, партия, совет эшендә була. Армиядә хезмәт итә (1932–1934, 1941–1947), Сталинград янындагы, Дон буендагы сугышларда катнаша, Будапештны ала, Румыниядә, Венгриядә, Австриядә сугыша, шунда җиңүне каршылый. Кызыл Йолдыз ордены, «Сугышчан казанышлары өчен», «Сталинград оборонасы өчен», «Будапештны алган өчен», «Венаны алган өчен», «Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә [Заитов Идрис...].

Шулай итеп, ТАССРның беренче ун елында XX гасыр татар рәсем сәнгатен үстерүнең нигезләре салына, КХПТ диварларында, төрле өлкәләрдә – газета-журнал битләрендә, театр сәхнәләрендә, шәһәр урамнарында һәм мәйданнарда, – татар милли профессиональ рәссамнары, скульпторлары, графиклары формалаша. Актив үсеш алган полиграфия җитештерүендә, вакытлы матбугатта, агитация-масса һәм тамаша сәнгате өлкәсендә рәссам-графикларга ихтыяҗ аеруча зур була. Әлеге процессларның мөһим өлешен татар җәмгыятенә яңа белем һәм күнекмәләр алып килүче рәссам-педагоглар отрядын формалаштыру тәшкил итә. Алар КХПТны тәмамлаган белгечләр эшләгән шәһәр һәм районнарда талантларны ачыкларга ярдәм итәләр. 1920 елларның икенче яртысында, Б.И. Урманче тырышлыгы белән, Казан Татарстан Республикасыннан гына

түгел, Россиянең башка төбәкләреннән дә татар рәссамнарын әзерләү үзәгенә әверелә, шул рәвешле милли рәсем сәнгатен үстерүгә сизелерлек йогынты ясый.

**Әдәбият**

*Әмир М.* Хатирәләр урманы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 178 б.

Баки Урманче. Живопись. Графика. Скульптура. Декоративно-прикладное искусство. Каталог выставки к 115-летию со дня рождения / авт.-сост. кат. О.Л. Улемнова; авт. вст. ст.: О.Л. Улемнова. Р.Г. Шагеева. Казань: Заман, 2012. 112 с.: ил.

Баки Урманче. Живопись. Графика. Скульптура. Литературное наследие. К 120-летию со дня рождения художника / сост.: Д.Д. Хисамова, О.Л. Улемнова, Г.П. Тулузакова. Казань: Заман, 2017. 480 с.: ил.

ГА РТ. Ф. Р-1431, оп. 1, ед. хр. 106.

ГАДЛС. Ф. 701 (2812), оп. 3л, ед. хр. 120.

ГАДЛС. Ф. 701 (2812), оп. 3л, ед. хр. 121.

ГАДЛС. Ф. 701 (2812), оп. 3л, ед. хр. 96.

ГАДЛС. Ф. 701(2812), оп. 3л, ед. хр. 114.

Дмитрий Красильников (1903–1951). Живопись. Графика. 3-я выставка проекта «Московские казанцы». Каталог / авт.-сост. и авт. вст. ст. О.Л. Улемнова. Казань: 2018. 64 с.: ил.

*Дульский П.* Конкурс графического отделения художественно-театрального техникума. Казань, 1929. 16 с.: ил.

Заитов Идрис Тагирович // URL: https://www.polkmoskva.ru/upload/iblock/fd9/fd999b140b8277b657427563ced75c8a.pdf (дата обращения: 15.06.2020).

*Кривошеева Т.Н.* Скульптура Татарстана: истоки, становление, традиции. Казань: Отечество, 2013. 254 с.: ил.

*Лобашева И.Ф.* Шакир Мухамеджанов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 163 с.: ил.

*Могильникова Г.А.* Булат Д.Г. // Татарская энциклопедия: в 5 т. Т. 1: А–В. Казань: Институт Татарской энциклопедии, 2002. С. 482–483.

НА ГМИИ РТ. Ф. 4, оп. 2, ед. хр. 245.

*Новицкий А.И.* Баки Урманче // Баки Урманче. Живопись. Графика. Скульптура. Литературное наследие. К 120-летию со дня рождения художника. Казань: Заман, 2017. С. 13–84.

*Султанова Р.Р.* Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития (XX – нач. XXI в.). Казань: Казанская недвижимость, 2019. 592 с.: ил.

*Улемнова О. Л.* [Вступительная статья к разделу «Иллюстрации»] // Путешествие к Тукаю. Каталог выставки. Казань, 2016. С. 256–273.

*Улемнова О.Л.* Казанская графика 1920–1930-х годов. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2018. 279 с.

*Улемнова О.Л.* Татарская книга в Париже. Реконструкция выставок 1925 и 1931 годов // 3-я Казанская международная биеннале печатной графики «Всадник». Каталог. Казань: Заман, 2017. С. 137–153.

*Урманче Б.И.* Становление и развитие изобразительного искусства и архитектуры Татарстана // Искусство Татарстана: пути становления: Сб. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ирагимова КФАН СССР, 1985. С. 69–78.

*Урманче Б.И.* Татарские художники и Казанская школа искусств // Баки Урманче. Живопись. Графика. Скульптура. Литературное наследие. К 120-летию со дня рождения художника. Казань: Заман, 2017. С. 91–103.

*Хисамова Д.Д.* Скульптура Баки Урманче // Баки Урманче. Живопись. Графика. Скульптура. Литературное наследие. К 120-летию со дня рождения художника. Казань: Заман, 2017. С. 465–470.

Художники народов СССР. Биобиблиографический словарь. Т. 3. М.: Искусство, 1976. 543 с.

Художники Оренбургской области: библиогр. указ. / сост. Е.В. Гинтер. Оренбург, 1982. 45 с.

Шакирджан Тагиров – педагог, просветитель, художник. К 150-летию со дня рождения / сост.: В.Р. Тагиров, Р.Р.Султанова. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2008. 68 с.

***Улемнова Ольга Львовна,***

*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 069(091)

***Н.В. Герасимова***

# КАЗАНДА КӨНЧЫГЫШ МУЗЕЕ. ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛМАГАН ПРОЕКТ

В статье раскрывается история создания в столице ТАССР – Казани уникального музея (1920), демонстрирующего культурные связи татар с многочисленными народами Востока, проживающими от Средней Азии до Китая.

**Ключевые слова:** Казань, Татарская Автономная Советская Социалистическая Республика, музей, выставка, коллекция, миниатюра, Б.Ф. Адлер.

The article reveals the history of the establishment in Kazan, capital of TASSR, of a unique museum, which demonstrates the cultural relations of the Tatars with the numerous peoples of the East, living on the territories from Central Asia to China.

**Keywords:** Kazan, Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic, museum, exhibition, collection, miniature, B.F. Adler.

ТАССР төзелү республикада музей эшен үстерүгә яңа этәргеч бирә. Башкалада булган музейларны яңартып кору һәм бөтен республика территориясендә яңа музейлар төзү процессы активлаша. Аның мөһим өлешен музейлар составында сәнгать коллекцияләре булдыру тәшкил итә. Шул ук вакытта музей сәясәте тулысынча дәүләт тарафыннан билгеләнә. Ул музей төзелешенең бурычларын һәм хокукый күрсәтмәләрен эшли һәм музейлар эшчәнлегенә турыдан-туры җитәкчелек итә. Республикада дәүләт куйган бурычларны хәл итү белән Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Музейлар эшләре һәм сәнгать һәйкәлләрен, борынгы әйберләрне һәм табигатьне саклау бүлеге шөгыльләнә башлый [Корнилов, с. 167]. Аның җитәкчелегендә республикада дистәдән артык музей ачыла. Алар арасында 1920 елда төзелгән Көнчыгыш халыклары мәдәнияте музее аерылып тора. Аның ачылуы яңа тарихи этапта барлыкка килгән иң әһәмиятле мәсьәләне – республикада милли мәдәният музее булдыруны хәл итү зарурлыгын тудыра. Музейны оештыруда хәлиткеч рольне Татарстанның Үзәк музее директоры Б.Ф. Адлер, Татарстан АССРның Мәгариф халык комиссариаты музее һәм музей бүлеге фәнни хезмәткәре М.Г. Худяков, Казан университетының тарих һәм сәнгать теориясе кафедрасы мөдире һәм университеттагы нәфис сәнгать һәм борынгы әйберләр музее директоры А.М. Миронов; Казан университеты, Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография институты профессоры Н.Ф. Катанов; университетның тарих, археология һәм этнография җәмгыяте рәисе М.С. Гобәйдуллин уйный.

Казан төбәге Россиядә традицион рәвештә Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләре очрашкан урын буларак кабул ителә: XIX гасыр башыннан Казан университетында «Көнчыгыш разряды» – Көнчыгыш халыклары телләрен һәм мәдәниятен өйрәнү факультеты эшләп

килә [Восточный разряд...], аның укытучылары Кытай, Иран һәм җирле – болгар һәм татар сәнгате әсәрләренең уникаль коллекцияләрен җыялар [Ключевская, с. 101–105]. Факультет ябылганнан соң да, университет музейлары диварларында – Сәнгать һәм борынгы әйберләр, Этнография, шулай ук Ватан белеме музейларында Көнчыгыш коллекцияләрен туплау һәм саклау эше дәвам итә. Бәлки, нәкъ менә шуңа күрә университет диварлары музей ачылышына ишарә булган масштаблы «Көнчыгыш халыклары мәдәнияте күргәзмәсе»н кабул иткәндер дә.

Күргәзмәне оештыручыларның берсе – Г.Ш. Шәрәф фикеренчә, этнография, татарларның һәм башка Көнчыгыш халыкларының этнографиясе, тарихы һәм сәнгате буенча материаллар тупланган махсус музей булдыру идеясен татар җәмәгатьчелеге элек-электән хуп күрсә дә, революциягә кадәрге хакимият аны гамәлгә ашырырга ирек бирми [Шараф, с. 6]. Бары тик 1920 елда гына Мөселман үзәк фәнни коллегиясе, ә аннары Татарстан Мәгариф халык комиссариатының Фән бүлеге әлеге идеяне тормышка ашыруга керешә [Фаттахов, Валеев, с. 13]. Нәтиҗәдә, 1920 елның 1 сентябрендә Казанда «Көнчыгыш халыклары музее» оештырыла.

Музейның Б.Ф. Адлер тарафыннан эшләнгән концепциясе «Милли музей» мәкаләсендә чагылдырылган [Адлер, 1921, с. 3–12]. Анда Адлер милли музей булдыру идеясен нигезли. Автор фикеренчә, татар мәдәнияте «бөтен төрки-татар гаиләсенең акрынлап үсешен күз алдына бастыру» максаты белән «рус һәм көнчыгыш ислам мәдәниятләре белән бәйләнештә» күрсәтелергә тиеш [Адлер, 1921, с. 9]. Концепция нигезендә музейда дүрт бүлек булдыру планлаштырыла: археология-тарих, этнография, икътисад һәм Көнчыгыш сәнгате бүлеге.

Булачак музейга экспонатларны ТАССРның Үзәк музее, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, Үзәк Көнчыгыш китапханәсе[1], Духовный академия[2] бирә. Шәхси коллекцияләрдән М.Е. Евсеев[3], С.М. һәм Г.М. Галиевләр[4], Г.М. Залкинд[5],

[1] Үзәк Көнчыгыш китапханәсе – ТАССРның милли, республика, рус һәм чит ил басмалары өчен иң зур китап саклау урыны.

[2] Казан духовный академиясе диварлары артында 1912 елдан тарих-этнография музее урнашкан була. Аның тупламаларының нигезен «чит халыкларның тормыш-көнкүреш» әйберләре, ягъни Россия империясе подданныйлары булган рус булмаган халыкларның 1840 еллардан җыела башлаган көнкүреш предметлары һәм костюмнары тәшкил итә.

[3] Макар Евсеевич Евсеев (1864–1931) – галим, мәгърифәтчеъ, педагог, Казан университеты профессоры.

[4] Салих Мөхәммәтҗан улы Галиев – коллекционер, библиофил, этнограф.

Галимжан Мөхәммәтҗан улы Галеев (псевдонимы: Галимҗан әл-Баруди) (1857–1921) – күренекле иҗтимагый-сәяси эшлекле, дин тәгълиматчысы, атаклы педагог-реформатор, мәгърифәтче.

[5] Георгий Моисеевич Залкинд (1893–1958) – әдәбият тарихчысы, библиограф, музей эшлеклесе, Көнчыгыш кульъязмаларын туплаучы.

Ф. Аитова[1], А.М. Миронов[2], Р.И. Лихачева[3] һ.б. коллекцияләрендәге әсәрләрнең кыйммәте аеруча зур була. Профессор Н.Ф. Высоцкийның[4] Кытай фарфоры һәм Көнчыгыш тәңкәләре коллекцияләре, В.Ф. Смолинның[5] болгар әйберләре, Н.Ф. Катанов[6] коллекциясендәге Алтын Урда һәм болгар тәңкәләре, профессор С.Е. Маловның[7] Кытай сәнгате әсәрләре аеруча кыйммәтлеләрдән санала. Музей комиссиясе, Көнчыгыш музеена экспонатлар алып килүләрен сорап халыкка мөрәҗәгать иткәннән соң, гади Казан халкы да шактый әйберләр китерә.

Шушы җыелган материаллар нигезендә 1920 елның 28 сентябрендә Казан университетының география кабинетында «Көнчыгыш халыклары мәдәнияте күргәзмәсе» ачыла [Выставка..., с. 653]. Ул сигез – татар, болгар, Көнчыгыш нумизматикасы, Көнчыгыш кульязмалары һәм китаплары, Урта Азия халыклары, Идел буе халыклары, Себер халыклары, Кытай халкы бүлекләреннән тора. Географиянең шундый киңлеге «Шәрык халыклары» дигән терминга Б.Ф. Адлер биргән аңлатма белән аңлатыла. Ул күргәзмә буенча эшләнгән юл күрсәткечнең керешендә болай дип яза: «сюда мы относим все народы, живущие на Востоке от Урала, а также те из европейских народов, которые находятся …или находились…под влиянием восточных культур и имеющие родственные связи по крови и языку с народами Азиатского востока» [Адлер, 1920, с. 4]. Күргәзмә 1921 елның февраленә кадәр эшли Һәм бик тә популяр була – аны 25 000 нән артык кеше тамаша кыла [ТР ДА, Р-3682 ф., 1 тасв., 5 сакл. бер., б. 115].

Музей тамашачысына тәкъдим ителгән сәнгать әсәрләре арасында, Б.П. Денике бәяләвенчә, болгар чынаяк кирпиче, ялтыравыклы (глазурьлы) керамика савытлар һәм зәркән бизәнү әйберләре, татар зәркән бизәнү әйберләре һәм костюмнары, мордва, чирмеш һәм чувашларның чигү үрнәкләре аеруча игътибарга лаек. Тикшеренүченең игътибарын Себер бүлегендә – кытай үрнәкләре йогынтысында

[1] Фатиха Аитова (1866–1942) – меценат, җәмәгать эшлеклесе. Хатын-кызлар өчен беренче татар гимназиясен оештыручы.

[2] Алексей Максимович Миронов (1866–1929?) – сәнгать тарихчысы, педагог, Казан университеты профессоры, сәнгать күргәзмәләре оештыручы, музей эшлеклесе, коллекционер.

[3] Раиса Ивановна Лихачёва (Трофимова) (1860–1929) – Казанда иң зур коллекционерларның берсе булган Андрей Федорович Лихачевның тол калган хатыны. Лихачев тупламасы Казандагы беренче һәркем керә ала торган музейның – Шәһәр фәннисәнәгать музееның нигезенә салынган.

[4] Николай Фёдорович Высоцкий (1843–1922) – табип, Казан университетының хирургия, патология һәм терапия профессоры, коллекционер.

[5] Виктор Фёдорович Смолин (1890–1932) – Казан университеты профессоры, археолог һәм музей хезмәткәре, Идел буе, Себер, Кырым халыкларының мәдәниятен өйрәнүче.

[6] Николай Фёдорович Катанов (1862–1922, Казань) – Россия тюркологы, Казан университеты һәм Казан духовный академиясе профессоры, чагыштырма тел белеме докторы, этнограф, фольклорчы, җәмәгать эшлеклесе.

[7] Сергей Ефимович Малов (1880–1957) – рус совет лингвисты, шәркыятьчетюрколог, СССР ФА мөхбир әгъзасы. Төрки телләр буенча белгеч.

ясалган гольд орнаментлары, Ерак Көнчыгыш бүлегендә кытай фарфоры җәлеп итә [Денике, 1920, с. 128–129; Денике, 1921, с. 108–126]. Күргәзмәгә куелган фарсы кульязмалары, шул исәптән Әмир Хөсрәү Дәһләвинең «Хамсә» дип аталган кульязмалары аеруча кызыксыну тудыра, алар XVI гасыр ахырында күчереп язылган. «Хамсә» ике заставка һәм 9 миниатюра белән бизәлгән: «Миграҗ» – Мөхәммәд пәйгамбәрнең күккә ашуы, «Искәндәр көзгесе» эпизоды һәм «Сигез җәннәт» [Денике, 1921, с. 109–117]. П.М. Дульский «Тәфсир-Кашшаф-Зәмәхшәри» дип аталган һәм Коръән тәфсирләрен үз эченә алган кульязмага игътибар итә. Аны XII йөз башында яшәгән Харәзем авторы «кара кара, киноварь, алтын һәм зәңгәр буяулар кулланып, гарәп хәрефләре белән матур итеп язган» [Дульский, с. 134]. Аның төп бизәкләре булып «уртасы караңгы зәңгәр фонда алтын розетка белән тутырылган турыпочмаклык формасындагы бик яхшы эшләнгән заставкалар хезмәт иткән. Турыпочмаклыкның кырыйларында да алтынлап төшерелгән орнамент. Заставканың бөтен фоны буйлап чәчәкләр рәсеме урнашкан, аларның сабаклары спиральсыман сызыклар белән стильләштерелгән» [Дульский, с. 134–135].

Күргәзмә ябылганнан соң музей коллекцияләрен формалаштыру эше дәвам иттерелә. Университет укытучысы Н.И. Масленников этнографик предметлар җыю максаты белән Алатырь шәһәренә һәм Кученяево авылына фәнни сәфәргә рөхсәт ала [ТР ДА, Р-3682 ф., 1 тасв., 5 сакл. бер., б. 116]. Музейның төбәк өчен характерлы һәм фәнни кыйммәткә ия фоторәсемнәр сатып алу турындагы белдерүләре газеталарда басылып чыга [ТР ДА, Р-3682 ф., 1 тасв., 5 сакл. бер., б. 40а–40б]. Фәнни кадрлар да әзерләнә – Б.П. Денике Казанда Көнчыгыш халыклары музее төзелү сәбәпле музейда Шәрык сәнгате буенча фәнни эш алып бару өчен Мәскәүгә һәм Петроградка командировкага җибәрелә [ТР ДА, 271 ф., 1 тасв., 163 сакл. бер., б. 350]. Әмма 1921 ел ахырына музейны алга таба финанслау мөмкинлеге турындагы мәсьәлә бөтен кискенлеге белән куела. Өстәвенә, 1922 елга кадәр аңа аерым бина да бирелми. Мондый шартларда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты Академүзәге Көнчыгыш халыклары музеен Үзәк музейга кушу һәм коллекцияләрне соңгысындагы бүлекләргә бүлеп бирү турында карар кабул итә [ТР ДА, Р-3682 ф., 1 тасв., 948 сакл. бер., б. 81]. Болар барысы да 1922 ел башында гамәлгә ашырыла. Музейның әлеге язмышка дучар булуына аның төп идеологы Б.Ф. Адлерның чит илгә китеп баруы да дә йогынты ясамый калмагандыр.

Музей бик аз яшәүгә карамастан, аны оештыручылар кызыклы материал туплауга һәм республика халкында Көнчыгыш мәдәнияте белән кызыксыну уятуга ирешәләр. Көнчыгыш илләре тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү буенча фәнни эш Көнчыгыш Академиясе каршындагы Россиянең көнчыгышын өйрәнү буенча Татарстан Республикасы фәнни җәмгыяте, ә аннан соң Татарстан Мәгариф халык комиссариаты Академүзәге каршындагы Татар белеме (татароведение) җәмгыяте эшчәнлеге кысаларында дәвам иттерелә [Фаттахова, Валеев, с. 61].

Бүгенге көндә Казанда аның тарихи һәм мәдәни әһәмиятен чагылдырган берничә музей бар: Татарстан Республикасы Милли музее, Казанның 1000 еллыгы музее, Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музее, Татар халкы дәүләтчелеге һәм Татарстан Республикасы тарихы музее һәм башкалар. Шул ук вакытта, безнең карашка, хәзерге заман шартларында татар халкының Көнчыгыш дөньясы белән киң элемтәләрен күрсәтүгә юнәлдерелгән Көнчыгыш музее булдыру идеясен яңадан торгызу бик тә мөһим, чөнки мондый учреждение Россиянең Көнчыгыш халыклары белән элемтәләрен торгызуда Казанның үзгә ролен ассызыклаячак.

**Әдәбият**

*Адлер Б.Ф.* Введение // Выставка культуры народов Востока. Казань: Первая государственная типография, 1920. С. 4.

*Адлер Б.Ф.* Национальный музей // Казанский музейный вестник. 1921. № 1–2. С. 3–12.

Восточный разряд Казанского университета. [Электронный ресурс] http: // www.briefeducation.ru/brieds-471-1.html (дата обращения: 01.06.2020).

Выставка культуры народов Востока // Татарская энциклопедия: в 5 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. Т. 1: А–В. С. 653–654.

*Денике Б.П.* Заметки по искусству Востока // Казанский музейный вестник. 1921. № 1–2. С. 108–126.

*Денике Б.П.* Искусство на выставке культуры народов Востока // Выставка культуры народов Востока. Казань, 1920. С. 128–129.

*Дульский П.М.* Миниатюра на Выставке культуры народов Востока // Выставка культуры народов Востока. С. 134–135.

*Ключевская Е.П.* Концепция создания восточного музея: история развития // Искусство и этнос: новые парадигмы. Казань: Дом печати, 2002. С. 99–108.

*Корнилов П.Е.* Охрана памятников ТССР (1917–1927) // Вестник научного общества татароведения. Казань, 1928. № 8. С. 163–173.

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы (ТР ДА). Р-3682 ф.. 1 тасв., 5 сакл. бер.

ТР ДА. 271 ф., 1 тасв., 163 сакл. бер.

ТР ДА. Р-3682 ф., 1 тасв., 948 сакл. бер.

*Фаттахова Г.А., Валеев Р.К.* Академический центр Татарии: 1920-е годы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 95 с.

*Шараф Г.Ш.* История возникновения выставки // Выставка культуры народов Востока. Казань: Первая государственная типография, 1920. С. 6–9.

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 78.01

***Э.М. Галимова***

# ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕННАН ТАТАР МУЗЫКА СӘНГАТЕ ҮСЕШЕНӘ КҮЗӘТҮ

В данной статье представлен обзор поэтапного формирования и развития татарского музыкального искусства. Был пройден сложный и богатый на культурные события вековой путь развития национального музыкального искусства. Фактически с начала XX века и далее уже более интенсивно все сферы искусства начинают развиваться в связи с образованием Татарской АССР. Автор статьи приводит исторические сведения о том, что Казань становится важным национальным культурным центром, где открываются новые образовательные учреждения. Создание в Казани Татарского государственного оперного театра, Татарской государственной филармонии, Ансамбля песни и танца Татарской АССР, Союза композиторов и ряда других творческих организаций и коллективов, позволили создать крепкий фундамент для развития культуры и искусства республики, воплотить в жизнь музыкальные премьеры, сохранить лучшие национальные традиции и обрести богатое культурное наследие.

**Ключевые слова:** музыка, татарское музыкальное искусство, национальные традиции, жанры песенной культуры, музыкальные премьеры, оперное и балетное искусство, композиторское творчество, учреждения культуры и искусства.

This article provides an overview of the phased formation and development of Tatar musical art. The national musical art has gone through a complex and culturally rich centuries-old development path. In fact, from the beginning of the 20th century, all spheres of art began to develop more and more intensively in connection with the formation of the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic. The author of the article gives historical information that Kazan then becomes an important national cultural center, where new educational institutions open. The creation of the Tatar State Opera House, the Tatar State Philharmonic Society, the Song and Dance Ensemble of the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic, the Union of Composers and several other creative organizations and collectives in Kazan made it possible to create a strong foundation for the development of culture and art of the republic, create musical masterpieces, preserve the best national traditions and find rich cultural heritage.

**Keywords:** Music, Tatar musical art, national traditions, genres of song culture, musical premieres, opera and ballet art, composer creativity, cultural and art institutions.

Тулы бер гасыр дәвамында татар музыка сәнгате кабатланмас һәм кызыклы вакыйгаларга бай, шул ук вакытта иҗади яктан катлаулы үсеш юлы үтә. Гомумән алганда, музыка сәнгатен халыкчан һәм профессиональ юнәлешләргә бүлеп карау, шул исәптән нәтиҗәләрне барлау – гадәти күренеш. Тарихка күз салсак, нәкъ менә татар халкының көнкүреше, традицион музыка мәдәнияте үрнәкләре музыка сәнгатенең профессиональ яктан формалашуына билгеле бер йогынты ясый. Әлбәттә, музыкаль фольклор үрнәкләре һәм жанрлары хакында

сүз бара. Җыр сәнгатенең йөзек кашы булган «озын көйләр», соңрак халык арасында киң таралган «кыска көйләр» жанрындагы җырлар, татар музыка сәнгатенең үсешенә йогынты ясаган төп чыганаклардан санала. Татар халык иҗаты кысаларында шигъри әсәрләрне, бәет һәм мөнәҗәтләрне көйләп уку традициясе, инструменталь сәнгатьне билгеле бер югарылыкка күтәрү җәһәтеннән, курай, сорнай, думбра, танбур, гөслә кебек уен коралларында уйнарга өйрәнү – профессиональ сәнгатьне гамәли үстерүгә шулай ук зур этәргеч була.

Әйтергә кирәк, XX гасыр башында ук Казан зур мәдәни башкалага әйләнә: музыка мәктәпләре, сәнгать юнәлеше буенча яңа уку йортлары эшли башлый. 1904 елны Р. А. Гуммерт мәктәбе нигезендә Казан музыка училищесы ачыла. Мәгълүм ки, М. Балакирев, Р. Гуммерт, И. Козлов, Е. Ковелькова, М. Пятницкая кебек иҗади шәхесләрнең эшчәнлеге Казан белән бәйле була. Татар музыка сәнгатенең үз юнәлешен булдыруга, аны профессиональ яктан үстерүгә алар үзләреннән зур өлеш кертә һәм мәдәни мирасыбызны туплау тарихында тирән эз калдыра [Валиахметова, с. 102].

Әлеге фикерне дәвам итеп, без беренче татар музыкантлары булып танылган К. Мотыйгый, Ф.М. Латыйпов, Г.С. Әлмөхәммәтов, Ф. Гомәрова, скрипкачылар – В. Апанаев, Г.М. Зайпин, пианист-импровизатор З.Я. Яруллин, гармунчылар – Ф. Биккинин, Ф.К. Туишевны атый алабыз.

1907 елның 1 декабрендә Казанда Шәрык клубы ачыла. Күпкырлы эшчәнлек алып барып, ул үзендә талантлы татар яшьләрен һәм иҗат әһелләрен берләштерә. Шәрык клубында төрле кызыклы чаралар, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә.

ТАССР төзелгәннән соң, милли мәдәниятнең үсешен барлау һәм пропагандалау эше дәүләт сәясәте нигезендә алып барыла башлый һәм беренче планга чыга дисәк тә ялгыш булмас. Гомумән алганда, профессиональ музыка сәнгате формалашу музыкаль сәхнә әсәрләреннән башлана. XX гасырның 1930 елларыннан башлап, республика җитәкчелеге татар композиторлары алдына милли опера жанры булдыру максатын куя. 1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе дә оештырыла.

Әйтергә кирәк, бу чорда рус классик операларын үрнәк итеп алып, ә үзебезнең халык җырларын өземтә сыйфатында кулланып яки халык җырларына стилизация эшләү ысулы белән татар операсы тудыру милли мәдәниятебез үсешендә иң беренче юнәлешне тәшкил итә: либретто авторы Г. Әлмөхәммәтов, композиторлар С. Габәши һәм В. Виноградов 1924 елда – «Сания», ә 1930 елда «Эшче» операларын иҗат итәләр. Шулай ук А. Эйхенвальд тарафыннан «Дала» (1929), «Кояшлы таш» (1932) оперaлары языла. Әлеге чорның талантлы музыканты, композитор, җәмәгать эшлеклесе Солтан Габәшинең күпкырлы иҗаты бүгенге көндә бик югары бәяләнә һәм аерым игътибарга лаек.

Икенче юнәлешне без тулысынча Салих Сәйдәшев иҗаты белән бәйли алабыз. Салих Сәйдәшев әлеге фикерне күпкырлы иҗаты

белән раслый: ул татар музыка сәнгатендә музыкаль драма жанрын булдыра, аны милли хәзинәбез итеп күрсәтүгә ирешә һәм бөек композитор булып таныла. Салих Сәйдәшев татар музыкасын Европа гармониясе ярдәмендә баета, аның милли йөзен ассызыклый, жанрларны төрлеләндереп, яңалык кертә, композитор буларак, ул үз стилен булдыра, симфоник оркестр өчен язылган кызыклы, шул ук вакытта заманча оркестровкалары ярдәмендә халык җырларына һәм әсәрләренә яңа яңгыраш бирә. Һичшиксез, Салих Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы», «Наемщик», «Кандыр буе», «Зәңгәр шәл», «Бишбүләк», «Күзләр» спектакльләренә язган арияләре, җырлары татар музыка мәдәниятенең классик әсәрләренә һәм милли мирасыбызның кабатланмас үрнәкләренә әверелде.

Республикабызның мәдәният тарихы сәхифәләренә күз салыйк: 1927 елда татар телендә радио эшли башлый, 1937 елда Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәм Татар дәүләт филармониясе оештырыла, шулай ук 1934 елда ТАССР җитәкчелеге Татар дәүләт опера театрын ачу турында карар чыгара. Болар барысы да татар музыка сәнгате үсешенә зур йогынты ясый.

Нәҗип Җиһановның «Качкын» (1939) һәм «Ирек» (1940), Мансур Мозаффаровның «Галиябану» (1940) операларының премьералары Татар дәүләт опера театрының ачылуын һәм иҗади эшләвен дәлилли торган зур вакыйгалар буларак тарихка керә. Әмма М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсының постановкасы белән бары тик 1956 елда гына тантаналы рәвештә ачыла.

1941 елда Мәскәүдә Татар сәнгате декадасы кысаларында Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсы һәм Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты куелырга тиеш була. Ләкин Бөек Ватан сугышы башлану әлеге гамәлне тормышка ашырырга комачаулый. Шуңа да карамастан, Фәрит Яруллинның беренче тәҗрибәсе буларак зур яңгыраш алган «Шүрәле» балетының премьерасы 1945 елда (композиторның вафатыннан соң) була. Бүгенге көндә дә «Шүрәле» балеты милли мәдәниятебезнең йөзек кашы буларак кабул ителә һәм дөньякүләм театрларда зур уңыш белән бара.

XX гасырның 1930–1940 елларында татар композиторлары туктаусыз иҗат итәләр һәм 1939 елда ТАССР Композиторлар берлеге оеша. Шуннан соң ТАССР Композиторлар берлеге чын мәгънәсендә татар музыка сәнгатенең үзәгенә әверелә. Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хабибуллин, Александр Ключарев иҗат иткән әсәрләр аны тагын да югары күтәрә.

Әйтергә кирәк, 1939 елда «Татар теле һәм әдәбияты фәнни тикшеренү институты» оештырылу милли музыка сәнгатен, традицион музыка мәдәниятен фәнни яктан өйрәнүгә зур этәргеч бирә. Күп кенә галимнәребез үзләренең фәнни эшләрен этномузыкология юнәлешендә эзлекле рәвештә алып бара башлыйлар. Шулар арасында

Я.М. Гиршман, М.Н. Нигъмәтҗанов, Р.А. Исхакова-Вамба, З.Н. Сәйдәшева һ.б. бар.

Татар мәдәнияте тарихында Бөек Ватан сугышыннан соңгы дәвер аеруча зур үсеш белән характерлана. Һичшиксез, әлеге үсеш 1945 елда Казан дәүләт консерваториясе ачылу белән дә бәйле була. Шулай ук 1958 һәм 1973 елларда Казан дәүләт консерваториясе СССР Фәннәр академиясенең филиалы буларак оешкан Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты белән берлектә үткәргән Идел, Урал, Төньяк Кавказ, Себер композиторлары һәм музыка белгечләренең I һәм II иҗади конференциясе кысаларында галимнәребез пентатоника биш баскычлы системасында музыканың киләчәге, аны фәнни яктан тикшерү проблемалары хакында фикер алыша.

XX гасырның икенче яртысында татар музыка сәнгате яңа баскычка күтәрелә. Рөстәм Яхин 1950 елда «Фортепиано һәм симфоник оркестр өчен концерт»ын яза. Бу әсәр милли мирасыбызның тагын бер энҗе бөртегенә әверелә. Профессиональ музыкантлар һәм тамашачылар аны яратып кабул итә. Бу концерт иң популяр классик әсәр исеменә лаек, дисәк тә ялгыш булмас. Мансур Мозаффаровның 1959 елда «Скрипка һәм симфоник оркестр» өчен иҗат ителгән әсәре татар музыкасы дөньясында концерт жанрын тагы да таныта.

Әйтергә кирәк, 1940–1950 елларда симфоник оркестр өчен язылган поэма, сюита, новелла, увертюра жанрлары аеруча популлярлаша. 1967 елда Натан Рахлин җитәкчелегендә симфоник оркестрның оешуына күпсанлы яңа симфоник әсәрләрнең тууы да зур этәргеч бирә. Симфоник жанрлар үсешенә бөек композитор Нәҗип Жиһанов үзенең саллы өлешен кертә: милли музыка сәнгатен ул 17 симфониясе белән баета. Симфоник оркестр өчен язылган әсәрләре арасында Н. Җиһановның «Сабантуй» симфониясе аеруча зур популярлык казана.

Алмаз Монасыйповның симфоник әсәрләре үзенә бертөрле фәлсәфи музыкаль драматургияга ия. Һәм без аны симфоник оркестр өчен заманча ысуллар белән оркестровканы эшли белүче зур профессионал, чын мәгънәсендә остаз дип атый алабыз. Алмаз Монасыйпов иҗат иткән дүрт симфония (аеруча «Муса Җәлил» симфониясе) – бу фикернең ышанычлы дәлиле.

1960–1970 елларда яшь буын татар композиторлары тамашачыны яңа әсәрләре белән шаккатыра. Алар арасында Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин, Рафаэль Белялов, Ринат Еникиев, Луиза Хәйретдинова иҗатлары аерылып тора. Ә бүгенге көндә иде алар – классик композиторларыбыз буларак, гәҗәеп бай милли музыкаль мирас калдырган горурланырлык шәхесләр.

1989 елда Композиторлар берлеге рәисе итеп композитор Рәшит Кәлимуллин билгеләнә һәм ТАССР музыка мәдәнияте өлкәсендә яңа чор башланып китә. Ул үзенең симфоник һәм камера-инструменталь әсәрләре белән дөньякүләм танылa һәм күпкырлы иҗаты белән

башкалардан аерылып тора. Әйтергә кирәк, Рәшит Кәлимуллин Россия күләмендәге халыкара музыка фестивальләренең, төрле музыкаль проектларның оештыручысы буларак та билгеле. Бүгенге көндә ул – Россия Композиторлар берлеге җитәкчесе.

1980 елларда яңа буын композиторларының әсәрләре татар музыкасына иҗади ташкын булып бәреп керә. Шамил Шарифуллин, Шамил Тимербулатов, Луиза Батыр-Болгари, Мәсхүдә Шәмсетдинова, Резеда Әхиярова иҗат иткән яңа һәм кызыклы әсәрләр татар җәмәгатьчелеген берничек тә битараф калдыра алмый. Аларның һәрберсе милли мәдәниятебез тарихында үзенең урынын таба. Әлеге чорда музыкаль жанрлар арасыннан симфоник картина, фреска, симфоник сюита, инструменталь концерт аеруча зур популярлык казана. Мәсәлән, Шамил Тимербулатовның «Утлы хәтер», «Ышаныч» симфония-ораторияләре, Резеда Әхиярованың «Ефәк юлы», «Тарих битләре», «Ак сөлге» симфоник поэмаларын атый алабыз.

XXI гасыр башы (2001) композитор Леонид Любовскийның Ренат Харис либреттосына нигезләнеп язылган «Йосыф турында риваять» балетының премьерасы белән башланып китә. Алга таба композитор Резеда Әхиярова һәм либретто авторы шагыйрь Ренат Харисның татар мәдәниятен милли әсәрләр белән баету нисбәтеннән аеруча нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге башланып китә. 2004 елда «Шагыйрь мәхәббәте» операсы, 2013 елда «Алтын Урда» балеты, 2018 елда «Сөембикә» операсы премьералары була. Әлеге әсәрләр профессионал музыкантлар, татар җәмәгатьчелеге тарафыннан бик җылы кабул ителә һәм тиз арада тамашачы күңелен яулап ала. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры постановкалар яхшы булсын өчен бөтен мөмкинлекләрне тудыра: премьераларны әзерләүгә тәҗрибәле режиссерлар, хореографлар, дөньякүләм танылган опера җырчылары җәлеп ителә. Әлбәттә, милли төсмерләр белән баетылган музыкаль сәхнә әсәрләре иҗат итү композитор Резеда Әхияровага зур танылу алып килә. Әлеге әсәрләр аның югары дәрәҗәдәге профессионал композитор булуын тагын бер кат раслый.

Яңа ысуллар ярдәмендә язу стилен булдыру – һәрбер иҗатчының хыялы. Музыка өлкәсендәге авангард юнәлешендә татар милләтен дөньякүләм таныткан композитор Софья Гобәйдуллина иҗаты аерым игътибарга лаек. Чөнки аның әсәрләре кабатланмас яңгырашка, үз стилен билгели торган оркестровка алымнарына һәм фәлсәфи идеягә корылган. Шунысы кызыклы, 1979 елда язылган «Ике торба өчен бәйрәм», «Сөембикә», «Татар җыры», 1992 елда иҗат ителгән баян һәм ике контрабас өчен «Татар биюе», шулай ук «Татар фольклоры буенча...» дип исемләнгән өч сюитадан торган цикл – милли һәм заманча музыка телен берләштергән әсәрләр.

Бүгенге көндә XXI гасырның талантлы яшь композиторлары арасында Лилия Таһирова, Светлана Зорюкова, Радик Сәлимов, Эльмира Галимова, Эльмир Низамов кебек сәнгатькярләр, милли музыкага яңа сулыш өрүен дәвам итә. Алар татар халкының тарихына күз ташлап,

мавыктыргыч сюжетка корылган яңа төр музыкаль жанрларга мөрәҗәгать итәләр, иҗатта заманча оркестровка һәм милли аһәңнәр кулланалар. Әлбәттә, киләчәктә кайсы әсәрләрнең тарихта лаеклы урын алачагын әлегә әйтүе кыен. Әмма шунысы куанычлы: яшь композиторлар тынгысыз иҗат утында янып эшлиләр.

Татар музыка мәдәниятендә зур иҗат юлы үткән һәм анда тирән эз калдырган дирижерларыбыз һәм солист буларак танылган музыкантларыбыз да бихисап. Алар арасында Натан Рахлин, Фоат Мансуров, Ренат Салаватов, Анатолий Шутиков, Рөстәм Абязов, Рубин Абдуллин, Александр Сладковский, Шәүкәт Әмиров, Евгений Михайлов, Рэм Урасинның исемнәре кемгә генә таныш түгел икән. Музыкаль театр өлкәсендә дан казанган опера җырчылары – Мөнирә Булатова, Асия Измайлова, Галия Кайбицкая, Мәрьям Рахманкулова, Усман Әлмиев, Нияз Даутов, Фәхри Насретдинов, Зөләйха Хисмәтуллина, Венера Шәрипова, Азат Аббасов, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Сәхәбиев – милли мәдәниятебезнең үз йөзен булдыру өчен зур хезмәт куйган шәхесләр.

ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан, Татарстан Республикасының дәүләт карамагындагы күп кенә мәдәният оешмалары һәм музыкаль коллективларының бүгенге көндәге иҗади эшчәнлекләрен дә билгеләп үтәргә кирәк. Чөнки алар татар мәдәниятен үстерүгә зур өлешл кертәләр һәм чит илләрдә безнең милли музыкаль мирасыбызны һәрдаим таныталар. Алар арасында М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры, Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры, Татарстан Республикасы Дәүләт халык уен кораллары оркестры, Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, «La Primavera» Казан камера оркестры, Татарстан Республикасының фольклор музыкасы Дәүләт ансамбле һ.б. бар.

Бүген мәркәзебез Казанда халыкара музыкаль проектлар үткәрелә, төрле сәнгать тармакларын берләштергән фестивальләр оештырыла. Бу, бер яктан, милли мәдәниятебезне таныту һәм үстерү өчен, икенче яктан, киләчәк буынга мирас булып калачак әсәрләрне, халык җәүһәрләре үрнәкләрен җиткерү йөзеннән эшләнә. Әлеге проектлар арасында Ф. Шаляпин, Р. Нуриев исемендәге фестивальләр инде үзенең иҗади тарихын булдырды. «Европа – Азия», «Созвездие – Йолдызлык», «Татар җыры», «Татар моңы» һ.б. башка фестивальләр төрле сәнгать юнәлешләрен пропагандалау буенча эшчәнлекләрен дәвам итәләр.

Әйтергә кирәк, һәрбер дәүләтнең йөзен билгеләүдә мәдәният өлкәсендәге сәясәтнең үтәлеше дә мөһим урын тота. Татар мәдәниятенең киләчәгенә һәрберебез зур өметләр баглый. Бер гасыр дәвамында мәдәнияттә булган үзгәрешләр, иҗат ителгән әдәбимузыкаль әсәрләр, барлыкка килгән яңа төр сәнгать юнәлешләре – барысы да бу өлкәнең ныклы һәм профессиональ дәрәҗәдә формалашуы, татар халкының горурланырлык милли мирасы булуы хакында сөйли.

**Әдәбият**

*Валиахметова А. Н.* Музыкальная культура в Татарстане (середина XIX века – первая четверть XX века): учеб. пособие. Изд. 2-е, доп. Казань: Изд-во ТГГПУ, 2009. 147 с.

*Нигмедзянов М. Н.* Татарская народная песня в обработке композиторов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1964. 140 с.

*Садрижиганов Д.Г.* В мире музыки (Воспоминания). Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 120 с.

*Сайдашева З.Н.* В мире татарской музыки: Сборник статей / Казанская консерватория. Казань, 1995. 220 с.

*Степанова А.Н.* Особенности становления профессионального музыкального образования в Республике Татарстан в начале XX века // Вопросы исторической науки: материалы II Междунар. науч. конф. (г. Челябинск, май 2013 г.). Т. 0. Челябинск: Два комсомольца, 2013. С. 29–31.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 81′22

***Җ.Ш. Сөләйманов,***
***А.Р. Гатиатуллин,***
***Р.А. Гыйльмуллин,***
***А.Ф. Хөсәенов***

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ЯҢА ИНФОКОММУНИКАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

В статье описывается деятельность Института прикладной семиотики Академии наук РТ по созданию программного инструментария и систем поддержки функционирования татарского языка в комьютерных технологиях. Представлены базовые результаты исследований и разработок в трех основных направлениях: татарская локализация систем и технологий; создание моделей, прикладных систем, сервисов и лингвистических ресурсов; когнитивное исследование лексико-грамматического потенциала татарского языка для создания новых компьютерных технологий. Приводятся результаты исследований и разработок в области создания русско-татарского машинного переводчика и речевых технологий для татарского языка.

**Ключевые слова:** инфокоммуникационные технологии, татарский язык, программные разработки.

The article describes the activities of the Institute of Applied Semiotics of the Tatarstan Academy of Sciences in creating software tools and systems for the Tatar language. The results of research and development in three main directions are presented: Tatar localization of systems and technologies; creation of models, application systems, services and linguistic resources; cognitive study of the lexical and grammatical potential of the Tatar language to develop new computer technologies. The results of research and development in the field of Russian-Tatar machine translation and speech technology for the Tatar language.

**Keywords:** infocommunication technologies, Tatar language, software tools.

Татар теленең аралашу теле буларак та, рухи байлык чыганагы буларак та яшәеше, үсеше, дәүләт теле буларак актив кулланылышта булуы турыдан-туры аның санак[1] технологияләрендәге, төрле социаль челтәрләрдәге активлыгына бәйле. Бүгенге көндә татар телен санак системаларында, Интернетта, мобиль җайланмаларда актив куллану өчен нәрсәләр эшләнгән, нинди системалар, технологияләр, ресурслар бар? Әлеге мәкаләдә шул сорауга җавап итеп Татарстан Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институтында башкарылган кайбер практик эшләр тасвирлана.

Әйтергә кирәк, беренчедән, татар теле өчен санак программалары төзү, аны Интернет челтәрләрендә куллану татар теленең абруен күтәрә, аны сакларга, өйрәнергә, үстерергә ярдәм итә. Икенчедән,

[1] Мәкаләдә компьютер технологияләренә бәйле терминнар авторлар тәкъдим иткән вариантта бирелә.

татар теленең дә технологияләрнең сыйфатын арттырырлык, аларны «акыллырак» итәрлек, интеллектуаль технологияләргә нигез булырлык зур потенциалы бар. Бу татар теле лексик-грамматик структурасының югары дәрәҗәдә закончалыклы, төзек, мантыйклы булуына бәйләнгән. Алга таба бу турыда да мәгълүмат бирелә.

Санак технологияләрендә татар теле мохитен булдыру 1980 еллар ахырында монитор (күрәк), принтер (басак) кебек периферия җайланмалары өчен беренче драйверлар, беренче татар шрифтлары, беренче татар тексты редакторы, беренче корректор, лингвист эш урыны программалары эшләүдән башланды. Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү Дәүләт программасы кысаларында 1993 елда Фәннәр Академиясенең һәм Казан дәүләт университетының уртак «Шәкли фәһем проблемалары» лабораториясе төзелде (фәнни җитәкчесе профессор Р.Г. Бохараев, лаборатория мөдире доцент Җ.Ш. Сөләйманов). 2009 елда Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Фәннәр академиясе Гамәли семиотика институты ачылды. Лаборатория традицияләрен дәвам итеп, институт түбәндәге өч төп юнәлештә фәнни-практик эшләр башкара:

1) санак системаларында татар телен куллану мөмкинлекләрен булдыру (санак технологияләрен татарчалаштыру);

2) татар теле өчен санак системалары һәм технологияләре эшләү, лингвистик ресурслар туплау (яңа технологияләрне татар теле өчен куллану);

3) татар теленең лексик-грамматик потенциалы нигезендә яңа санак системалары, яңа санак технологияләре, ясалма интеллект телләре эшләү (татар телен яңа технологияләр эшләү өчен куллану).

## 1. Санак системаларын татарчалаштыру

Санак системаларын татарчалаштыру дигәндә, иң элек, түбәндәге мәсьәләләр күз алдында тотыла:

– татар телен санакларда куллану стандартларын эшләү: татар хәрефләрен операцион системаларның код битләрендә урнаштыру; татар хәрефләрен төймәсарда (клавиатурада) урнаштыру;

– татар хәрефләрен төрле периферия җайланмаларында чагылдыру өчен драйверлар эшләү (күрәк (дисплей) драйверлары, санак (принтер) драйверлары, сканер драйверлары, төймәсар драйверлары);

– татар телендәге текстны бер имладан икенче имлага күчерүче программалар (конвертор) эшләү;

– операцион системаларның интерфейсын (экранга чыгарыла торган кулланучы белән аралашу текстларын, командаларны) һәм ярдәм текстларын татар теленә күчерү;

– операцион системадагы телләр опциясендә татар текстларының дөреслеген тикшерү мөкинлеге булдыру (корректор, спелчеккер);

– офис пакетына кергән программаларның интерфейсын һәм ярдәм текстларын, меню төймәләрендәге командаларны татар теленә күчерү;

– санак технологияләре өчен терминнар һәм төшенчәләр системасын эшләү, сүзлекләр төзү.

Санакларны татарчалаштыруның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын исбатлап торасы юк. Чөнки бүгенге глобальләшү, интернетлашу, челтәрләрдән чыкмыйча айлар буе аралашу заманында, цифрлашкан икътисадлар, электрон хөкүмәтләр, дәүләтләр төзелгәндә, сакланып калу өчен, татар теленең дә шул виртуаль дөньяда аралашу теле, дөньяны тасвирлау, танып-белү теле булуы зарур. Төрле электрон ресурсларда, тамгасарларда (мәгълүмат базаларында), әйтик, шул ук дөньякүләм китапханә – Википедиядә актив кулланылуы да телне үстерә, аның халыкара абруен күтәрә.

Татарстанда дәүләт теле булган татар телен информацион технологияләрдә, электрон дәүләт системасында рус теле белән бер дәрәҗәдә куллану, һичшиксез, аның сакланып калуына, үсешенә зур уңай йогынты ясый.

Бүгенге көндә санакларны татарчалаштыру мәсьәләсе, нигездә, тулаем чишелгән, ягъни татар телендә генә дә, башка арадашчы телләр кулланмыйча, санак системалары белән турыдан-туры аралашу, профессиональ мәсьәләләр чишү мөмкинлеге тормышка ашырылган, татар телендә электрон базаларда мәгълүмат туплау, эшкәртү, эзләү өчен ярдәмче программалар эшләнгән.

Фәннәр академиясе тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 1996 елда Татар телен санакларда куллану өчен стандартлар кабул итте. Шул стандартлар нигезендә «Шәкли фәһем» лабораториясендә монитор, клавиатура, принтер драйверлары, татар шрифтлары ясалды. Санак системаларын татарчалыштыру һәм татар телен эшкәртү өчен стандарт технологияләрне туплаган Татар Офисы 2001 дигән махсус программ пакет эшләнде һәм кулланышка кертелде.

Майкрософт фирмасы белән килешеп, әлеге стандартлар нигезендә Windows NT системасы һәм Офис-2000 пакеты татарчалаштырылды. Алга таба TATWIN драйверлар пакеты эшләнде. Хәзерге вакытта MS Windows’ның Windows 3.1-дән башлап Windows XP, Windows Vista, Windows 7, Windows 8, Windows 10 версияләре һәм аның барлык офис кушымталары татарчалаштырылган. Бу эшне башкарганда биш меңләп яңа термин һәм төшенчә гамәлгә кертелде, 800 меңнән артык сүз татарчага тәрҗемә ителде.

Хәзерге заманда мобиль электрон системалар массакүләм кулланышка керде. Шуннан чыгып, безнең институт та мобиль системалар өчен төрле кушымталарны татар теленә яраклаштыра, яисә турыдан-туры татар телендә эшли башлады. Татарча төймәсар, сүзлекләр, текст җыйганда ярдәм итүче программа (Predictive text input), уеннар, төрле системаларда (әйтик, iOS 7, Android 4+, WP 8.0–8.1) куллану өчен уку-укыту программалары, русча-татарча тәрҗемәче программа – шундый эшләнмәләрнең мисалы. 2016 елда Иннополисның «Ачык мобил Платформа» резиденты белән берлектә Linux-Sailfish

OS нигезендә мобил җайланмалар һәм планшетлар өчен төзелгән Аврора операцион системасына татар теле урнаштырыла башланды. Әлеге Sailfish Mobile OS Rus системасына татар теле рус теле белән бервакытта ике төп телнең берсе булып кертелде. Бу эш берничә этапта, операцион системаның үзеннән башлап, төрле кушымталарын да кертеп башкарылды. Беренче тәрҗемә ителгән материалның күләме 17000 сүз тәшкил итә.

Институт белгечләре ABBYY LS ширкәте белән берлектә татарчалаштырган тагын бер уникаль система – ул профессиональ тәрҗемәчеләр өчен Смарткат системасы. Профессиональ тәрҗемәләргә кулай инструмент буларак эшләнсә дә, Смарткат гади кулланучыга да тәрҗемә эшләрендә ярдәм итә. Күптөрле инструментлардан (Yandex, Tatsoft, Google тәрҗемә программалары, сүзлекләр һ.б.) торган санак платформасы эш процессын җайларга, проектлар төзергә, тәрҗемә ителгән сегментларны тикшереп барырга, тәрҗемәне төркем белән башкарырга мөмкинлек бирә. Тәрҗемә ителгән текст сегментларын тәрҗемәләр хәтерендә (Translation Memory) саклап калдыру мөмкинлеген Смарткатның иң төп өстенлеге дип әйтеп була. Бу системаны куллану тәрҗемәченең эшен 2–3 мәртәбә тизләтә. Бүгенге көндә Смарткат системасында «Рәсми Татарстан» аккаунты эшләп килә. Анда республиканың 63 оешмасы, йөздән артык тәрҗемәче теркәлгән. Алар тарафыннан, Смарткат системасын кулланып, агымдагы елның беренче дүрт аенда гына да 6 миллионга якын сүз тәрҗемә ителде.

Алда әйтелгәнчә, татарчалаштыру юнәлешендә төп мәсьәләләрнең берсе – ул яңа терминнар, яңа төшенчәләр тудыру. Чөнки бу процесс бик нечкә, бик җаваплы һәм ул – татар теленең нигезенә, аның лексик-грамматик төзелешенә тәэсир итә торган фәнни-практик мәсьәлә. Терминнарның дөреслеге, төгәллеге телнең бербөтенлеген, тотрыклылыгын тәэмин итә. Шулай ук, дөрес кулланылган яңа терминнар, төшенчәләр санак командаларының һәм меню тестларының аңлаешлы булуын, нәтиҗәдә, кулланучы куйган мәсъәләнең дөрес чишелүен тәэмин итә.

Санак терминнарын һәм төшенчәләрен тәрҗемә иткәндә, татар теле фәнендә тасвирланган кагыйдәләр системасы [Закиев, 1995] һәм үзебезнең тәҗрибәдән, эзләнүләрдән чыгып эшләнгән принциплар нигез итеп алынды [Сулейманов, 2006]. Төп кулланылган принципларга килгәндә, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– терминнарны, мөмкин кадәр, татар теленең бүгенге һәм тарихи лексикасыннан алу (мәсәлән, *санак – computer; санак (анахронизм) – алыш-бирешне киртләп бара торган көтүче таягы; йөкләү – download*);

– татар диалектларыннан сүзләр алу (мәсәлән, *тәрәз – window;* әдәби телдә: *тәрәзә*);

– татар телендә сүз ясалышы кагыйдәләрен кулланып, терминнар, төшенчәләр ясау (мәсәлән, *сайлак – menu, тамгасар – database, күрәк – display, күрсәр – cursor*);

– башка телдән кергән терминнарны татар теленең фонетика системасына турыдан-туры яраклаштыру (мәсәлән, *stack – стәк, стэк* түгел; *cash – кәш, кэш* түгел).

Биредә, мисал итеп, MS Windows системасын һәм аның офис кушымталарын татарчалаштырудан кайбер үрнәкләр китерелә.

Бу эш барышында түбәндәге эшләр эшләнде:

1) операцион системаның һәм аның офис кушымталарының интерфейсын тәрҗемә итү (мәсәлән, электрон почта, Windows Word, Excel кушымталары белән эшләгәндәге меню текстлары);

2) сайлак (меню) төймәләрендәге текстларны татарчага күчерү (Save, Open, Close, OK, Yes, Delete, Print һ.б.); ярдәм системасы файлларын татарчага тәрҗемә итү. Бу очракта терминнарга карата үтәлергә тиешле шартлар: а) татарча төшенчәләрнең һәм терминнарның табигый, дөрес, төгәл булуы, ике телдәге текстның да бер үк мәгънә белдерүе; б) терминнарның, төшенчәләрнең, сайлак төймәләрендәге текстларның кыска, аңлаешлы һәм дөрес булуы; в) белешмә файлларындагы текстларның, төшенчәләрнең, терминнарның җыйнак һәм аңлаешлы булуы.

Операцион системаны һәм офис кушымталарын татарчалаштыру – ул инглиз, я рус теленнән турыдан-туры тәрҗемә түгел, ә татар телле кулланучыга эшләү җайлы булсын өчен, бу системаны татар теленә иҗади яраклаштыру. Биредә үтәлергә тиешле мөһим шартлардан: барлык текстлар, кайсы телдә булуга карамастан, бертөрле кабул ителергә, кулланучыга карата итагатьлелек шартлары үтәлергә, бигрәк тә кулланучының һәм бу продуктны эшләүче фирманың хокуклары анык һәм аңлаешлы булырга тиеш. Шулай ук, продуктның яңа версияләрендә дә бер үк терминология системасы булу, ягъни алдагы версиялардәге терминнар һәм төшенчәләр саклану зарур.

Тәрҗемә иткәндә, татар телендә терминнар һәм төшенчәләр ясалуның классик принципларына өстәп, без тагын берничә яңа принцип кулландык. Шуларның берсе – «Шәкли оя» принцибы. Яңа сүзләрне татар сүзенең каркасыннан (матрицасыннан) ясау. Татар сүзе каркасына яңа сузыклар кертеп, яңа, татар телендә кулланылмаган, татар сүзлекләрендә булмаган, әмма татарча яңгырашлы сүз ясау бу.

Татар телендәге сүзләрне тартык авазлар арасына сузык авазлар «салынган» каркас (матрица, схема) дип күз алдына китереп була. Хәзерге әдәби татар телендә 9 сузык бар ([а] – [ә], [о] – [ө], [у] – [ү], [ы] – [е], [и]). Шуннан чыгып, әйтик, «*т-з*» каркасын сузыклар белән тутырганда ясалган сүзләр: *таз-тәз-тоз–төз-туз-түз-тыз-тез-тиз*. Биредә 9 мөмкинлектән 7 сүз татар телендә инде бар: *таз (тазик), тоз (соль), төз (стройный), туз (береста), түз (терпи), тез (строй), тиз (быстро)*. Шул ук вакытта, «*җ-л*» схемасы белән бер генә сүз ясала, ул да булса, *җил (ветер)* сүзе. Ә менә «б-н» структуралы татар теле сүзлегенә кергән бер генә сүз дә юк.

Шул ук «шәкли оя» принцибын кулланып, берничә иҗекле тамыр сүзләр дә ясап була. Мәсәлән, «*с-н-к*» каркасы нигезендә мөмкин

булган 28 сүздән сөйләмдә бары тик өчесе генә кулланыла: *сүник, сынык, сәнәк;* ә «т-р-к» каркасы өчен шундый 7 сүз бар: *тарак, тырык, төрик, төрек, тирәк*. Хәзерге вакытта санак технологияләрендә әлеге принцип белән ясалган берничә төшенчә гамәлгә керде: *күрәк* (*к-р-к*) (дисплей), *күрсәр* (*к-рс-р*) (курсор), *сайлак* (*с-йл-к*) (меню), *буяк* (*б-й-к*) (тонер), *турак* (*т-р-к*) (размелчитель бумаги). Шул ук *санак* (санак) сүзен дә «*с-н-к*» каркасы нигезендә ясалган сүз дип була.

## 2. Татар телен информацион технологияләрдә һәм электрон челтәрләрдә куллану өчен санак программалары

Әлеге фәнни-практик юнәлеш татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен күпкырлы эзләнүләр һәм программ пакетлар ясауны үз эченә ала. Санак кулланып эш кәгазьләре тутыру, аларны төзәтү, дөреслеген тикшерү, газета-журналлар чыгару, китаплар бастыру, белгечләрнең эш урыннарын автоматлаштыру, Интернетта мәгълүмат туплау, аны эшкәртү, эзләү, тәрҗемә итү, татарча яңгырату, татарча сөйләмне текстка күчерү һ.б. күп кенә программалар – шул эшләнмәләрнең үрнәге.

Мәгълүм булганча, татар морфологиясе бай һәм формаль дәрәҗәдә закончалыклы булуы белән аерылып тора. Шуңа да, санак технологияләрендә куллану өчен, татар морфологиясенең төрле модельләре эшләнелде.

Шундый модельләрнең берсе – ул татар аффиксаль морфемаларының структур-функциональ моделе. Бу модельдә татар кушымчаларының структур һәм функциональ сыйфатлары хакында тулы мәгълүмат тупланган. Аның нигезендә, практикада – санак технологияләрендә, морфология фәнен өйрәнгәндә куллану өчен, «Татар морфемасы» исемле программа ясалды [Сулейманов, 2003]. Хәзерге вакытта бу модельгә башка төрки телләр дә өстәлде һәм төрки телләр белән эшләү өчен махсус программаларны үз эченә алган Интернет-сервис – «Төрки морфема» исемле портал ясалып килә (рәс. 1). Порталда кулланылган модельнең төп үзенчәлеге – ул, беренчедән, төрки морфемаларының энциклопедик тулы мәгълүмат базасы булса, икенчедән, шуның үрнәгендә, төрки галимнәрнең үзләре катнашында тутырылган, эшкәртелгән, барлык төрки телләр тупланмасы булыр дип күзаллана.

Әлеге платформа төрки телләр арасында тыгыз мәгълүмат алмашу мөмкинлеге тудыра, кулланылган лексик-грамматик берәмлекләрне чагыштыру, тегларны унификацияләү мөмкинлеген бирә. Төрки телләрдәге текстлар, тел берәмлекләре белән төрле чагыштырма анализлар үткәреп, телләрнең никадәр якын булуын ачыклап була. Технологияләр күзлегеннән караганда, төрки телләрнең төзелеше ягыннан бер-берсенә якын булуы сәбәпле, бер төрки тел өчен эшләнгән программаны башка төрки телләр өчен дә кулланып булачак.

Бүгенге көндә практикада киң кулланышка кергән тагын бер гамәли системаларның берсе – ул Татсофт татарча-русча тәрҗемә




Рәс. 1. «Төрки морфема» порталы

системасы [Хусаинов, 2019]. Тәрҗемәче программалар төзү юлында без төрле технологияләр кулланып эшләп карадык: тәрҗемә ителгән текстлар (параллель текстлар) ярдәмендә дә, татар теле кагыйдәләре нигезендә дә, статистика ысулларына таянып та, төрле ысулларның комбинацияләрен кулланып та. Әлеге Татсофт тәрҗемә системасы дөньядагы иң алдынгы ясалма интеллект технологияләре ярдәмендә эшләнде. Соңгы 2–3 елда тәрҗемәче программа төзүдә нейрочелтәрләр архитектурасына нигезләнгән технологияләр уңай нәтиҗәләргә китерде. Хәзерге көндә Татсофт системасын 20 дән артык илдә 100 меңләп кеше куллана.

Текстларны татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү, Татсофт (translate.tatar) системасыннан тыш, шулай ук, Yandex. translate һәм Google.translate системаларында да башкарыла. Әлеге системаларның тәрҗемә сыйфатын ачыклар өчен, IBM хезмәткәрләре төзегән BLEU метрикасына нигезләнеп тест үткәрелде. BLEU күрсәткече 100 баллы шкала белән тәрҗемәләрнең сыйфатын бәяли. Бүгенге көндә актив кулланышта булган өч тәрҗемәче программаны сынау нәтиҗәләре түбәндәге таблицада китерелде (таблица 1).

Таблица 1.

| Тәрҗемәче | Русчадан татарчага | Татарчадан русчага |
|---|---|---|
| Yandex | 12.18 | 13.51 |
| **Tatsoft** | **26.52** | **25.60** |
| Google | 14.28 | 17.93 |

Әлеге таблицадан күренгәнчә, Гамәли семиотика институты хезмәткәрләре тарафыннан төзелән Татсофт системасының тәрҗемә сыйфаты бүгенге көндә башкаларныкыннан күпкә югары.

Гамәли семиотика институтында тагын бер мөһим һәм перспектив активлык – ул татар теленең тавыш синтезы һәм тавышны танып-белү программаларын төзү, шул юнәлештә актив фәнни эзләнүләр һәм практик эшләр башкару [Khusainov, 2017; Хусаинов, 2019]. Бу

юнәлештә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе – татар теленең махсус тамгаланган аудиобазасын булдыру. Хәзерге вакытта татар теленең санакта укылырлык итеп тамгаланган беренче аудиокорпусы эшләнде. Әлеге корпуска яңгырашлы 500 диктор язмасы кертелгән. Шуның нигезендә, ясалма интеллект технологияләре кулланып, татар теле акустик модельләре төзелде һәм өйрәтелде. Бу модельләр институтта эшләнүче татар сөйләмен танып-белү системасына нигез булып тора.

Шуңа өстәп, татар сөйләмен синтезлау программасы өчен профессиональ дикторлар укыган һәм тамгаланган 4 аудиокорпус әзерләнде. Шул аудиокорпуслар нигезендә, алдынгы нейрон челтәр технологияләре кулланып, махсус программа эшләнде. Әлеге модуль татар текстларын реаль вакыт агышында табигый һәм ятышлы итеп яңгыратырга (синтезларга) мөмкинлек бирә.

Үткәрелгән сынаулар яңгыратылган текстның (синтезланган сигналның) югары сыйфатлы – аңлаешлы һәм табигый булуын дәлилли. Татар текстларын яңгырату һәм танып-белү технологияләрен төзү юнәлешендәге уңышлар санак белән «сөйләшеп аралашу»га – сөйләм телен тәрҗемә итү, Интернеттан яңалыклар уку, мәгълүматны тавыш белән кертү һ.б. мөмкинләрне тормышка ашыруга юл ача.

### 3. Татар теленең лексик-грамматик потенциалын яңа информацион технологияләр ясау өчен куллану

ТР ФАнең Гамәли семиотика институтында әлегә теория буларак өйрәнелүче өченче юнәлеш – яңа интеллектуаль операцион системалар, яңа санак телләре, яңа санак программалары төзүдә төрки телләрнең, шул исәптән, татар теленең дә потенциалын, аның лексик-грамматик закончалыкларын, синтактик, семантик структурасы үзенчәлекләрен, шулай ук сүзләр байлыгын куллану күзлегеннән чыгып өйрәнү һәм когнитив модельләрен төзү. Мәгълүм ки, теләсә кайсы символик системаның нигезендә табигый тел менталитеты, аның структурасы, семантикасы ята. Математиканы, мантыйк фәнен, санак телләрен алганда да моның шулай икәнен күрәбез. Гуманитар фәннәрне тасвирлауда кулланылучы шәкли телләрнең нигезендә табигый телләр булуы аеруча ачык күренә. Аңлашыла ки, тел структурасы (морфология, синтаксис, семантика), аның лексикасы һәм башка шундый үзенчәлекләре белән бергә, тел менталитеты (төгәлрәк әйткәндә, телдә чагылыш таба торган этнос менталитеты) да формаль системаларага күчә.

Санак технологияләрендә кайсы характеристикалар, нинди күрсәткечләр иң мөһиме дигәндә, аның җавабы, әлбәттә, *мәгълүмат эшкәртү вакыты, мәгълүмат саклау өчен хәтер күләме, мәгълүмат-белемнең актив булуы* һәм *төгәл үк булмаган* (әмма контекстка карап аңлаешлы) *команда-боерык бирү мөмкинлеге булу*. Соңгы ике характеристика – интеллектуаль системалар һәм технологияләр өчен, гомумән, ясалма интеллект өчен бик мөһим һәм зарури сыйфатлар.

Шуңа да санак программалаштыру телләре, ясалма интеллект теле, шулай ук, мәгълүматны тасвирлау, туплау, саклау һәм эшкәртү телләре ясау өчен, табигый телнең мөмкинлекләрен, андагы закончалыкларны, аның лексик-грамматик төзелешен, семантик һәм прагматик потенциалын өйрәнү бүгенге көндә яңа информацион технологияләр ясау һәм куллану өлкәсендә иң актуаль һәм перспектив юнәлешләрнең берсе булып тора.

Билгеле булганча, актив кулланышта булган операцион системалардан алып, гади программа төзү теленә кадәр барысы да, төзелеше белән дә, яңгырашы белән дә, инглиз теле нигезендә, аның структурасына, аның закончалыкларына, лексикасына таянып, димәк ки, инглиз теле менталитеты нигезендә эшләнелгән дип әйтеп була. Инглиз теле флектив-аналитик тел, ягъни аффикслар сүзнең алдына да (префикс), уртасына да (инфикс), ахырына да (постфикс) кушылырга мөмкин. Шул ук вакытта, аның аналитик тел булуы морфологиясенең бик ярлы булуын күрсәтә, җөмләдә катлаулы мәгънә бирү сүзләрне аффикслар белән төрләндереп түгел, ә сүзтезмәләр аша башкарыла. Катлаулы мәгънәләрне сүзтезмәләр белән бирү анализ вакытында комбинаториканың үсүенә китерә. Ә бу, үз чиратында, исәпләү системаларында мәгълүмат эшкәрткәндә күбрәк вакыт һәм күбрәк оператив хәтер таләп итә. Нәтиҗәдә, системаның эффективлыгын тәэмин итү өчен, зур контекстлардан, тирән мәгънәле конструкцияләрдән баш тартырга туры килә, ә бу исә фразаның, җөмләнең катлаулы, тирән мәгънәле булуыннан ваз кичүгә, аны гадиләштерүгә китерә. Шулай итеп, әлеге лексик-грамматик үзенчәлекләре булу сәбәпле, Һинд-Европа телләреннең нигезендә санак системалары өчен «интеллектуаль тупик» ята. Һәм бу ситуация системаларның эффективлыгын арттыруны «акыллырак» итү юлы белән түгел, ә аларның тизлеген һәм хәтерен арттыру аша, экстенсив юл белән чишәргә этәрә. Башкача әйткәндә, ситуация системаның «аңын-акылын» түгел, ә «физик» мөмкинлекләрен үстерү аша чишелә.

Инглиз теле нигезендә төзелгән технологияләрнең тагын бер мөһим кимчелеге, инглиз теленең структурасы, аның синтаксисы интеллектуаль системаларның төп принципларыннан булган «мәгълүматның активлыгы» прицибына «карышуыннан», хәтта каршы килүеннән гыйбарәт. Һинд-Европа төркеменә керүче тел буларак, инглиз теленең җөмлә структурасы SVO (Subject-Verb-Object). Ягъни, җөмләдә башта субъект, аннары гамәл, һәм аннары гына мәгълүмат бирелә. Мәсәлән, *I will go to the cinema tomorrow afternoon with my friend ….* (Сүзгә-сүз тәрҗемә: *Мин барам кинога иртәгә дустым белән...*). Димәк, бу схема буенча, система башта гамәлне башкарырга, ә аннары гына мәгълүматны анализларга, эшкәртергә тиеш. Мәгълүмат нигезендә гамәл башкару түгел, ә киресенчә, гамәлдән чыгып мәгълүматны яраштыру килеп чыга, яисә, гамәл мәгълүматны бөтенләй әһәмияткә алмыйча башкарыла. Ягъни, тиешле гамәл мәгълүматны эшкәртү нәтиҗәсеннән чыгып башкарылмый, ә алдан

билгеләнгән гамәл, схемалардан, алгоритмнар таләбеннән чыгып мәгълүмат үзгәртелә, шул таләпләргә яраклаштырыла.

Һинд-Европа телләреннән аермалы буларак, төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең дә, җөмлә структурасы SOV (Subject-Object-Verb), ягъни «Субъект-Мәгълүмат-Гамәл» схемасы белән тасвирлана. Димәк, алда китерелгән инглиз җөмләсенең мәгънәсен татарча биргәндә, сүзләр бөтенләй башка тәртиптә кулланыла: *Мин* (I) ... *иртәгә* (tomorrow) *төштән соң* (afternoon) *дустым* (my friend) *белән* (with) *кинога* (to the cinema) *барам* (will go). Күргәнебезчә, татар җөмләсендә башта мәгълүмат тора, мәгълүмат эшкәртелә, ситуация анализлана, ә аннары гына җөмлә ахырында, анализдан соң, кагыйдә буларак, фигыль белән бирелгән гамәл куела. SOV форматындагы җөмлә төзелеше татарның менталитетын, фикер йөртү рәвешен дә чагылдыра: башта анализ, мәгълүматны эшкәртү, шуннан соң гына, шуның нәтиҗәсендә, гамәлгә күчү, фигыль белән бирелгән гамәлне үтәү. Димәк, татар теленең синтаксик структурасы интеллектуаль системалар өчен булган төп таләпкә тәңгәл килеп, информациянең (белемнең) актив булуын тәэмин итә.

Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институтында күп еллар дәвамында башкарылган эзләнүләр нәтиҗәсендә язылган фәнни мәкаләләрдә [Suleymanov, 2010] татар теленең, агглютинатив тел буларак, регуляр (автомат дәрәҗәдә формаль) морфологиясе, шул ук вакытта, тирән мәгънә чагылдырырык катлаулы, әмма конструктив һәм закончалыклы синтаксисы булуы белән, яңа программалаштыру телләре, интеллектуаль мәгълүмат эшкәртүче системалар, технологияләр төзү өчен нигез, эффектив инструмент булырлык потенциалы барлыгы исбатлана. Җөмлә төзелгәндә, сүзләр ясалганда һәм төрләнгәндә, сүз төзелешенең дә, җөмлә төзелешенең дә автомат дәрәҗәдә регуляр булуы вакыт һәм хәтер күрсәткечләренең минималь булуын, информация туплаганда һәм эшкәрткәндә системаның эффектив эшләвен тәэмин итә [Сулейманов, 1997]. Текстта бирeләсе мәгънәне, фикерне җыйнак итеп бирү мөмкинлеге татар телендә күп аффикслы бер сүз белән тирән мәгънә тасвирлап булуы аша аңлатыла. Флектив-аналитик телләрдә, әйтик, инглиз телендә, шул ук мәгънәне бирү өчен, берничә җөмлә кирәк булыр иде. Ә бу, үз чиратында, татар телендә бер җөмлә белән бирелгән бер үк мәгънәне инглиз телендәге берничә җөмләдән чыгару өчен эшкәртү, анализлау вакытын арттыра.

Йомгаклап әйткәндә, бүгенге көндә татар теленең Татарстан Республикасында чын мәгънәсендә дәүләт теле, фән теле, аралашу теле, ә виртуаль пространствода мәгълүмат туплау, мәгълүмат алмашу теле буларак яшәве – турыдан-туры аның санак технологияләрендә актив кулланылышына бәйләнгән. Моңа Татарстан Фәннәр академиясе Гамәли семиотика институтында гамәлгә ашырылучы проектлар дәлил булып тора.

**Әдәбият**

*Закиев М.З., Низамов И.М.* Правила образования, совершенствования и применения татарских терминов / Комитет при Кабинете Министров РТ по реализации Закона РТ «О языках народов РТ». Зам. председателя Комитета профессор М.З. Закиев, председатель терминологической комиссии Комитета, доцент И.М. Низамов. Казан, 1995. 13 с. (на татарском языке).

*Сулейманов Д.Ш., Галимянов А.Ф., Валиев М.Х.* Термины информатики и информационных технологий. Англо-татарско-русский толковый словарь (толкования на тат. яз.). Казань: Магариф, 2006. 383 с.

*Сулейманов Д.Ш., Гатиатуллин А.Р.* Структурно-функциональная компьютерная модель татарских морфем. Казань: Фэн, 2003. 220 с.

*Хусаинов А.Ф., Хусаинова А., Сулейманов Д.Ш., Гильмуллин Р.А.* К вопросу построения нейросетевой системы русско-татарского машинного перевода // Proceedings of the 7th International Conference on Turkic Languages Processing (TURKLANG-2019). (Simferopol, October 3–5, 2019). Simferopol, 2019.

*Khusainov A.* Recent Results in Speech Recognition for the Tatar Language // Text, Speech, and Dialogue, Lecture Notes in Artificial Intelligence. 2017. Volume 10415. P. 183–191.

*Хусаинов А.Ф.* Обзор созданных ресурсов и программных средств для синтеза татарской речи // Proceedings of the 7th International Conference on Turkic Languages Processing (TURKLANG-2019). (Simferopol, October 3–5, 2019). Simferopol, 2019.

*Suleymanov D.S.* Natural cognitive mechanisms in the Tatar language // In the Collection of the Vienna Proceedings of the Twentieth European Meeting in Cybernetics and Systems Research. Edited by Robert Trappel. Vienna, Austria, 6–9 April, 2010. P. 210–213.

*Сулейманов Д.Ш.* Татарский язык: его регулярность и типы нарушений // Сб. трудов Межд. конф. «Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность» (Казань, 9–13 июня, 1992 г., в трех томах). Т. 1. М.: Инсан, 1997. С. 55–60.

***Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы,***
*техник фәннәр докторы, ТР ФА Гамәли семиотика институты директоры*

***Гатиатуллин Айрат Рафиз улы,***
*техник фәннәр кандидаты, ТР ФА Гамәли семиотика институтының интеллектуаль информацион системалар бүлеге мөдире*

***Гыйльмуллин Ренат Абрек улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты, ТР ФА Гамәли семиотика институтының когнитив тикшеренүләр бүлеге мөдире*

***Хөсәенов Айдар Фаил улы,***
*техник фәннәр кандидаты, ТР ФА Гамәли семиотика институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81′373.421

***О.Н. Галимова***

# ДИАХРОН ҺӘМ СИНХРОН АСПЕКТЛАРДА ХАЙВАН АТАМАЛАРЫ СИНОНИМИЯСЕ

В статье прослеживается история некоторых синонимичных зоонимов: определяется время их лингвистической фиксации, рассматривается процесс отбора членов синонимического ряда, исследуется семантика отдельных слов, указываются модели дублетов. В парах, образованных по модели калька – термин с родовым компонентом, первые характеризуются компактностью, вторые – полнозначностью. и поэтому последние предпочтительнее. Вместе с тем образование названий животных с родовым компонентым в татарском языке является традиционным и может рассматриваться как проявление системности в терминологии.

**Ключевые слова:** терминология, терминосистема, названия животных, синонимия, дихрония, татарский язык.

The article traces the history of some synonymous zoonyms. The time of their linguistic fixation is determined, the process of selecting members of the synonymous series is considered, the semantics of individual words are examined, and models of doublets are indicated. In pairs formed by the model «loan translation – the term with a generic component» the first is characterized by compactness, the latter – by meaningfulness. And therefore the latter is preferable. At the same time, the formation of animal names with a generic component in the Tatar language is traditional and can be considered as a manifestation of systematic terminology.

**Keywords:** terminology, terminological system, animal names, synonymy, dichrony, Tatar language.

Татар тел белемендә төрле фән өлкәләренә караган терминологияне өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Мәсәлән, математика, физика, экономика терминнары, хайван атмаларының зур гына өлеше этимологик, структур, сүзьясалыш, номинатив, функциональ аспектларда тирәнтен өйрәнелгән. Әйтергә кирәк, бу тикшеренүләр, нигездә, синхрон яссылыкта башкарылган. Аларда билгеле бер чорга хас атамалар анализлана, ягъни телдә булган атамалар статик халәттә карала. Әмма терминология һәрвакыт үзгәрештә: кулланышта булган атамаларның семантикасы тарая, дифференциальләшү күзәтелә, яңа мәгънәләр барлыкка килә, телнең үз чаралары белән яңа сүзләр ясала, алынмалар үтеп керә. Галимнәр әйтүенчә, бары диахрон тикшеренүләр генә әлеге үзгәрешләрнең асылын ачыкларга, гомумән, терминосистемаларның ?терминнар системаларының формалашу үзенчәлекләрен билгеләргә һәм киләчәктә үсеш юлларын фаразларга мөмкинлек бирә. Махсус атамаларны тәртипкә салуның алшарты булып та терминологиянең тарихын өйрәнү тора [Герд, б. 31]. Шуңа да терминологик системаларны диахрон яссылыкта өйрәнү тел белемендә актуаль мәсьәләләрдән санала.

Тәкъдим ителгән мәкаләдә татар телендә беренче тапкыр хайван атамаларының синонимиясе диахрон һәм синхрон аспектларда өйрәнелә. Мәкаләдә татар телендә зоология терминологиясенең үсеш закончалыкларын билгеләү максатыннан, кайбер синонимик рәтләрнең тарихы тасвирлана. Дублетларны, вариантларны теркәү вакыты күрсәтелә, зоонимнардагы семантик үзгәрешләр ачыла һәм синонимик рәтләрдәге күчешләр карала. Фәнни тикшеренүнең актуальлеге һәм яңалыгы әнә шулар белән билгеләнә. Анализлана торган чыганаклар корпусын 1801–2019 еллар аралыгында чыккан төрле сүзлекләр, үзөйрәткечләр, дәреслекләр, фәнни-популяр әдәбият тәшкил итә.

Билгеле булганча, гомумкулланылыштагы теләсә кайсы сүз термин була алмый. Терминологлар махсус атамаларны мәгънәсе, кулланылышы, формасы ягыннан билгеле бер сыйфатларга ия булырга тиеш дип күрсәтәләр. Семантик яктан аларның бер генә мәгънәле, тулы мәгънәле һәм синонимнарсыз булуы шарт [Гринев-Гриневич, б. 31–32]. Бу таләпләрнең барысына да җавап биргән атамалардан торган системалар камил системалар булыр иде. Әмма терминологиядә, телнең бер катламы булганга күрә, полисемия дә, синонимия дә күзәтелә. Татар терминологы Ф. Фасеев билгеләп үткәнчә, «терминологиядә синонимнар булмаска тиеш дигән таләп – ул әле бик абстракт куелыш; ул идеаль бер максатка омтылу ягыннан файдалы һәм терминология үзенең туктаусыз үсешендә шуңа омтыла» [Фасеев, б. 53]. Тиңдәш атамаларны функциональ яктан өйрәнү дә икенче атаманың кирәклеген күрсәтә. Ул фикерне төгәл җиткерергә, атамага (бигрәк тә алынмаларга) фәнни аңлатма бирүгә хезмәт итә, текстта кабатлаулардан коткара [Пилецкий, с. 116]. Шулай да терминнар синонимиясе гомумтел сүзләре тиңдәшлегеннән аерыла. Терминологиядә, башлыча, бер үк фәнни объектны атаган сүзләр – дублетлар [Ахманова, с. 13–14] күзәтелә. Әмма мәгънәсе белән бер-берсенә тулысынча туры килгән дип бәяләнгән абсолют синонимнарда да [Татар лексикологиясе, б. 196], кайбер галимнәр әйтүенчә, тәңгәллек шартлы, алар – семантик һәм функциональ яктан бары якын, эквивалентлыгы өлешчә генә булган берәмлекләр [Иванов, с. 341].

Терминологияне диахрон яссылыкта өйрәнү анда макро- һәм микроэволюцион характерда үзгәрешләр булуын күрсәтә. Ике чорга мөнәсәбәттә зур аерма, сикерешле үсеш булганда, сүз макроүзгәрешләр турында бара. Болардан яңа ысуллар белән сүз ясалу, яңа атамалар барлыкка килүне әйтеп үтәргә кирәк. Икенчеләре – эзлекле, акрынлап барлыкка килгән, зур булмаган үзгәрешләр. Терминологик дублетлар да микроүзгәрешләргә керә дип санала [Мякшин, с. 26].

Бер үк хайванның ике яки аннан да күбрәк атама белән исемләнүе күп кенә чыганакларда чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Борынгы төрки сүзлек»тә «фил» мәгънәсендә – *Fil, Jaγan, Jaŋa* сүзләре, «маймыл» мәгънәсендә *kejlig, bičin* сүзләре теркәлгән [ДТС, с. 194, 233, 295, 98]. XIX гасыр – XX гасыр башы сүзлекләрендә һәм үзөйрәткечләрендә дә шундый атамалар табыла. Ләкин алар күп түгел. Мәсәлән, И. Гиганов

сүзлекләрендә: *балцыргай – сукыр чыргай* ‘мошка’, *бүгаляк – елан* ‘змей’ [Гиганов, 1801, б. 46], *хайван – аң* ‘зверь’, *керүвитъ – кыскацъ* ‘рак’ [Гиганов, 1804, б. 191; 484], А. Троянский сүзлегендә: مار – يلان ‘змей’, *бүдәнә – быдбылдык* ‘перепел’ [Троянский, 1833, с. 317; Троянский, 1835, с. 181, 211], Г. Чәләбинең «Татарско-русские разговоры» хезмәтендә *тавшанъ – коянъ* ‘заяц’, *сератан – кыскыч* ‘рак’ [Челеби, с. 37, 39], С. Кукляшев сүзлегендә كربه ‘кот кошка’, ماچى ‘кошка’, مشق ‘кошка’, مار – يلان ‘змей’ [Кукляшев, с. 83, 85, 90, 87, 104] кебек парларда атамаларның мәгънәсе тәңгәл дип теркәлгән. Телдә бер үк мәгънәдә кулланыла торган сүзләр К. Насыйри тарафыннан да китерелә: آهو – غزال ‘газель’, ‘кабан’, ‘зверь’, قصقچ – صرطان ‘рак’ [Насыри, б. 29, 62, 54, 173].

Сүзлекләрдә хәзерге күзлектән караганда искергән, диалекталь сүзләр дә, ялган синонимнар да (*әфгый* ‘змей, полоз’, *кара елан* ‘змей’, يلان , مار *елан* ‘змей’; *карчыга – лачын* ‘ястреб’) бар. Шулай да фәнни хезмәтләрдә тиңдәш атамалар төгәлрәк сайланган. Мәсәлән, Н. Износковның С. Рахманколый тәрҗемәсендә татар телендә дөнья күргән «Тарих табигый» хезмәтендә *гади куян – ак куян* ‘беляк’, *челән – чапур* ‘цапля’, *умарта – бал корты* ‘пчела’, *гади чуар күбәләк – кычыткан күбәләге* ‘капустная белянка’ [Износков, с. 2, 54, 118, 125], «Мөкәммәл хайванат атласы»нда очраган *арслан маймылы – уйнак* ‘игрунка’, *эт башлы ярканат – зурканат* ‘крылан’, *Америка капланы – пума* атамалары шундыйлардан [Мөкәммәл хайванат атласы, б. 74]. Күренә ки, кайбер дублетлар XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына инде формалаша һәм шуннан соң чыккан хезмәтләрдә тотрыклы кулланыла. Мәсәлән, *гади куян – ак куян* ‘беляк’, *гади чуар күбәләк – кычыткан күбәләге* ‘капустная белянка’, *өй куяны – йорт куяны* ‘кролик’, *бута – төя баласы* ‘верблюжонок’ шундыйлардан. Терминологиядә халык авыз иҗаты әсәрләрендә үк күренгән *умарта – бал корты* ‘пчела’ (*умарта, кечкенә булса да, бал ташый, карга, зур булса да, тирес ташый; бал корты бал алыр чәчәген белә*) тиңдәшлеге дә урын ала. Бу елларда дублет классификация терминнары да күренә башлый: *канат куллы хайваннар – ярканатлар* ‘рукокрылые’, *озын борынлы хайваннар – филләр* ‘хоботные’ [Хәмиди, б. 16, 17].

XX гасырның 10 нчы елларына К. Насыйри сүзлегендә чагылыш тапкан *аһу – газәл* ‘газель’ синонимик пары таркала. *Аһу* атамасы бары сайгакны (сайгаклар ыругы) гына белдерә башлый, *газәл* зоонимы белән газәлләр ыругыннан булган хайван атала [Хәмиди, 1910, б. 68]. Соңрак бу мәгънәдә *җәйрән* сүзе дә кулланыла. Ә инде XX гасырның 50 нче елларыннан рус теле аша кергән *газель* атамасы күзәтелә [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1950, б. 38].

Татар терминологиясен халыкка якынайту өстенлек алган 1920–1930 елларда [Татар лексикологиясе, б. 185] хайван атамалары өлкәсендә синонимия күренеше, яңа зоонимнар эшләнсә дә, зур

үсеш алмый. Авторлар бер хайванны бер генә атама белән атауга өстенлек бирәләр. Мәсәлән, *Австралия керпесе* ‘ехидна’, *диңгез гөмбәсе* ‘актиния’, *су капкачлы бакасы* ‘речная ракушка’ [Зоология, Хайванат, 1925, б. 275]. Бу чорда *хамелеон – яһүд тәвәсе; урман тавыгы – кыргавыл* һәм тулы һәм кыска *Африка кыр аты – кыр аты* ‘зебра’ атамаларының синонимиясе күзәтелә [Кәрим, Әхмәдеев, б. 132; Хәмиди, б. 31]. Җ. Вәлиди төзегән аңлатмалы сүзлектә дә синонимия күренеше чагылыш таба. Галим хайван атамаларын еш кына синонимнары аша аңлата: *аш бакасы* ‘устрица’ *(Моңа диңгез бакасы да диләр, аш бакасы диюләре ашарга яраклы булудан)* [Вәлиди, б. 78].

XX гасырның 30 нчы елларыннан хайван атамалары системасында макроэволюцион үзгәрешләр күзәтелә. Яңа атамалар ясалу, телгә алынмалар керү сәбәпле, дублетларның саны арта, триплетлар барлыкка килә.

Сүзлекләрдә һәм махсус әдәбиятта яңа синоним атамалар теркәлә: *көн качар коңгыз – бызылдавык* ‘жуженица’, *озынборын – черки* ‘комар’, *канәфер коңгызы – шпан коңгызы* ‘шпанская муха’, *филчек – озын авыз* ‘слоник – долгоносик’ [Атамалар сүзлеге, б. 20, 28, 80, 63, 30], *кәркәдан – борынмөгез* ‘носорог’ [Табигать һәм биология, б. 66], *соры бака – үлән бакасы* ‘травяная лягушка’, *ала тритон – гади тритон* ‘тритон обыкновенный *или* прудовой’, *тере тудыручы кәлтә, тау кәлтәсе* ‘живородящая ящерица’, *яр карлыгачы – керәшә* ‘береговая ласточка’, *ягылбай – бүзтургай* ‘кобчик’, *су үгезе – бугай* ‘выпь’, *урман кулигы – шөлди* ‘вальдшнеп’, *коралай – кыр кәҗәсе* ‘косуля’, *ас – кара койрык* ‘горностай’, *куш аяк – ялман* ‘тушканчик’ [Юсупов, б. 84, 94, 106, 154, 164, 204, 169, 206, 342]. Дублетларның бер өлеше алынма – туган тел сүзе (*дафния – су борчасы* [Цузмер, б. 90], *гну – ат үгез* ‘гну’ [Табигать һәм биология, б. 26], *нанду – Америка дәвә кошы, гавиал – Һиндстан тимсахы*, *бегемот – су аты* ‘бегемот’ [Юсупов, б. 220, 124, 279]), сирәргәк туган тел сүзе – алынма (*болыт – губка* ‘губка’ [Табигать һәм биология], *Австралия керпесе – ехидна, Америка тимсахлары – кайманнар* [Юсупов, б. 251, 124]) моделендә ясала. Мондый синонимик парларда ана тел атамалары алынмаларның мәгънәсен ачуга хезмәт итә. Бу үзенчәлек чит телдән кергән зоонимнарның аңлатмаларында бик ачык чагыла: «*Нанду* – муены һәм башы мамык йон белән капланган, канаты куе күперенке каурыйлы, өч бармаклы аяклы, яхшы йөгерә һәм йөзә, әмма оча алмый торган Көньяк *Америка тәвә кошы*» [Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге, б. 257].

Халык авыз иҗатында тиңдәш мәгънәдә тотрыклы кулланылган *күке – кәккүк* ‘кукушка’ *(Күке кычкырса, су җылына. Кәккүк яз көне агачлар яфрак яргач та кычкырса, ачлык булыр), тартай – тартар (Бер тартарга дөнья тар. Карга теләгән теләшкән тартай үзенә давыл китергән)* орнитонимнары дублетлар буларак махсус әдәбиятта [Юсупов, б. 195], сүзлекләрдә урын ала башлый. Бу елларда ук

*күке* орнитонимы деривацион яктан отышлырак дип табыла, классификация терминнары шуннан ясала: *күкесыманнар* [Табигать һәм биология, б. 48], *күкеләр* [Юсупов, б. 171]. «Буй-буй төстәге Африка кыргый аты» мәгънәсен белдергән сүзне туган тел нигезендә ясау һәм аның кулланылышын ныгыту омтылышы дәвам итә. Яңа сүз фәнни әдәбиятта алынма атама белән тәңгәллектә бирелә. Шул рәвешле яңа синонимнар барлыкка килә: *ала ат – зебра* ‘зебра’ [Юсупов, б. 277].

Зоология фәненең үсеше бары тик фән теленә хас синонимнарның – гади, чын, төп сүзләре белән ясалган тәңгәл төр атамаларының артуына сәбәпче була. Махсус әдәбиятта *гади песнәк – зур песнәк* ‘синица обыкновенная’, *гади тилгән – кара тилгән* ‘коршун’, *чын челәннәр – төп челәннәр* ‘цаплевые’ [Юсупов, б. 152, 164, 203] атамалары тәңгәл мәгънәдә кулланыла башлый.

Бу елларда классификация терминнарына зур игътибар бирелә. Барлыкка килгән дублетларның зур гына өлешен нәкъ менә алар тәшкил итә. *Сайраучылар – төрле тавышлылар* ‘певчие птицы’, *кычкыручылар – бер тавышлылар* ‘кричащие’, *коңгызлар – каты канатлылар* ‘жуки, жесткокрылые’, *маймыллар – дүрткуллылар* ‘четверорукие’ [Юсупов, б. 149, 144, 151, 355].

Дәреслекләрдә триплетлар күренә башлый. Мәсәлән, *пеликан – баба кош – сәда кош* ‘пеликан’, *селёдка – җүләр балык – тиле балык* ‘селёдка’. Алар да, безнеңчә, телдәге хайван атамаларын барлау, отышлы терминны сайлап алу омтылышына бәйле. Мәсәлән, Ф. Йосыпов *талпан – урман бете – кош бете* атамалары арасыннан соңгы икесен фәндә куллану хаталы дип таба [Юсупов, б. 116]. Синонимия мәсьәләсе еш кына полисемия белән бәйле була. Дөрес терминны сайлау атамаларның семантикасын, куллану үзенчәлекләрен өйрәнүне таләп итә. Атамалар өлкәсендә шул рәвешчә эшләү синонимик рәтләрне дә үзгәртә. Мәсәлән, бу елларда күзәтелгән *пеликан – баба кош – сәда кош* триплетындагы орнитонимнар турында Ф. Йосыпов болай ди: *Бу кошка [пеликан] тагын сәда дип йөртәләр, сәда дип щегольларны да йөртү сәбәпле пеликаннарны уртак исем булмаганга баба дип йөртү артык күрелде* [Юсупов, б. 197]. Шулай итеп, триплет дублетка таркала. «Атамалар сүзлегенә» теркәлгән *урман тавыгы – суер* ‘глухарь’ [Атамалар сүзлеге, б. 14; *чаг.* Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1971, б. 58] орнитонимнарының тәңгәллеге тотрыклы булмау *урман тавыгы* атамасының рус телендәге *тетерев* сүзенең эквиваленты буларак та теркәлүенә бәйле [Атамалар сүзлеге, б. 70; Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1971, б. 235]. Рус телендә *глухарь* һәм *тетерев* дип аталган кошларның татар телендә бер үк төрле атала алмавына галимнәр шул ук елларда игътибар итә. Мәсәлән, Ф. Йосыпов зоология дәреслегендә бер орнитоним белән бер генә кошны атый: *кыр тавыгы* ‘куропатка’, *көртлек* ‘тетерев’, *суер* ‘глухарь’ [Юсупов, б. 189]. «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»ндә дә (1939) атамалар семантик

яктан аерыла: *суер* атамасы рус телендәге *глухарь* орнитонимының, *урман тавыгы* атамасы *тетерев* орнитонимының эквиваленты итеп бирелә [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1939, б. 148]. Соңрак Э. Сафина *урман тавыгы* атамасына синоним итеп төрки телләрдә кулланылган *озан* орнитонимын китерә [Сафина, б. 119, 147].

Терминнар өлкәсендәге эзләнүләр фонетик вариантларны (*дөя – төя* ‘верблюд’ [Табигать һәм биология, б. 18]) теркәүдә, хаталы синонимнар (*чукмарбаш – ташбаш* ‘головастик’ [Табигать һәм биология, б. 26]) булдыруда да күренә.

1940–1960 елларда да, интенсив рәвештә булмаса да, алынмаларның татарча эквивалентларын булдыру эше дәвам ителә. Яңа атамалар фәнни, фәнни-популяр текстта, таныш булмаган сүзне кыскача аңлату максатыннан, алынма парлары белән бирелә. Мәсәлән, *керпе-чебен – тахин*, *су борчасы – дафния, кыргый баран – муфлон* [Шалаев, Рыков, б. 71, 88, 254], *лемминг – чуар тычкан, канналар – болан-үгезләр* [Смирнов, б. 56, 131], *ихтиозавр – балыккәлтә, тередо – краб тишкече* [Шаксель, б. 28, 46]. *Су борчасы* һәм *дафния* синонимик парында төп атама итеп беренчесе сайлана. *Дәвә кошы* һәм *страус* парында алынма активлаша, ул яңа атамалар ясауда катнаша башлый: *Австралия страусы – эму* [Смирнов, б. 135]. Фәнни-популяр әдәбиятта *табан балыгы – кәрәкә* ‘карась’, *үр куяны – ак куян* ‘русак’ дублетлары урын ала [Смирнов, б. 12; 72]. «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»нә *саранча, чикерткә* инсектонимнары да синоним буларак теркәлә [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1950, б. 161]. Әлеге күренешнең тарихи нигезе бар: *чикерткә* атамасының «саранча» мәгънәсендә кулланылган булуы да мәгълүм [Әхмәтьянов, б. 435]. *Кызыл таракан – чуар таракан – камка* ‘божья коровка’ триплеты теркәлә [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1950, б. 19]. Бу елларда бары тик алынмалардан торган дублетлар (*шамбы – жумба* ‘налим’ [шунда ук, б. 109]), кыска һәм тулы вариантларның синонимиясе (*башмакчык – инфузория-башмакчык, Аскания мериносы – Аскания нечкә йонлы сарыгы* [Шалаев, б. 21, 254], *имезүчеләр – имезүче хайваннар* ‘млекопитающие’ [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1950, б. 103]) күзәтелә башлый.

XX гасырның 70 нче елларыннан соң синонимик рәтләрнең саны тагын да арта. Мәсәлән, 1971 елда басылып чыккан «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»нә 40 тан артык дублет, дүрт триплет, бер фонетик вариант (*борча* / *бөрчә* ‘блоха’) теркәлгән. Синонимнарның бер өлешен халыкка киң таныш булган атамалар тәшкил итә, алар арасында диалектизмнар да күренә: *йон бете – йонкояр – чәчкояр* ‘власоед’*, эт балыгы – этләч* ‘вьюн’*, ләрге балык – зәңгелә балык* ‘гольян’, *опты – аҗау* ‘жерех’, *табан балык – кәрәкә* ‘карась’, *лачын – шонкар* ‘сокол’; *суалчаннар – бабасырлар* ‘глисты’. Синонимнарның алынма һәм туган тел сүзе моделендә барлыкка килүе дәвам

итә: *белуга – кырпы балыгы* ‘белуга’, *кролик – йорт куяны* ‘кролик’. Синонимлык токым атамаларында да саклана: *ангор кролигы – ангор куяны* ‘ангорский кролик’. Сүзләрне калькалаштыру нәтиҗәсендә дә күп кенә синонимик рәтләр барлыкка килә. Татар терминологы Ф. Фасеев атамаларны калькалаштырудан бигрәк ыруг компоненты белән ясауны дөресрәк дип саный [Фасеев, б. 88–89]. Ыруг төшенчәсен белдергән сүз белән яңа атама ясау – төрки телләргә хас күренеш [Галимова, б. 66]. XX гасырның 70 нче елларыннан татарча яңа атамалар ясау әнә шул юнәлештә дә алып барыла. Сүзлекләргә алар калькалар белән бергә теркәлә. Мәсәлән, *купшыл – купшы чыпчык* ‘щёголь’, *алтынкүз – соры чебен* ‘златоглазик’, *тиреләч – кызыл ярканат* ‘кожан’ [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1971, б. 264, 81, 97]. Тиңдәш атамаларны янәшә бирү ыруг компоненты белән ясалган зоонимнарның семантикасы төгәлрәк ачылуын, бер төрдәге яки охшаш хайваннарга атама бирүдә борынгыдан килгән милли нигезгә корылган сүз ясау ысулының отышлырак булуын күрсәтә. Әмма терминология кыскалыкка омтылганга, компактлы калькалар ешрак кулланыла.

Ыруг компоненты алынмалар янында килеп тә шул ук алынма атамалар белән дублетлар ясый. Мәсәлән, *салака – салака балыгы* ‘салака’, *ак леггорн – леггорн тавык* ‘белый леггорн’, *шпанка – шифан – шпан чебене* ‘шпанка’ [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, 1971, б. 204, 115, 262].

Бу чорда атамаларның семантикасын төгәл билгели алмау сәбәпле туган дублетлар, триплетлар кыскара. Мәсәлән, *камка* сүзенең 1950 еллар өчен хас синонимнары терминологиядән төшеп кала. *Байгыш* атамасы, киресенчә, *ябалак* ‘сова’, *мәче башлы ябалак* ‘филин’ атамалары белән ике синонимик рәт барлыкка китерә [Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге, б. 248]. *Бөркет* орнитонимына мәгънәдәш булган тагын ике атама теркәлә: *бөркет – каркош – самраукош* ‘орел’ [Русча-татарча биология терминнары сүзлеге, 1972, б. 72].

Зоология терминологиясенең 80 нче еллардагы үсешен 1985 елда чыккан «Русча-татарча биология терминнары сүзлеге» күрсәтеп тора. Синоним атамалар яңа дублетлар һәм триплетлар хисабына арта. XIX гасыр ахыры – XX гасырның 40 нчы елларына кадәр махсус әдәбиятта очраган атамаларның активлашуы күренә, алар алынмалар белән дублетлар хасил итә (*бегемот – су сыеры* [Русча-татарча биология терминнары сүзлеге, б. 19]). Аерым синонимик рәтләрнең компонентлары үзгәрә: *кырмыска арслан – бөҗәк арслан* ‘лев муравьиный’, *яшел коңгыз – сирень коңгызы – сасы коңгыз* ‘мушка шпанская’ [Русча-татарча биология терминнары сүзлеге, б. 91, 107]. Тулы һәм кыска вариантлардан торган парларда кыскалары, ешрак кулланылу сәбәпле, сүзлекләргә беренче итеп теркәлә: *хордалылар – хордалы хайваннар* ‘хордовые’, *чуртан – чуртан балык* ‘щука’, *умырткасызлар – умырткасыз хайваннар* ‘беспозвоночные’, *кәлтә – кәлтә елан*

‘ящерица’*, ялгыз кысла – ялгызак* ‘рак-отшельник’ [Русча-татарча биология терминнары сүзлеге, б. 184, 192, 21, 198, 145]. Бу исә терминнарны кыскалык таләпләренә буйсындырудан килә булса кирәк.

XX гасырның 90 нчы еллары – терминологик синонимиянең кискен үсеш алган чоры. Бу елларда классификация терминнарын эшләүгә игътибар арта, сүзлекләргә дә, дәреслекләргә дә алар, кагыйдә буларак, тиңдәшләре белән керкәлә. Мәсәлән, «бөҗәкләрнең – каты алгы канатлары булган *коңгызларның* яки *катыканатлыларның* табигатьтә очраулары бик гади» [Биология, 1994, б. 98]. «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»кә тупланган синонимик атамаларның да 45% ын отряд, семьялык, ыруг атамалары тәшкил итә. Бу татар теленә генә хас күренеш түгел. Рус телле чыганакларда да, шул исәптән «Биологиядән энциклопедик сүзлек»тә дә, классификация атамаларының синонимиясе еш күзәтелә. Хезмәтләрдә дублет һәм триплетларның сүзгә-сүз тәрҗемәләрен бирү (*моллюсклар – йомшактәнлеләр* ‘моллюски – мягкотелые’, *чүкеч башлылар – ышыклык кошлары* ‘молотоглавые – теневые птицы’), безнеңчә, зоология терминнары системасына хас синонимиянең гомуми бер чагылышы булып тора. Алынма – алынма, алынма – туган тел сүзе (шул исәптән гомумтөрки сүзләр), туган тел сүзе – алынма, туган тел атамасы – туган тел атамасы моделендәге синонимнар милли җирлектә төрле генетик катламнарга караган, төрле чаралар белән ясалган атамалардан формалаша. Теге яки бу хайванны атау өчен шул телдә атама булмаганда, бары тик алынмалардан торган дублетлар һәм триплетлар хасил була. Мәсәлән, фин-угор теленнән алынма *шамбы* һәм чыгышы ачык билгеле булмаган *жумба* ихтионимнарыннан [Әхмәтьянов, б. 479] торган дублет бу елларда, алынма *налим* ихтионимы да активлашу сәбәпле, триплет булып китә [Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек, б. 380]. *Эфа – әфгый* ‘эфа’ алынма герпетонимнары татарлар өчен экзотик булган еланны атауда бер үк дәрәҗәдә кулланыла. Чит телләрдән кергән атамаларның ана тел сүзләре белән тәңгәллеге татар теленә генә хас күренеш түгел. Әмма һәр телдә дә бер үк алынма теге яки бу атама белән дублет хасил итми. Татар телендә бу елларда *чуллык – бекас* ‘бекас’ (чаг.: азәрб. *cüllüt, bekas* ‘бекас’), *сөмбаш – сёмга* ‘сёмга’ [Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек, б. 57, 119], *кырпы балыгы – белуга* [Ханбикова, Сафиуллина, б. 66] атамаларының синонимиясе күзәтелә. *Җизбаш – бакыр кәлтә* ‘медянка’, *кара елан – зәһәр елан* ‘гадюка’, *укбаш – сәврүк* ‘севрюга’ дублетларындагы һәр зооним туган телдә барлыкка килгән, алар хайванны төрле билгеләренә карап атау нәтиҗәсе булып тора. *Эрбетче – эрбет чыпчыгы* ‘кедровка’ [Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек, б. 255], *шөпшәашар – шөпшә кошы* ‘осоед’, *арсланбөҗәк – кырмыска арысланы* ‘лев муравьиный’ [Азбука природы, с. 26] синонимик парлары калька һәм ыруг компоненты белән ясалган хайван атамаларыннан торалар. Соңгы елларда чыккан сүзлекләрдә дә тиңдәш атамалар зур урын алып тора. Аларда инде тотрыклашкан

дублетлар да, яңалары да теркәлә (*арыслан башлы алтын балык – арысланбаш* ‘львиноголовая золотая рыбка – львиноголовка’, *күктүш – чуартүш – көяз сандугач* ‘варакушка’ [Галимова, б. 25; Сафина, б. 116]).

Гомумән алганда, синонимия – зоология терминологиясендә киң таралган күренеш. Фән алга киткән һәм шул өлкәнең терминологиясе тирәнрәк эшләнгән саен терминологик синонимия дә үсә генә. Тәңгәл мәгънәле хайван атамалары татар телендә узган гасырның 30 нчы һәм 90 нчы елларында бик күп теркәлә. Алар, нигездә, дублетлар, сирәгрәк, триплетлар хасил итә. Синонимнарны булдыруда ана тел атамаларының катнашу-катнашмавыннан чыгып, дублетларның берничә моделен күрсәтергә мөмкин: 1) туган тел сүзе – туган тел сүзе. Аларның бер өлеше халык авыз иҗаты әсәрләрендә үк күзәтелә. Фән теле атаманың икесен дә кабул итә. Әмма деривацион яктан отышлырагы, ешрак кулланылганы өстенлек ала; 2) алынма – алынма моделе. Ул, нигездә, экзотик хайваннарны атауда, теге яки бу хайванны атау өчен телдә атама булмаганда формалаша һәм сирәк очрый; 3) алынма һәм туган тел сүзләреннән торган алынма – туган тел сүзе, туган тел сүзе – алынма модельләрендәге синонимнар кайсы сүзнең доминанта итеп сайлануын күрсәтеп тора; 4) калька – ыруг компоненты белән ясалган атама моделендәге парларда беренчеләре кыскалык ягыннан аерылып торса, икенчеләре семантиканы тулы, төгәл ачуы белән ота. Әмма терминның кыскалыгы тел нормаларына буйсынырга [Фасеев, б. 88] һәм мәгънәгә зыян китермәскә тиеш. Атамаларның борынгы калып белән ясалуы исә терминологиядә системалылыкның бер күренеше булып санала. Атамаларның структурасына бәйле тулы һәм кыска вариантларның синонимиясе терминологиядә кыскалыкка омтылуның бер чагылышы булып тора.

**Әдәбият**

Азбука природы: насекомые и др. позвоночные // Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов. Казань: Магариф, 1997. 95 с.

Атамалар сүзлеге (авыл хуҗалыгы һәм урманчылык атамалары). Казан, 1931. 83 б.

*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов. М.: Советская энциклопедия, 1966. 608 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. Т. 2. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек / ред. Ф.Г. Ситдыйков, Р.К. Зәкиев. Казан: Мәгариф, 1998. 655 б.

Биология: Хайваннар: Урта мәктәпнең 7–8 классы өчен дәреслек / Ф.Г. Иштирәкова, Р.Г. Шакирова тәрҗ. Казан: Мәгариф, 1994. 272 б.

Вәлиди Җ. Татар теленең тулы сүзлеге. Казан: Татарстан мәгариф комиссариатының гыйльми үзәге басмасы, 1927. Т. 1. Ч. 1. 352 б.

*Герд А.С.* Основы научно-технической лексикографии. Л.: Изд-во ЛГУ, 1986. 69 с.

*Галимова О.Н.* О родовом компоненте в названиях животных (на материале татарского языка) // Тюркское языкознание XXI века: лексикология и

лексикография: Материалы международной конференции. Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 65–67.

*Галимова О.Н.* Балык атамаларының татарча-русча-латинча аңлатмалы сүзлеге. Казан: ТӘhСИ, 2019. 204 б.

*Гиганов И.* Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку, собранные в Тобольской главной школе учителем татарского языка, Софийского собора священником Иосифом Гигановым и юртовскими муллами свидетельствованные. СПб., 1801. 75 с.

*Гиганов И.* Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище, учителем татарского языка И. Гигановым и муллами юртовскими. СПб.: Имп. АН, 1804. 627 с.

*Гринев-Гриневич С. В.* Терминоведение: учеб. пос. для студ. высш. учеб. заведений. М.: Академия, 2008. 304 с.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Иванов А.В.* Метаязык фонетики и метрики: дис. … д-ра филол. наук. Северодвинск, 2004. 632 с.

*Износков Н.А.* Тарих табигый. 1 кис. Хайванат / тәрҗ. С. Рахманколый. Казан: Сабах, 1908. 158 б.

*Кәрим С., Әхмәдеев Г.* Зоология (Хайванат). 1–2 бүлекләр. Казан: Татиздат, 1925. 405 б.

*Кукляшев С.* Словарь к татарской хрестоматии, составленный С. Кукляшевым. Казань: Университетская типография, 1859. 106 с.

Мөкәммәл хайванат атласы. (Басылган шәһәре, нәшрияты, елы билгесез.) 76 б.

*Мякшин К.А.* К вопросу об изучении терминологических систем в диахронии / Наука и образование. 2016 https://cyberleninka.ru/article/n/k-voprosu-ob-izuchenii-terminologicheskih-sistem-v-diahronii/viewer (дата обращения: 06.02.2020)

*Насыри К.* Полный русско-татарский словарь, с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке, как научные термины. Казань: И.Н. Шамсутдинов, 1904. 64 с.

*Пілецький В.І.* Деякі лінгвістичні проблеми українського термінознавства // Український правопис і наукова термінологія: проблеми норми та сучасність: матеріали засідань Мовознавчої комісії і Комісії всесвітньої літератури НТШ у Львові 1996–1997 рр. Львів: Наукове товариство ім. Т. Шевченка у Львові, 1997. Т. 9. С. 116–117.

Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге. Казан: Татгосиздат, 1939. 176 б.

Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге / Г. Әхмәтов, М. Гыймадиев. Казан: Татгосиздат, 1950. 210 б.

Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге / төз. А.К. Тимергалин. Казан: Татгосиздат, 1971. 303 б.

Русча-татарча биология терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 198 б.

*Сафина Э.И.* Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге. Казан: ТӘhСИ, 2018. 184 б.

*Смирнов К.С.* Хайваннар турында очерклар. Казан: Татгосиздат, 1940. 146 б.

Табигать һәм биология терминнары / ред. М. Корбан. Казан: Татгосиздат, 1935. 123 б.

Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 510 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

*Троянский А.* Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии, священника Александра Троянского: в 2-х т. Казань: Университетская типография, 1833. Т. 1. 629 с.

*Троянский А.* Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нем речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии, священника Александра Троянского: в 2-х т. Казань: Университетская типография, 1835. Т. 2. 340 с.

*Фасеев Ф.С.* Татар телендә терминология нигезләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 200 б.

*Хәмиди И.* Рәсемле гыйлеме хайванат. Рөшдия мәктәбе өчен дәреслек. 2 басма. 1 кис. Казан, 1910. 124 б.

*Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 1999. 256 б.

*Цузмер М. Я.* Зоология. 6–7 класслар өчен д-лек / тәрҗ.: Н. Асманов. Казан: Татиздат, 1933. 243 б.

*Челеби А. К.* Татарско-русские разговоры. С присоединением к ним пословиц, басен, образцов для сложений и спряжений татарских слов. Казань: Типография Н. Коковина, 1848. 151 с.

*Шаксель Ю.* Терлек һәм аның җир йөзендә таралышы / Р. Бикбулат тәрҗ. Казан: Татгосиздат, 1941. 88 б.

*Шалаев В.Ф., Рыков Н.А.* Зоология: урта мәктәпнең 7 классы өчен дәреслек / тәрҗ. С.Ш. Фәйзуллина. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 288 б.

Ысулы җәгърафия. Казань: Типография Торгового Дома «Бр. Каримовы», 1905. 176 б.

*Юсупов Ф.* Зоология дәреслеге. Умырткалы хайваннар: 2 нче баскыч мәктәпләр, педтехникумнар, һәм рабфаклар өчен дәреслек. Казан: Татиздат, 1930. 366 б.

***Галимова Ольга Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.51:82-1/-9

*Д.Ф. Заһидуллина*

# Г. ИБРАҺИМОВ – ӘДӘБИЯТЧЫ: ЯҢА ЧЫГАНАКЛАР (15 томлык академик басманың 6–7 томнары басылу уңае белән)

Статья написана по случаю появления новых томов 15-томного академического издания знаменитого писателя, видного государственного деятеля и литературоведа Галимджана Ибрагимова. В ней делаеся попытка определения новизны томов и издания вообще, анализируются материалы 6 и 7 томов.

**Ключевые слова**: Г. Ибрагимов, академическое издание, история литературы, теория литературы, литературная критика.

The article is written on the occasion of new volumes of 15-volume academic publication of the famous writer, a prominent statesman and theorist of literature Galimdzhana Ibragimov. The article attempts to determine the novelty of volumes and of the whole edition, analyzes materials from 6 and 7 volumes.

**Keywords:** G. Ibragimov, academic publication, history of literature, theory of literature, theorist of literature.

Һәрбер чорда милли мәдәниятнең үзәк юлын билгеләгән, асылын-эчтәлеген хасил иткән шәхесләр була. Аларның тарихи-мәдәни мирасы исә еш кына бер халык рухи, гаклый байлыгы белән тәңгәлләшергә дә мөмкин.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты узган 80 еллык юлда, башка бик күп фәнни мәсьәләләрне хәл итү белән бергә, шундый күп шәхесләрнең иҗади һәм гыйльми мирасын татар халкына кайтару башкарыла. Гомумән, оешканнан алып бу юнәлеш Институт коллективының төп эшләү юнәлешләреннән булып кала. Кол Гали, М. Болгари, Өмми Кәмал, Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Г. Утыз Имәни, Акмулла, К. Насыйри, Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, М. Гафури, Г. Камал, Ш Мөхәммәдев, З. Һади, Һ. Такташ, Ш. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Колахмәтов һ.б. тагын бик күп язучыларның әсәрләре – томлыклар, сайланма әсәрләр булып, хрестоматияләрдә, вакытлы матбугатта нәкъ менә Институт хезмәткәрләре эзләнүләре нәтиҗәсендә дөнья күрә, халыкка мәгълүм була һәм алтын хәзинәбездә үз урынын ала.

Татар мәдәниятенең кыйммәтле мирасында урыны аерата кадерле булган шәхесләр арасында күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы, галим Г. Ибраһимов та бар. Шәхес культы юкка чыгарган зыялыны аклау хакындагы карар чыгуга (1955 елның 24 сентябре) [Галимджан Ибрагимов..., 2012, с. 76], аның иҗат мирасын кайтару комиссиясе оеша, Институтта өч томлык сайланма әсәрләрен басмага

әзерләү эше башлана. Бу китаплар 1956 елны басылып та чыгалар. Г. Халитнең, Х. Хәйринең, М. Хәсәновның һ.б. галимнәрнең язучы тормышы-иҗатына багышланган, томнарга анализ ясаган мәкаләләре дөнья күрә. М.Х. Хәсәнов тарафыннан кандидатлык [Хәсәнов, 1961] һәм соңрак докторлык [Хасанов, 1971] диссертациясе яклана, монографияләре укучыларга тәкъдим ителә [Хасанов, 1977; 1969]. Мирасның зурлыгы, байлыгы исә галимнәрне Г. Ибраһимов әсәрләрен сигез томда әзерләү ниятенә китерә. 1974–1987 елларда әлеге томлыклар редакцион коллегия (М. Хәсәнов, Х. Хәйри, Н. Юзиев) һәм томнарны төзүчеләр (аеруча А. Шамов, Р. Гайнанов, Г. Камалиев, Х. Гобәйдуллин, С. Алишев, Ф. Фасеев, Л. Гайнанова) тырышлыгы белән дөнья күрә һәм татар мәдәниятенә Галимҗан Ибраһимов дигән дөньяны ача [Ибраһимов, 1974–1987].

Әмма бу чор – совет дәвере, текстология гыйлеме никадәр генә үсеш кичермәсен, совет идеологиясе, аның цензурасы мирасны кайтару эшчәнлеген турыдан-туры күзәтү астында тота. Галимнәр бүген, әлеге чор истәлекләрдә калгач, аерым бер зыялылар мирасының әзерләнгән 4 томыннан – берсе басылу, яки 4 томлыкның – 2 томга калуы хакында ачынып сөйлиләр. Хәтта 1986 елны, 100 еллык юбилей көннәренә әзерләнгән Г. Тукай, Ф. Әмирхан томнары да шактый киселеп, сайланып кына нәшер ителә. Г. Ибраһимовның 8 томлыгы да мондый телгәләүләрдән читтә кала алмый.

Бары тик советтан соңгы чорда гына әлеге вазгыять бетерелеп, мирасны тулы килеш кайтару мөмкинлеге туа. Шуннан файдаланып, Институтта Г. Тукайның 6 томлык тулы академик басмасы әзерләнә. Бу яктан, Институт коллективының гаять зур һәм мактаулы хезмәте – күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы Гаяз Исхакыйның әдәби мирасын кайтаруны да искә төшерергә кирәк. 1993 елның 26 апрелендә Татарстан хөкүмәте Г. Исхакый әсәрләренең 15 томда бастыру турында карар кабул иткән була. Текстология бүлеге хезмәткәрләре Г. Исхакыйның төрле жанрларга караган әдәби, публицистик, тарихи-сәяси текстларын, аның турындагы әдәбиятның фәнни библиографиясен төзи, күп чыганаклардан (китаби басмалар, газета һәм журналлар, архив материаллары) Г. Исхакый текстларын барлап, псевдонимнарын ачыклап, җыйнап, укып, кулдан гарәп графикасында язылганнарын (язуының тану өчен авыр булуын да әйтик) беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертеп, һәр текстка аңлатмалар һәм искәрмәләр язып басмага әзерли [Исхакый, 1998–2014]. Әлеге 15 томлыкка шулкадәр байлык тупланган ки, татар мәдәни галәме әле аны тулысынча аңлап һәм бәяләп тә бетерә алмады. Дөрес, ике гасыр чигендә әдәби мирасы буенча диссертацияләр яклану, монографик хезмәтләр басылып чыгу, конференцияләр уздырылу Исхакыйны язучы буларак ачарга һәм бәяләргә ярдәм итте. Әмма аның иҗтимагый-сәяси карашлары һәм эшчәнлеге, политологик, милли мәсьәләләрдә фикерләре, публицистикасы үз тикшеренүчеләрен, бәяләүчеләрен көтә.

Г. Ибраһимовның 15 том тәшкил итәрлек мирасын бастырып чыгару фикере дә советтан соңгы чор биргән мөмкинлектән файдалану омтылышы белән бәйле иде. Нәтиҗәсе булып, узган 2018 елда Г. Ибраһимовның 15 томлык академик «Әсәрләр»енең 1–5 томнары дөнья күрә. Алар язучының әдәби иҗатын тулы килеш күзалларга мөмкинлек бирә. Томнарга язучы әсәрләренең вариантлары да, өйрәнчек текстлар да, үз заманында цензура кискән өлешләр дә, моңа кадәр кирилл хәрефләрендә басылмаган әдәби әсәрләр дә тупланган.

2019 ел ахырында исә 6–10 томнар укучы кулына тапшырылды. Безнең сүзебез дә шул хакта булыр. Чөнки бу томнар Г. Ибраһимов эшчәнлегенә һәм мирасына да, шәхесенә дә карашны бик нык үзгәртәләр. Иң беренче чиратта, бу томнарда беренче тапкыр җыйнап укучыга тәкъдим ителгән материаллар Г. Ибраһимовның әдәби, тәнкыйди, фәнни эшчәнлеге бер максатка – татар дөньясын үзгәртү, алга җибәрү, торгынлыктан чыгару, аерым бер юнәлешләрдә аның үсешенә хезмәт итү максатына буйсынганлыкны гаять калку итеп ассызыклый.

Әйтик, 6 нчы томга әдәбиятка һәм сәнгатькә кагылышлы 1910–1914 еллар аралыгында язылган мәкаләләр, хезмәтләр тупланган. Аларның саны – 25, шулардан 9 ы (өчтән бере!) әдипнең басмаларына беренче тапкыр кертелә. Моңа кадәр күптомлыклардан читтә кала килгән язмалар Ибраһимовның әдәбият-мәдәниятkә, гомумән дөньяга карашы, яшәү кредосы-фәлсәфәсе, зәвыге, идеаллары турындагы күзаллауны киңәйтәләр. Алар яшь иҗатчының газета-журналлар сәхифәләрен милләт хәле хакында сөйләшү, аның үсеше өчен кирәк булган мәсьәләләргә җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтү, шул юл белән чишү мәйданы итеп каравы хакында сөйли.

1910–1914 еллар – Казанга күчеп килеп, мөстәкыйль тормыш итә башлаган 23 яшьлек егетнең шәхес буларак ныгыган, үзен татар дөньясына таныткан чоры. Әдәбият-сәнгатькә кагылышлы язмаларында Г. Ибраһимовны зур әдип һәм фикер иясе, милләтпәрвәр һәм көрәшче итеп өлгертәчәк омтылышлар аермачык күренә. Казан университетына керергә әзерләнү өчен дәресләр ала башлаган яшь Ибраһимов 1910 елның гыйнварыннан «Йолдыз» газетасы белән хезмәттәшлек итә. Мөхәррире – Әхмәтһади Максуди, сәркатибе Галиәсгар Камал булган бу басма (15.01.1906–21.06.1918) татар җәмгыятендәге һәм дөньядагы яңалыкларга сизгер булуы белән аерылып тора, һәр вакыйга яки хәл, хәтта шәхесара мөнәсәбәтләр шунда ук аның сәхфәләрендә яктыртыла. Бер үк вакытта «Йолдыз» милли идеяләргә киң мәйдан бирә. Әйтик, Г. Тукайның 30 лап шигыре, берничә мәкаләсе шушы басмада дөнья күрә [Габдулла Тукай, 2016]. «Йолдыз» газетасы сәхифәләрендә каләм чарлап, Г. Ибраһимов әдәбият тәнкыйтьчесе, тарихчысы, теоретигы булып җитешә.

Беренче дөнья күргән («Йолдыз»ның 1910 елгы 12 гыйнвар саны) «Татар матбугаты» дигән мәкаләсендә XX йөз башы милли-мәдәни тирәлегенә шактый киң колачлы бәя бирелә. 1905–1909 еллар

аралыгындагы әдәби барышка караш тулы булмаса да (әйтик, бу чорда әдәбиятка тәэсире зур булган Ш. Мөхәммәдевлар, Ш. Камаллар һ.б. әдипләр телгә алынмый), шактый төгәл. Шунысы мөһим, Г. Ибраһимов бәяләү ноктасында тукталып калмый: ул шигъриятне, поэзияне әдәбиятның таҗы санаган татар укучысына дөнья күләмендә эпик әсәрләрнең кыйммәтле булуын искәртә: «һәр милләт әрбабе каләм эчендә нәсер язучыларын, иң алгы сафка чын романчы һәм хикәячеләрене куядыр» [Ибраһимов, 2019, т. 6, б. 31]; Пушкиннарны, Байрон, Гюголарны телгә алып һәм эпик әсәрләрнең милләтне күтәрүен әйтеп, аларга карата мөнәсәбәтне үзгәртергә чакыра. Шул рәвешле, күзәтү мәкаләсе кебек язылган текст милли яңгыраш ала: аның авторы укучыга татар җәмгыятенең мәдәни хәле хакында сөйли, әдәбият мәйданындагы уңай һәм кимчелекле күренешләргә игътибар итә һәм үсеш перспективаларын билгели!

Газетаның 26 февраль һәм 4 март саннарында басылган «Рәссамлык» мәкаләсендә татар җәмгыятендәге яңарыш күренешләре санап-барлап барыла: «милли матбугат туды, «журналистларымыз», «әдип, шагыйрь вә педагогларымыз бар», дәреслекләр языла, мәктәпләр ачыла, нәшрият эше тармаклана; театр куела, әдәбият кичәләре уздырыла, «татар композиторлары да бар»; китапханәләр, уку заллары ачыла, җәмгыятьләр оеша… Шушы рәттән сиздермичә, үтешли генә әйтелгән кебек нечкә ирония катыш көлү дә яңгырый: «“Русское знамя”ны уздырырлык “Дин вә мәгыйшәт”емез вә Пуришкевичтән рәхмәт әйттерерлек кадимчеләремез бар» [Ибраһимов, 2019, т. 6, б. 33]. Әлеге фонда Ибраһимов рәссамлык мәсьәләсен – «шул яңа вә мәдәни эшләр белән бергә туарга тиеш булып та, ни өчендер тумый калган бер нәрсә хакында вә халкымызга бөтенләй әҗнәби булган бер мәсьәлә»не күтәрә. Аның фикеренчә, татар мәдәнияте үссен өчен, аның рәссамнары һәм башка халыкларга да күрсәтерлек гүзәл рәсемнәре булырга тиеш! Язма авторы талантлы татар яшьләренең игътибарын шуңа юнәлтә.

Әлеге ике язма янәшәсендә Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре» дип аталган күләмле мәкаләсе («Йолдыз»ның 1 апрель, 3, 8 июнь һәм 1911 елгы 10 февраль саннары) дә татарда булмаган фәннәрне – әдәбият теориясе һәм әдәбият тарихын булдыру омтылышы кебек кабул ителә.

Мәкаләдә Г. Ибраһимов үз дәвере татар әдәбиятына кискен тәнкыйди якын килә. З. Бәшири, М. Укмасый шигырьләрен бөтенләй яраксызга чыгара, М. Гафури һәм Н. Думавида тезмә сөйләм ярыйсы булса да, «шигърият», ягъни әлеге өч сыйфат юк дип саный. Аныңча, С. Рәмиев шигырьләрендә хис тә, образлылык та бар, ләкин нәзым камил түгел – матурлык җитми. Өч яктан да канәгатьләнерлек шигырьләр Г. Тукайда дип күрсәтелә. Татар шигъриятенә, гомумән алганда, тирәнлек, тематик киңлек җитмәү ассызыклана.

Мәкаләнең үз эчендә автор әдәбият теориясе, кануннары фәне дөньяга килү вакыты җиткәнен, моңа татар әдәбиятында ихтыяҗ

барлыгын ассызыклый. Аныңча, соңгы елларда матбугат үсеше әдәбиятны күтәрелешкә китерде. Ләкин яхшы, чын әдәби әсәрне ясалма, түбән дәрәҗәдәге әсәрдән аерырлык зәвык юк. «Моның өчен, бер яктан, чын шигырьләрне тәхлил илә күздән кичереп, гыйльми сурәттә тәмйиз куәсе үзләштерергә, икенче яктан, шуның үзенә гаид булган каванине нәзарият белән танышырга лаземдер; мәгаттәәссеф, бездә әле буның икесеннән берсе дә юктыр» [Ибраһимов, 2019, т. 6, б. 49] дип, теориянең әдәби зәвык булдыру, әсәр бәяләү, укучыны эстетик тәрбияләү бурычын көн тәртибенә куя. Бу мәсьәләгә караган махсус китаплар булырга тиешлекне искәртә.

«Мәктәптә әдәбият» (1913) мәкаләсендә, мәктәп-мәдрәсәләрдә милли тел-әдәбият укытуның төзек системасын бер-берсенә ялганган, үсә баручы биш өлеш итеп төзеп, туган телне һәм әдәбиятны укыту җиңелдән авырга, кисәктән бөтенгә күчү тәртибендә булырга тиеш дип билгели. Әлеге предметларны укытуга бәйле хәл-халәткә тукталып, Ибраһимов дәреслекләр булмауга, әмма алар өчен ихтыяҗ туганлыкка да игътибар итә.

Әдәбият теориясеннән дәреслеккә рецензия итеп язылган «Баттал әфәнденең «Нәзарияты әдәбиясе»» (1913) язмасын да Г. Ибраһимов шушы милли ихтыяҗ турындагы фикердән башлап җибәрә, татар әдәбияты теориясе фәне нинди булырга тиеш дигән сорауга җавап эзли. «Тәрҗемә һәм аның шартлары» язмасында тәрҗемә өчен татар халкы психологиясенә туры килгән әсәрләр сайлау, туган телгә җайлаштырып тәрҗемә итү, тәрҗемә өчен сайланган текстларның эчке рухын, идеясен, хисләр бөтенлеген җиткерә белү кебек таләпләр хакында сүз алып барыла.

Ибраһимов башка халыкларның тормышын, күренекле шәхесләрнең үз милләте өчен башкарган хезмәтләрен үрнәк итеп куйган язмалар белән дә чыгыш ясый. «Госманлы музәсенең мөдире мәрхүм Хәмди бәк җәнабләре» (1910), «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикадчы В.Г. Белинский җәнабләре хакында» (1910), «Каһарман шагыйрь» (1914), «Әхмәд Мидхәт әфәнде (Ризаэтдин Фәхретдин әсәре)» (1914) язмалары шундыйлардан. Аларда күренекле әдәбият-сәнгать әһелләренең үз халкының фикер-аңын үстерүгә керткән өлеше, милләтпәрвәрлеге югары күтәрелә.

1911–1912 елларда Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив эшли, аның тәнкыйть мәкаләләре һәрчак текстлардагы кимчелекләрне җентекләп күрсәтүе белән аерылып тора.

«Әдәбият агымы» (1913) күзәтү характерындагы мәкаләсе «Олуг кешеләр һәм аларның әсәрләре» китабы басылып чыгу уңаеннан языла. Китаптагы беренче, Г. Гобәйдуллин хезмәте Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренә кагыла. Аны бәяләгәнче, Г. Ибраһимов Исхакый иҗатына күз ташлап уза. Аның фикеренчә, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» язучының башка әсәрләреннән темасы белән дә, әдәбилеге җәһәтеннән дә югары булса да, аннан соң иҗат ителгән «Зиндан», «Солдат», «Тормышмы бу?» кебек әсәрләрендә тупаслану

күренә, үтә зәвыклылык, «табигый агымлы хыял», «фикер нәзәкатлеге» югала.

Г. Гобәйдуллинның фәнни хезмәтенә анализ гаять җентекле, әсәрне дә, аны тикшерүгә куела торган таләпләрне дә ачык белеп язылган. Ибраһимов хезмәттә Исхакый әсәренең иҗтимагый проблематикасы яхшы тикшерелүгә игътибар итә, төп идеянең төгәл билгеләнүен искәртә. Татарларның бетүенә сәбәп булачак дип күрсәтелгән биш күренешнең («икътисадый, сәяси, җәгърафи, әдәби, гыйльми, дини һәм рухи») арасыннан дини сәбәп, исламият мәсьәләсенә тукталa һәм тәнкыйтьченең Исхакыйны «дин илә фәнне килештерергә йөрегән ислам реформаторларының берсе»; ул динне «мөкаддәсләрнең мөкаддәсе» дип танучы итеп каравы белән килешми, аны исламның «кодисиятенә ышанып түгел, тик халыкны, үзенең ышанган нәрсәсе белән димләп, тәрәкъкый юлына кертү җиңелерәк булганга, аны тәмәдден» [Ибраһимов, 2019, т. 6, б. 84], ягъни мәдәниятле булу юлында файдаланучы дип атый.

Аерып алынган тагын бер өлкә – әсәрдә милләт мәсьәләсенең Г. Гобәйдуллин тарафыннан ачып бирелә алмавы. Моннан тыш, Ибраһимов хезмәттә Исхакый әсәренең ни өчен кыйммәтле булуы да әйтелмәгән дип саный: ««Инкыйраз» «чын әдәби әсәр, ул мәңгелек». Ни өчен? Чын әдәби, димәк, ни дигән сүз? Бер әсәрнең чын әдәбилеге өчен ни нәрсәләр шарт? Бу шартлар «Инкыйраз»да табылганмы? Ничек вә кай җирдә? Бер әсәр гадиләрдән аерылып нинди хасиятьләр аркасында «мәңгелек» була ала? «Инкыйраз» хакында бу сүзне әйтү мөмкинме? Менә Газиз әфәнде үзенең тәнкыйтен тутыру өчен әсәрендә шул сөальләргә икънагый рәвештә җавап бирергә, «Инкыйраз»ның чын-чын әдәбилеген күрсәтерлек, аңардан нәмунәләр алырга тиеш иде» [Ибраһимов, 2019, т. 6, б. 85].

Бүген, Г. Ибраһимов тәнкыйтьли торган әсәрләр яки хезмәтләр вакыт сынавын үткәннән соң да, язмаларга мөнәсәбәт шактый каршылыклы булып кала. Бер яктан, Ибраһимов игътибар иткән, каты-кискен гыйбарәләр белән тәнкыйтьләгән күренешләрнең – узган дәвер мәдәниятенең кыйммәтле мирасын тәшкил итүе ачык. Икенче яктан, Ибраһимовның 1910–1914 еллар әдәби-публицистик иҗатының гомуми юнәлеше фонында, әлеге тәнкыйть әдипнең татар мәдәнияте алдына гаять зур (аерым бер очракта идеаллаштырылган) таләпләр куеп, татар зыялыларын шул үзе билгеләгән идеалга өндәве кебек аңлашыла. Әмма аңа ирешер өчен күп кенә шартларның берьюлы үтәлергә тиешлеге, аерым бер очракларда, игътибардан читтә кала: шуңа да Ибраһимовның тәнкыйте еш кына татар җәмгыяте тарафыннан тискәре кабул ителә, татар зыялылары берничә тапкыр аңа рәсми кисәтү ясыйлар.

Г. Тукай иҗатына кагылышлы аеруча тәнкыйди характердагы «Талант трагедиясе» (1914) мәкаләсе «Йолдыз»да (2 сентябрь) басылып чыга. Казанның зыялылары, шушы мәсьәләне «хакимнәр суды»нда тикшереп, Г. Ибраһимовны изоляциядә калдыру турында карар чыгаралар.

Текстны укыганда, аның беренче юлларыннан ук Ибраһимовка карата тискәре мөнәсәбәт уяна. Әле генә дөньядан кичкән халык сөеклесе турында сүзне ул болай башлый: «– Тукаев үлде...

Телеграмның Киевкә китергән бу хәбәре минем йөрәгемә һичбер нәрсә сөйләмәде. Чөнки мин ул мәшһүр исемнән, гади бер Гайнетдин кебек икмәк чертә торган ике аяклы, ике куллы Габдулла түгел, бәлки аның "Шүрәле" һәм "Печән базары" белән өмидемезне кузгаткан хәят шигъриясен аңларга өйрәнә килгәнмен. Бу исә минем кашымда күптән гүргә кергән иде инде» [Ибраһимов, 2019, т. 6, б. 212].

Шуннан соң, акланырга ашыккандай, бу очракта мин конкрет кеше турында сөйләмим, бәлки гомумән шагыйрь трагедиясе хакында сүз йөртәм дип өсти. Һәм мондый сурәт тудыра: Тукай зур талантка әйләнерлек сәләт белән туган, әмма аны әйләндереп алган тормыш, мохит аны бу мөмкинлектән мәхрүм иткән! Чөнки, Ибраһимов фикеренчә, сәбәп ярлы татар тормышының өметсезлектә, караңгылыкта булуында; талантның әйләнә-тирәсендәге кешеләрдә; табигатьтән илһам ала алмавында; үзен югары санавында. Бу сүзләр белән тулысынча килешү мөмкин түгел. Әмма Ибраһимов бу ноктада да тукталып калмый. Шуннан соң ул Тукайны йомшак холыклы булуда, мактауларга ышануда, үзен тәнкыйтьләүчеләр белән сугышуда гаепли һәм янында дошманнары булмауны талантка ачылырга ирек бирмәгән хәл дип атый.

Әйтергә кирәк, мәкалә исеменең куелышында һәм фикерләрнең шәрехләнүендә Ибраһимовның Тукай үлемен «милли фаҗига» дип атаган Г. Исхакый белән бәхәс рухы аермачык. Шагыйрь үлеменә китергән сәбәпләрдә күзәтүләр уртак булса да, Исхакыйның төп фикере болай яңгырый: «Татарның тупас, дорфа тормышына матурлык, ямьлелек, күркәмлек тудырыр өчен яратылган Тукай, ямьне, тәмне күрмәенчә, ач, мохтаҗ, ялангач, ялгыз көенчә үлде, татар тормышындагы суыктан – зәмһәрир суыгыннан туңып, катып үлде, суык кальбне җылытырлык, туңган күңелне эретерлек, каткан күзләрне яшьләндерерлек, үлгән өметне тудырырлык, үстерерлек матур, ямьле шигырьләр бүләк итеп үлде, киләчәктәге буынның шагыйрьләре туңмасын, өшемәсен өчен җылы тудырып, кояш чыгарып үлде» [Ибраһимов, 2019, т. 6, б. 0]. Бу өзек Ибраһимовның ялгышын, Тукайның бөеклеген аңлый алмавын да бик ачык күрсәтә.

Гомумән алганда, 1910–1914 еллар дәвере – Г. Ибраһимовның иҗат мирасындагы эзләнү вакыты буларак бәяләнә ала. Бу чорда яшь иҗатчы әдәбият теориясе һәм тәнкыйтен эшләүнең зарурлыгына төшенә, шушы өлкәдә фикер туплый, позиция булдыра. Күп уку, күп уйланулар, милли әдәбиятны башка әдәбиятләр белән чагыштыру, татар мәдәниятенең үзенчәлекләрен барлау аша ул көчле әдәбият тәнкыйтьчесе булып өлгерә һәм үзен чор татар әдәби барышы хакында төп фикер әйтүчеләрнең берсе итеп таныта. Академик басманың 6-нчы томы безгә шуны күрсәтә алуы белән кыйммәт.

Г. Ибраһимов әсәрләренең **7** нче томы аны әдәбият теоретигы итеп таныта. 1915–1917 еллар – Ибраһимовның татар әдәбияты

теориясе өлкәсендә галим, фикер иясе булып җитешү дәвере. Бу томга тупланган мәкаләләрдә дә Г. Ибраһимов әдәбият-мәдәният нәзариясе эшләүнең милли мәдәниятне үстерү, милләтне күтәрү өчен кирәклеген гел искәртеп, ассызыклап бара. Шушы омтылыш аны бәхәсле милли мәсьәләләргә дә игътибар иттерә, шуларның берсе – еллык күзәтү характерындагы «Хәят вә әдәбият (еллык тәэсират)» (1915) мәкаләсе төркилек яки татарлык каршылыгына кагыла.

Г. Ибраһимов татар җәмгыятендә XIX йөз ахырыннан бу мәсьәләдә ике төрле караш яшәп килүне әйтә. Беренчесе – Исмаил Гаспралыдан башланган бердәм төрки кавем турында булса, икенчесе 1905 ел белән мәйданга чыккан, Шиһабеддин Мәрҗани һәм Каюм Насыйриларның милли җәмгыятебезнең татар икәнлеге хакындагы карашы. Ибраһимов шушы хактагы «Шура» журналы башлаган анкетаны телгә ала, үзенең дә шуңа кагылышлы мәкалә язуын күрсәтә, Г. Баттал, Җ. Вәлидиләрнең әлеге мәсьәләдә кире каккысыз нәтиҗәләр ясавын билгели. Кабат моңа әйләнеп кайтуын Риза Фәхретдиннең «Әхмәд Мидхәт әфәнде» мәкаләсендәге татарлык концепциясенең бүлгәләнүгә китерү куркынычы хакындагы фикергә («татар әдәбияты туса, аның янында мишәр, башкорт, типтәр әдәбиятлары да туачак» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 53]) нисбәт итә, аның авторы белән бәхәс ача.

Г. Ибраһимов фикеренчә, татар әдәби теле нугайлар өчен дә (бу очракта «Идел» газетасы телгә алына), Чистай мишәрләре яки Касыйм татарлары, «Златоус башкортлары», «Уфа типтәрләре», Себер татарлары («Сибирия» газетасы телгә алына) өчен дә уртак. «Яубашымы, Эстәрлебашымы, мишәр, башкорт вә нугаймы – алар шул хәвазадагы табигый халәтнең тәэсире белән татарлык елгасына кушылдылар. Моңа кем дә булса хезмәт итмәде, бу адәм теләкләренә илтифатсыз бара торган тарихи агымның зарури нәтиҗәседер» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 56]. Шул рәвешле, Г. Ибраһимов Идел-Урал буендагы төрки халыкларның алга таба да татар әдәби телен үстерәчәген сөйли.

1916 елда Г. Ибраһимов казах яшьләре кузгаткан тел мәсьәләсенә багышланган «Телләре башка булса да, күңелләре бер» язмасында («Аң» журналының март санында басыла) тагын бер тапкыр шушы мәсьәләгә туктала. Бу очракта аның фикерләре үзгәрә башлау күзгә ташлана: авторның төрки халыкларның мөстәкыйль әдәбиятлар булдыруын тануы – биш яки алты әдәбиятны тану булып чыга.

«Әдәбият дәресләре» хезмәтендә Г. Ибраһимов кабат шушы мәсьәләгә әйләнеп кайта. Россиядә яшәүче төркиләрне 8 кабиләгә бүлеп (казан татары; башкорт; мишәр; типтәр; касыйм татарлары; әстерхан нугайлары; түбән һәм алатыр татарлары), аларның уртак бер әдәби тел һәм уртак бер әдәбият тудыруы күрсәтелә.

Бу мәсьәләдә эзләнүләрен язучы соңгы көннәренә кадәр туктатмый, хәтта карашларының үзгәргәнлеген танып, матбугатта чыгышлар ясаудан да тартынмый. Чөнки әлеге мәсьәләне Ибраһимов

әдәбият язмышы белән бер итеп карый, татар әдәбиятының киләчәге, әдәбият фәненең киләчәге, яшь көчләр – барысы да шушы өлкәдә дөрес сәясәт коруга бәйле икәнлекне ачык аңлап эш итә.

Шулай ук Г. Ибраһимовның әдәбиятка-сәнгатькә караган эшчәнлегендә даими бара торган мәсьәлә – әдәби барышка еллык күзәтүләр. Шуларның чираттагысы – «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр (Еллык тәэсираттан)» (1915) күзәтү мәкаләсе «Йолдыз» газетасында (6 февраль, 29 апрель саннары) басылып чыга. Ул әдәби барышка тирән һәм тәнкыйди караш ташлап иҗат ителгән. 1914 елның күренекле әсәрләре дип Р. Фәхретдиннең «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр»е, Ш. Камалның «Хикәяләр төркеме», Борһан Шәрәфнең «Гани бай»ы, Г. Исхакыйның «Мөгаллимә»се, С. Сүнчәләйнең «Әлмансур»ы (тәрҗемә), Һади Атласиның «Сөенбикә»се, Җ. Вәлидинең «Милләт вә миллияте», Г. Тукайның «Мәҗмугаи асар»е аерып күрсәтелә. Болар – татар җәмгыятендә күп кенә сөйләшүләргә азык булган, макталган әсәрләр. Ибраһимов исә һәр автор һәм әсәр хакында шактый үткен тәнкыйть сүзләре дә ишеттерә.

Ш. Камал талантын вак һәм кечкенә дип атап, ул болай дәвам итә: «Анда җиңел кул, җиңел каләм бар. Һәр җиргә җиңелчә генә кагылып уза ала торган җитез тасвир бар. Аның теле матур, каләме шома йөри, җиңел һәм рәхәт яза. Бервакытта да тирәнгә чуммый. Шуңа күрә аны бер генә, тик бер генә мәртәбә укыйсың, икенче кат эзләмисең, чөнки, бирәчәге алынып беткән була» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 62]. Бу бәядә тирән психологизм остасы булган Ш. Камал иҗатын яки аңламау, яки аңларга теләмәү күзгә ташлана.

Шулай ук тәнкыйди рухта иҗат ителгән «Журналларымыз» (1915) мәкаләсе дә милли матбугатка тәфсилле күзәтү булып чыккан. Бездәге газета-журналларның алдынгы милләтләр матбугаты белән бер дәрәҗәдә була алмавы хакындагы фикергә таянып, мәкалә авторы аерым матбугат органнарына күзәтү ясый. Әйтик, «Аң» журналы мисалында ул «мин татарның хәзерге мәдәни вә әдәби куәте камил мәгънәсе белән әдәби вә мәдәни бер мәҗмуга яшәтергә җитә алмавын ачык хис иттем» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 95] дигән нәтиҗә ясый. Бу хәлнең сәбәпләре хакында уйланып, татар журналларының, әбунәчеләре азлыктан, матди файда китермәүләре; журналның эчтәлеген баетыр өчен җитәрлек әдәби һәм гыйльми материал булмау атала.

Әдәбият мәйданында, Ибраһимов фикеренчә, балалар язучыларына, рәссамнарга кытлык. Бу җитешмәгәнлеккә исә «бөтен татар гаепле, бөтен тарихи агымымыз гаепле».

Г. Ибраһимовның бәхәсләр уяткан тагын бер язмасы – «“Мөгаллимә”нең Уфада уйналу мөнәсәбәте» (1915) тагын бер тапкыр Г. Исхакый иҗатына анализ рәвешен ала. Әлеге язмада моңа кадәр Г. Исхакый иҗаты турында әйтелгән һәм әдәби җәмәгатьчелектә кабул ителгән фикерләргә дә, әдипнең соңгы әсәре – «Мөгаллимә»гә карата белдерелгән бәяләргә дә турыдан-туры каршы төшү күзәтелә.

Рецензиядә сүз иҗатның билгеле бер идея белдерү икәнлеген ассызыклаудан башлана. Шуңа нисбәтән Исхакыйга бирелгән беренче бәя үк шактый усал яңгырый: Ибраһимов аны идея белдерү ягыннан «мәгълүм мөхәррирләремез арасында иң күңелсез тәэсир калдырганнарыннан бере» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 74] дип атый. Иҗатының төрле дәверләрендә фикерләре үзгәрү кимчелек буларак калкуландырыла.

Беренче чор, «Тәгаллемдә сәгадәт», «Бай угылы», «Кәләпүшче кыз», «Ике гашыйк», «Өч хатын белән тормыш» кебек әсәрләрендә «ысулы җәдидә яхшы, кадимләр начар, бәхет вә сәгадәт җәдит белән укуда» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 75] дигән дәверне Ибраһимов «Ике йөз елдан соң инкыйраз» белән төгәлләп куя.

«Теләнче кызы», «Солдат», «Зиндан», «Җыентык» шикелле яңа дәвер хасил иткән әсәрләрендә «социализмга охшаш бер ис аңкый» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 75], сыйнфый көрәш үзәккә куела дип, шуның белән бәрабәр беренче чор иҗатындагы тәрәккыйпәрвәрлек, миллилек идеясенең югалуын Ибраһимов иҗатчы өчен зур кимчелек санавын әйтә. Әлеге фикерләр татар матбугатында моңа кадәр дә Исхакый иҗатына карата әйтелә, яшәп килә.

Әмма өченче дәверен рус «порнографист яшь язучыларына» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 75] иярү дип карау, Исхакыйның «Тормышмы бу?», «Шәкерт абый», «Мәдрәсә җимешләре»н – шушы яссылыкта бәяләү гомуми карашларга каршы килә. Татар дөньясы әлеге әсәрләрне тормышның моңа кадәр язучылар каләмгә алырга җөрьәт итмәгән, әмма күрсәтелеп кире кагылырга тиешле якларын ачкан дип кабул иткән була.

Г. Ибраһимов «Мөгаллимә» драмасы Исхакый иҗатында тагын яңа бер дәверне ачып җибәрә дип саный һәм әсәргә шактый җентекле тукталa. Озын-озын нотыклар, хатлар урнаштыруы өчен гаепләп, ул драманың әдәбилеген төп героиняның бирелешенә бәйләп бөтенләй юкка чыгара: «күпчелегенең язмышы шул югарыча булган татар мөгаллимәсе тибы юк» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 80]. Моны ул Фатыйма язмышының «типичный» булмавы белән аңлата. Ибраһимовча булган кискен хөкемен чыгара: «“Мөгаллимә” исеме астында мондый бернәрсә тәкъдим итүне мин авыр язмышлы мөгаллимәләр сыйныфына каршы җинаять дип беләм». Һәм бөтенләй нәзария мәйданына күчеп, болай ди: «Мөхәррир йә матур вә мәгънәле хыял язсын, яки үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берен укучы алдында ачып салып, халыкны шул хакта уйларга, авыр язмышны җиңләйтү турында чаралар күрә башларга, һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен!» [Ибраһимов, 2019, т. 7, б. 81]. Бу инде я реализмны, яки романтизмны сайларга чакыру, ягъни метод чисталыгын-сафлыгын шарт итеп кую булып аңлашыла.

Әлбәттә, Ибраһимовның бу мәкаләсе аның холкы-характеры һәм әдәбият-сәнгатькә мөнәсәбәте хакында күп мәгълүмат бирә. Бер яктан, татар әдәбияты тарихын, дөнья әдәбияты тарихын, әдәбият

нәзариясен яхшы белүе күзгә ташлана. Инде әдәби җәмәгатьчелектә урнашкан, аксиома дәрәҗәсендәге фикерләргә каршы чыгуы – үз-үзенә, үз фикеренең дөреслегенә тирән ышанып яшәвен һәм иҗат итүен күрсәтә. Моннан тыш, Ибраһимов үзенә дә, татар зыялыларына да, гомумән татар милләтенә дә куя торган таләпләрнең зур, кайчак көч җитмәслек, артык идеаллаштырылган булуын да күздән ычкындырмаска кирәк. Шул ук вакытта Исхакыйның аерым бер әсәрләренең кыйммәтенә, аларның әдәби барыштагы урыны-роленә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренең күбесе бүген, бер гасырдан артык вакыт узганнан соң да хаксыз, субъектив икәнлекне дә әйтмичә калып булмый. Болар Ибраһимовның әдәбият-сәнгатькә карата урнашкан карашы, тәгълиматы белән генә аңлатыла алмыйлар. Тукайга, Исхакыйга, Ф. Әмирханга карата яңгыраган күп кенә тәнкыйтьләр иҗатчының талантын хәрәкәткә китергән көнчелек белән дә бәйле булгандыр.

Г. Ибраһимовның нәзари эзләнүләренең нәтиҗәсе 1916 елда зур хезмәт – «Әдәбият дәресләре» китабы булып басылып чыга. Ул, чын мәгънәсендә, татар әдәбият теориясенең үсешендә яңа баскыч, яңа этап буларак бәяләнергә лаеклы. 7 нче томда бу хезмәт, беренче тапкыр, татар укучысы игътибарына тулы килеш тәкъдим ителә!

Китап – Г. Ибраһимовның Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итү нәтиҗәсе, нада татар әдәби-нәзари фикере өчен яңа, кызыклы әдәби әсәр теориясе булдырылган. Г. Ибраһимовның «Әдәбият дәресләре» тулы бер дәверне – татарларда әдәбият нәзариясе фәне формалашу дәверен йомгаклап куя. Дәреслек итеп язылса да, аның вазифалары күпкә киң: татар әдәбиятын нәзари кагыйдәләр ярдәмендә аңлату, бәяләү, үсеш юлларын сызу да максат итеп алынган була.

Г. Ибраһимовның әдәбият теориясенә караган эзләнүләре реализм иҗат методы эчендәге мәгърифәтчелек алымнарыннан баш тартып, романтик алымнарга өстенлек бирү, реализм әдәбиятын романтик сурәт тудыру чаралары белән баетырга чакыру булып аңлашыла. Г. Ибраһимов исә үзенең хикәя-романнары белән генә түгел, бәлки фәнни-теоретик эзләнүләре ярдәмендә дә татар әдәбиятында романтик иҗат тибы үсүгә этәргеч ясый.

Томнар, аларга тупланган материаллар, Г. Ибраһимовның әдәбитарихи һәм тәнкыйди, нәзари мирасы хакында бик күп сөйләргә мөмкин. Әмма бер нәрсә ачык: бу мирасны тулысынча аңлау һәм бәяләү өчен – аны белү зарур! Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре әзерләгән 15 томлык академик басма безгә менә шундый мөмкинлек бүләк итә! Моның өчен аларга рәхмәттән башка сүз юк.

Шуның белән бергә, совет чорында ук 8 том булып чыккан (аннары 9 нчы томы да өстәлә бит әле! [Ибраһимов, 2000]) Г. Ибраһимов мирасында да укучыга нәмәгълүм калган материалның гаять тирәнлеге, киңлеге (өчтән бере билгесез калу) безне башка язучыларыбыз, галимнәребез, аларның совет чорында йолыккаланып чыгарылган томнарын академик тулы басмалар итеп эшләү кирәклеге хакындагы фикерләргә этәрә. Шул вакытта гына без элгәргеләребез үз халкына,

милләтенә әйтергә, ишеттерергә теләгән фикерләргә якыная, аларның шәхси бәһасен аңлый алырбыз.

**Әдәбият**

Габдулла Тукай. Энциклопедия / баш мөхәрир З.З. Рәмиев. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 313 б.

Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / авт.-сост. М.-Х. Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 336 с.

*Ибраһимов Галимҗан:* Хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. Казан: 2000. 464 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 327 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Академик басма: унбиш томда. 7 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 375 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр. Сигез томда. 1–8 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974–1987.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. Т. 1–15. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998–2014.

*Хасанов М.* Галимжан Ибрагимов: монография. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 432 с.

*Хасанов М.Х.* Галимджан Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 432 с.

*Хасанов М.Х.* Эволюция творчества Галимджана Ибрагимова в послеоктябрьский период: дис. ... д-ра филол. наук / ИВ АН СССР. М., 1971. 595 с.

*Хәсәнов М.Х.* Галимҗан Ибраһимов иҗаты: (Октябрьгә кадәрге чор): филол. фән. канд. ... дис. Казан, 1961. 343 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты*

УДК 821.512.145

***Ф.Х. Миңнуллина***

# ИЛЕМ ТАРИХЫ – ХАЛКЫМ ЯЗМЫШЫ
## (1920–1930 еллар татар драматургиясе мисалында)

Статья посвящена изучению поэтики трагического как формы образного мышления и ее отражения в произведениях Г. Исхаки, Н. Исанбета, Г. Ибрагимова, Т. Гиззата, где показана драма человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания. Проблема противостояния героев трагическим обстоятельствам в безвыходной ситуации в каждом из рассматриваемых произведений решается по-разному.

**Ключевые слова:** драматургия, конфликт, драма, герой, история, персонаж.

The article is devoted to the study of the poetics of the tragic as a form of imaginative thinking and its reflection in the works of G. Iskhaki, N. Isanbet, G. Ibragimov, T. Gizzat, which shows the drama of a person who has suffered severe life trials. The problem of heroes‘ opposition to tragic circumstances in a hopeless situation is solved differently in each of the works under consideration.

**Keywords:** dramaturgy, conflict, drama, hero, story, character.

2020 елның 27 маенда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел булды. Әлбәттә, бер гасырлык юбилеен билгеләп үткән Татарстан тарихын, әлеге тарихны тудырган кешеләр хакында, аларның мирасы, эшләре турында сөйләргә дә, язарга да, киләчәк буыннарга да җиткерергә кирәк.

Татар халкының илгә, дөньяга танылган шәхесләре бик күп. Мондый шәхесләр арасында язучылар, галимнәр, сәнгать осталары, сәясәтчеләр дә бар. Һәр укучы, үзе яши торган төбәкнең үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын белергә тиеш. Кеше кайчан халык күңеленә мәңгегә кереп урнаша соң? Зур батырлыклар эшләсә, аның өчен яшәсә, аның мәнфәгатьләрен һәм хәсрәтләрен чагылдырып иҗат итсә... Мәгълүм ки, татарның һәр чорда бәйсез дәүләт төзү теләге белән януы билгеле. Безнең мәшһүр бабаларыбыз, шанлы дәүләтләр төзеп, Кытай, Россия кебек илләргә, гомумән, бөтен дөньяга дәрт һәм көч биреп торганнар. 500 ел элек югалткан дәүләтчелекне кайтару теләге белән һәр татар кешесе гасырлар дәвамында янса да, узган гасырның 1917–1920, 1990 елларында гына күпмедер дәрәҗәдә моңа ирешә [Вәлиев]. Билгеле булганча, Февраль һәм Октябрь революцияләре халык язмышын кискен үзгәртә. Октябрь революциясе булып, хакимияткә большевиклар килгәч, милли мәсьәләнең дә торышы үзгәрә. Дөрес, милли дәүләт төзү идеясе әле яшәвен дәвам итә. 1917 елның 29 ноябрендә Милли Мәҗлес Уфадагы утырышында Идел-Урал Штаты исеме астында төрки-татарларның территориаль автономиясен төзү турында карар кабул итә һәм, бу карарны гамәлгә ашыру өчен, махсус комиссия

төзи. Комиссия Казанда эшләргә тиеш була, аның составына И. Алкин, Г. Гобәйдуллин, Г. Шәрәф, С. Атнагулов һ. б. керә. 1918 елның 8 гыйнварында, «Идел-Урал» республикасын игълан иткәндә тәртип саклау өчен, Казанда II Бөтенроссия мөселман хәрби съезды җыела. Республика төзелүне хәбәр итү тантанасы 1918 елның 1 мартында Казанда узарга тиеш була, әмма бу чарага Казан большевиклары кискен каршы чыга. Алар 1918 елның 28 февралендә «Идел-Урал» республикасын төзүне гамәлгә ашырырга тиешле комиссия әгъзаларын кулга ала һәм II Бөтенроссия мөселман съездыннан әлеге республиканы игълан итүдән баш тартуны таләп итә. Үзара сөйләшүләр нәтиҗәсендә «Идел-Урал»ны игълан итү кичектерелә, кулга алынучылар азат ителә. Моннан соң милли хәрәкәт лидерлары һәм съезд делегатлары татарлар күпләп яшәгән Болак ягына чыгып китәләр. Шул елның март-апрель айларында Казанда совет власте белән хезмәттәшлек итәргә теләмәгән милли оешмаларның бөтенесе дә юкка чыгарыла. Большевиклар Идел-Урал Штаты урынына Татар-Башкорт республикасы төзүне хәбәр итәләр: милли дәүләт төзү тарафдарларының байтагы совет власте ягына күчә. Шулай итеп, татарларның үз дәүләтен төзү идеясе юкка чыгарыла. 1920 елның 25 июнендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелә. Әмма татарларның милли азатлыкка һәм бәйсезлеккә ирешү хыялы тагын тормышка ашмый кала [Заһидуллина, б. 17]. Революция, Гражданнар сугышы еллары – халыклар мәдәниятен үстерү өчен авыр чор. Татар әдәбиятының үсеше катлаулы, каршылыклы шартларда бара.

1920 еллардан әдәбиятта фронт, сугыш, Кызыл Армия, хәрби коммунизм темалары күтәрелә, яңа кеше, гаилә формалашу, завод-фабрикалар, хезмәт процессы, совет крестьяны психологиясе, эшчеләр көнкүреше һ.б. темалар актуальләшә. Яңа хөкүмәт вәгъдә иткән якты киләчәккә өмет күп кенә каләм ияләрен рухландыра. М. Гафури «Татар байрагы» (1917) шигырендә, мәсәлән, бу хыял тормышка ашты дип раслый. Әйтергә кирәк, мондый фикерләү алга таба да төп тенденцияләрнең берсе була. 1920 елларның икенче яртысында язучыларга коммунистлар партиясенең идеологик басымы көчәя, репрессияләр котырыну язучыларның иҗатын көчсезләндерә, билгеле бер кысаларга кертә. «Солтангалиевчеләрнең контрреволюцион оешмасы» эше буенча күп кенә татар язучылары җавапка тартыла (Ф. Бурнаш, С. Сүнчәләй, Җ. Вәлиди, С. Җәләл һ.6.). Егерменче елларның ахырларында исә «Җидегән» исемле яшерен оешма уйлап чыгарыла. Бу чорда берәр югары уку йортында белемен арттыру нияте белән 1930 елда Уфадан Казанга күчеп килгән Н. Исәнбәт каты эзәрлекләүләргә дучар була, татар матбугатында аның «Җидегән» оешмасында әгъза булып торуын «фаш иткән» нахак мәкаләләр басыла. Тикшерү нәтиҗәсендә җавапка тартылганнар (Н. Исәнбәт, Г. Кутуй, Г. Минский, Т. Ченәкәй, С. Борһан, С. Агиш) гаепсез дип табылса да, «җидегәнче», «милләтче» дигән тамга әле бик озак еллар алар өстеннән төшми тагылып йөри [Рахмани, б. 7]. Н. Исәнбәт

бу вакыйгалардан соң ун елга матбугаттан, әдәбияттан читләштерелә, укытучылык эшеннән куыла, «Спартак» аяк киемнәре фабрикасына кара эшче булып урнаша. Әмма, язганнары матбугатта чыкмаса да, әдип үзенең язучылык эшен, гыйльми эзләнүләрен туктатмый. Г. Исхакыйның эмиграциягә китүе татар совет әдәбияты өчен зур югалту була. Большевиклар сәясәтен кабул итмәгән Ф. Туктаров, Сания Гыйффәт кебекләр мөһаҗирлектә кала. Тарих вакытлар узу белән һич тә әһәмиятен югалтмый, киресенчә, аның кыйммәте арта гына. Моның шулай булуы әдәби әсәрләр мисалында тагын бер кат раслана. Мәсәлән, Г. Исхакый мөһаҗирлектә дә милли рух белән сугарылган әсәрләренең үзәгенә милләт язмышы мәсьәләсен куеп, әлеге проблеманы төрле яссылыкта чишә. «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд», «Хәят юлында», «Дулкыннар арасында» кебек сәхнә әсәрләре – шуларның матур бер үрнәге. Р.К. Ганиева билгеләгәнчә, ул большевиклар сәясәте, кызыл террор мәсьәләләрен тасвирлаган «Дулкын эчендә», «Катлаулы рус һәм татар сәяси мөнәсәбәтләрен, христиан һәм ислам диннәренең рус һәм татар тарихындагы урынын, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы кебек дәүләтләребезнең, казан татарларының ниндиерәк варислары булу мәсьәләсен, тарихи барышта ирешкән уңышларыбыз һәм җибәргән хаталарыбыз турындагы уйлануларны, гореф-гадәтләребезне «Олуг Мөхәммәд» драмасында чагылдырды» [Ганиева, б. 147]. Язучының «Дулкын эчендә» драмасында автор яшьли тол калган Разыя абыстай белән аның бердәнбер кызы Бану язмышы мисалында халык язмышы, фаҗигасе хакында сүз алып бара. Драмада Разыяны ике балалы Хәйрулла яучылый. Ләкин, Разыя кызы хакына аңардан баш тарта. Кызы Бану кияүгә чыгып Кырымга киткәч, ул бу адымының хата булуын аңлый. «Мин гаепле... Мин сине балам өчен корбан иттем. Сине генә түгел, үземне дә корбан иттем... Анда үлсәң, син анда кан эчендә буылып, балаларыңны күрергә тилмереп үлсәң, мин монда ялгызлыкта, ятимлектә буылам...» [Исхакый, б. 280]. Шул рәвешле әсәргә үз-үзен ялгызлыкка дучар иткән кеше фаҗигасы килеп керә. Автор шәхси бәхетнең кешенең үзеннән дә торуын күрсәтә. Шуңа күрә дә Разыя үзе кебек яшь бала белән тол калган кызына яңадан гаилә корырга киңәш бирә. «Бер кайгыны ялгыз күтәргәнче, икәү бүлешерсез» [Исхакый, б. 293], – ди ул. Гражданнар сугышын, Беренче бөтендөнья сугышын кичергән гаиләнең язмышы, большевиклар властька килгәч, тагы да катлаулана, фаҗигалы төс ала. Кызыллар Разыяның бер гаебе булмаган киявен атып үтерәләр, үзен, буржуйлыкта гаепләп, булмаган акчаларын бирүне таләп итәләр. Нәтиҗәдә, Разыяның өйдәге бар әйберен алып чыгып китәләр. Бу авырлыкларга түзә алмаган хатын якты дөньядан китеп бара. Шул рәвешле, әдип сәясәттән ерак торган бер гаилә мисалында яңа заман җилләренең кырыслыгын һәм яңа хакимият вәкилләренең рәхимсезлеген ассызыклый. Әлеге күренешләр ананың бала алдындагы бурычының шәхси мәнфәгатьләр белән каршылыкка керүе кебек мәсьәләләр тирәсендә яктыртыла. Рәсми мөнәсәбәт аяусыз булуга

карамастан, совет системасына тәнкыйди карашны чагылдырган әсәрләр әдәбият мәйданында күренгәләп тордылар. Ф. Әмирханның сатирик рухта язылган «Март каһарманы» (1917) хикәясе – шуларның берсе. Хикәядә язучы Февраль революциясе нәтиҗәсендә татарлар арасында көчәеп киткән милли каһарманлык күренешеннән ачы көлә. «Шәфигулла агай» (1924) повестенда автор гади татар эшчесенең «яңа кеше» булып үзгәрүен, советча яшим дип, милли гореф-гадәтләрдән ваз кичүен, чиктән тыш кызыл активист булып китүен сатирик планда сурәтли. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920) драмасы да яңа заман сулышын, әле генә мәйданга чыккан заман геройларын, совет иделогиясе тудырган яңа кешеләрне бирүе белән үзенчәлекле. Әйтергә кирәк, Татар әдәбияты классигы, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов – утыз елдан артык иҗат гомерендә бай һәм күпкырлы мирас калдырган, сәяси-тарихи вакыйгалар тәэсирендә барган үзгәрешләрне әсәрләрендә чагылдырган шәхес. Ул да, башка бик күп зыялылар кебек, 1917 ел революциясен шатланып каршы ала. Иҗатының икенче чорында язылган «Яңа кешеләр» (1920), «Кызыл чәчәкләр» (1922), «Тирән тамырлар», (1928), «Безнең көннәр» (1934) кебек әсәрләренә вакыйгаларны тарихи эзлеклелектә, сыйнфыйлык принципларына таянып бирү хас. Шулай да, Г. Ибраһимовның иҗатын бәяләүгә сыйнфыйлык принцибына гына таянып түгел, ягъни байлар-ярлылар, аклар-кызыллар каршылыгы аша гына якын килү объектив булмас. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» романнарында, «Яңа кешеләр» драмасында, «Кызыл чәчәкләр» повестенда революция алып килгән үзгәрешләрне, халыкның көрәш юлын, яңа кеше һәм җәмгыять формалашуын, халыкның аянычлы һәм шул ук вакытта фаҗигале язмышын күзалларга була. Сыйнфый нәфрәтнең үсүе, аның кеше холкын ничек үзгәртүе белән бәйле күренешләр Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасында Тимеркәй, Батырхан кебек геройларның эш-гамәлләрендә дә чагылыш таба. Әдипнең бу әсәрендә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшкә күтәрелгән геройлар өстенлек итә, сыйнфый көрәш идеясе, яңа система дошманнарын юк итү конфликты үзәккә куела. Шулай да, Г. Ибраһимов пьесасында сыйнфый каршылыкларны гына түгел, ә яңа җәмгыятьне төзүче кешеләрнең формалашуын, үз чорының канлы вакыйгаларын, гражданнар сугышы фаҗигаларына бәйле рәвештә шәхес фаҗигасын дә күзалларга мөмкин. «Яңа кешеләр» драмасында Батырхан, Камәр, Тимеркәйләр, нәкъ менә тигезлек, ирек өчен көрәш юлына баскан геройлар булып торалар. Әсәрдә сурәтләнгән яшь буын вәкиле Тимеркәй дә игътибарга лаек. Вакыйгалар үстерелешендә ул кызу канлы, хаксызлыкны, гаделсезлекне кабул итә алмаучы шәхес буларак ачыла. Егетнең Вәли абыйсын үтерүе һәм: «Агайны гына түгел, андый урында туган атайны да кызганмам мин!» [Ибраһимов, б. 410], – дип әйтүе аеруча тетрәндерә. Ул гомумкешелек бәхетенә көрәш, кан кою юлы белән генә ирешеп була дип уйлый. Драмада кеше, гаилә фаҗигасы ил фаҗигасы югарылыгына куела.

Бөтен Идел буен колачлаган 1921 елгы ачлыкны татар әдипләре милли фаҗига итеп карыйлар. Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» (1923) повестенда, мәсәлән, реаль-чынбарлыктагы куркыныч хәлләрнең дәһшәтлелеген күрсәтү максатыннан, әсәргә кеше ашау вакыйгалары да кертеп җибәрелә. Кеше ашаучыларга каршы көрәшкән Гәрәй дә, мәсәлән, алга таба кызы Нәфисәгә ит, ризык итеп карый башлый. Язучы яшәү белән үлем арасындагы көрәш аша аерым бер кешеләрдә кешелек сыйфатларының юкка чыгуын ассызыклый. Кеше ашау дәрәҗәсенә барып җиткән адәмнәр, автор тарафыннан натуралистик сурәтләнә.

Татар халкының үз дәүләтчелеге, яңача яшәү өчен гасырларга сузылган көрәше һәм, ниһаять, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү бу турыдагы тарихи һәм тарихи-документаль чыганаклар нигезендә әсәрләр язу ихтыяҗын үстерә. Моның мисаллары: К. Тинчуринның «Ил» (1927), Ф. Борнашның «Авыл яшьләре» (1929), «Олы юл белән» (1929), Т. Гыйззәтнең «Наёмщик», «Талир тәңкә» (1922), «Кызыл карчыга» (1928), М. Галәүнең «Пугач явы» (1926), Г. Кутуйның «Казан» (1927), «Тәхет йә мәхәббәт» (1927), Н. Галимовның «Казан өчен көрәш» (1927), А. Таһировның «Ач һәм ялангачлар» (1924), «Тәхетләргә ләгънәт» (1924), Г. Чыгтайның «Ачлык корбаннары» (1926) һ. б. әсәрләр [Закирҗанов, б. 337].

Т. Гыйззәт заман кешеләрен, чорга хас үзенчәлекләрне эволюцион үсештә сурәтли. Аның иҗатында илне якты киләчәккә өметләндергән көрәш рухы да, халыкның яшәү рәвеше, йола-гадәтләре, бәйрәмнәре, этнографик үзенчәлекләре дә, авыл кешесенең өметхыяллары да чагылыш таба. Бигрәк тә «Наёмщик», «Кызыл карчыга», «Чаткылар» әсәрләре заман белән бәйле фикри әхлакый кыйммәтләр, дөньяга карашлар үзгәрешен, татар кешесенең киң борылышлар чорындагы гыйбрәтле дә, шул ук вакытта фаҗигалы да язмышын тарихи контекстта тергезүе белән үзенчәлекле. Шуңа күрә әдәбият галиме Б. Гыйззәтнең драматургның иҗат тематикасын халык тарихын авыл халкы тормышы аша сурәтләү итеп каравы аңлашыла: «Т. Гыйззәт үзенең иҗатын төп темаларның берсе булган авыл халкының тормышын күрсәтүгә багышлады. Шуның өчен дә ул авыл крестьяннарының ерак үткәнен дә, власть яулап, көрәшкә күтәрелүен дә, илен саклап Гражданнар сугышына катнашуын да, колхозлашу һәм колхозларның үсеп чәчәк аткан чорын да гәүдәләндерде» [Гыйззәтов, б. 198]. Мәсәлән, Т. Гыйззәтне драматург итеп таныткан тәүге әсәре – «Талир тәңкә» драмасында (1922 елда языла, 1923 елның мартында Татар дәүләт театры сәхнәсендә куела) сыйнфый каршылыклар кискенләшү вакыты тасвирлана. Гади халык алпавыт утарларын талый, урманнарны кисә. Конфликт Сабир байның, Столыпин реформасы ачкан мөмкинлекләрдән файдаланып, община җиренең иң яхшы өлешен үзенә тартып алуыннан башлана. Рамай, Гаяз кебек ярлы халык вәкилләре, үзләрендә көрәшкә җитәрлек көч булмавына карамастан, кыю рәвештә бу гаделсезлеккә каршы чыга. Нәтиҗәдә, Гаяз

кулга алына, Рамай Сабир бай тарафыннан үтерелә. Фаҗигалылык очраклы, аерым бер шәхескә бәйле рәвештә генә түгел, ә гаделлеккә каршы куелган явызлыкның көчлерәк булуыннан килеп туа.

«Талир тәңкә»не яңартып язылган «Чаткылар» (1934) драмасының финалында инде бунт күтәргән авыл кешеләренең Сабир байны ялкын эченә атуы халыкның оешкан төстә хәрәкәт итә башлавын символлаштыра, әсәрнең төп пафосын үзгәртә. Монда үз хокукларын яклап көрәшкә күтәрелгән халык җәберләнүче түгел, ә җиңүче итеп сурәтләнә.

Т. Гыйззәтнең «Кызыл карчыга» (1926) драмасында кеше, гаилә фаҗигасе ахыр чиктә ил фаҗигасы югарылыгына куела. Драматург совет власте урнаштыру өчен канлы көрәш барган көннәр вакыйгаларын тергезә. Яхшы тормышлы шәһәр кешесенең улы үз теләге белән Кызыл Армия сафларына языла. Бу – тынгысыз, Совет хөкүмәтенә каршы баш күтәрүләр оештырылган чак. Кызыл карчыганың туган йорты канкойгыч бәрелеш үзәгенә әйләнә, бу бәрелештә атасы ялгышлык белән улын атып үтерә. Үз гаебе белән улын югалткан ата фаҗигасы сәяси көрәш шартларында бер гаилә, нәсел, ил кешеләренең үзара дошманлашуы, кан коюы, идеологик каршылыклар кешеләрнең бер-берсен физик юк итүгә китерүе хакында уйланырга чакыра. Бер үк вакытта бу көрәштә илнең куркусыз Кызыл карчыгаларын югалтуы өчен сызлану да, алар белән горурлану да тоемлана.

Яңа заманның коммунистик идеологиясен үз мәнфәгатьләре, карьералары өчен файдаланучы икейөзле активистлар, дәүләт хезмәткәрләре, «бозык» коммунистлар, бушкуык иҗатчылар катлавын фаш иткән әсәрләр 1920 еллар драматургиясе агымын хасил итте. Алар арасында тарихи мәгълүмат биреп, халыкның милли үзаңын уяту, тарихи шәхесләрне күз алдына бастыру ягыннан әһәмиятле әсәрләр дә бар иде: Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» (1934), «Ташкыннар» (1937), Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» (1935) кебек әсәрләрне мисал итеп китерергә була. Н. Исәнбәтне 1920 еллар татар әдәби барышында күренекле драматург итеп таныткан «Һиҗрәт» (1923), «Культур Шәңгәрәй» (1927), «Пикүләй Шәрәфи» (1929), «Портфель» (1929) кебек сатирик комедияләрдә нэп чорында җанланып киткән спекулянтлар, яңа заман түрәләре һәм алар белән эш итүче шәхесләр рәхимсез көлү объекты итеп алына, чорның кимчелекле күренешләре кискен сатира ярдәмендә фаш ителә. «Портфель» комедиясендә мәсәлән, буш сүз сөйләп йөргән, яңа шартларга җайлашырга омтылган нэпманнарның эш-гамәлләре тәнкыйть утына алына. Әсәрдәге мулла Миргаян, Мәгъсүм, Камәретдиннәр, үз вазифаларыннан файдаланып, кооператив әйберләре белән сату итәләр. Алар өчен «инкыйлаб», «совет» сүзләре кылган гамәлләрен каплау өчен генә кирәк. Бу юнәлештә иҗат ителгән комедияләре Н. Исәнбәтне яңа хакимияттәге уңай күренешләрне чагылдырмауда гаепләүләргә китерә. Мәсәлән, Дәүләткол дигән автор: «Портфель» авылдагы муллаҗанизмны рәхимсез рәвештә ярып күрсәтә дә, аларга каршы куелган сыйнфый көч – авылдагы

хәзерге социализм һөҗүме – колхоз хәрәкәте бөтенләй яктыртылмый» [Исәнбәт, б. 320], – дип яза. «Пикүләй Шәрәфи» комедиясенә бәйле Г. Кутуй, С. Фәйзи мәкаләләрендә яңа хөкүмәт шартларында карьеристларның чынбарлыкта булуы шик астына алына. Заман тәнкыйте драматургның совет законнарын яхшы белеп эш иткән тискәре геройларны сәхнәгә чыгару максатын: элеккеге мулла Миргаянның («Портфель»), советлашкан сәүдәгәр Шәрәфинең («Пикүләй Шәрәфи») Совет хакимиятендә җылы урын эзләүләрен сурәтләп, җәмгыятьтәге ялганга, алдауга юл калдырылу хакында кисәтергә омтылуын ачыклый-билгели алмый. Н. Исәнбәтнең милли республикалар төзү тарихын яктырткан «Болак арты республикасы» (1939) комедиясендә сәяси көрәш мотивлары алга чыга.

XX гасыр төрле вакыйгаларга бай була, шуңа да ул чор тарих сәхифәләре үтә катлаулы. Октябрь революциясе булып, хакимияткә большевиклар килгәч, милли мәсьәләдә хәл нык үзгәрә. Татарларның үз дәүләтен төзү идеясе юкка чыгарыла. Әлеге вакыйгалар язучыларыбыз игътибарыннан да читтә калмый. Милли республикалар төзү тарихы Н. Исәнбәтнең «Болак арты республикасы» комедиясендә чагылыш таба. Биредә әлеге «республиканың» көлке дәрәҗәдә кечкенә һәм мәнфәгати тар булуы ассызыклана. Бу әсәрдә төрле социаль катлау вәкилләре, милли оешмалар Идел-Урал штаты төзү проектына үз мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Әмма алар уңай нәтиҗәгә ирешә алмыйлар. Автор моны сәяси наданлык, шәхси мәнфәгатьләр белән бәйләп карый. Комедиядә Идел-Урал Штатының төп асылын аңламаган төрле социаль катлау вәкилләре көлү объектына әйләнә. Штатның милли байрагы нинди төстә булырга тиешлеген хәл итү бәхәсе аша чорның тирән каршылыклары ачыла. Нечкә комик детальләр ярдәмендә драматург зур сәяси проблемаларны күрсәтә: әйтик, сәясәтне сай белгән читекче Габдрахман болай ди: «...штат булсын! Әмма ләкин шундый булсын, үзе татарныкы булсын, үзе советныкы булсын». Гыйлаҗи байның һәм башка штат вәкилләренең планнары үзгә: алар кан кою исәбенә илдә барган революция хәрәкәтен туктатырга, малларын саклап калырга телиләр. Вакыйгалар агышында Габдрахман «Мин – җөмһүрият өчен үлә торган кеше... Әмма ләкин мондый җөмһүрияткә түгел! Нинди җөмһүрияткәме? Менә Мулланур Вахитовлар кора торган шураларски татар җөмһүрияткә» [Исәнбәт, б. 320], – дип, кызылгвардиячеләргә кушыла һәм Маһирә, Морат Сәлмиевләр белән бергәләп, революция дошманнарын кулга алуда катнаша. Әдип чынбарлыкның кешеләргә тәэсирен, заманның яңа кешесе формалашуын да шул рәвешле игътибарга ала.

Шулай итеп, татар әдәбиятында заман проблемаларын, ил язмышы, халык язмышы турындагы уйлануларын, көчле характерлар, кызыклы вакыйгалар аша тасвирлаган әсәрләр әдәбият мәйданына чыга. Язучылар үзләренең геройлары аша үткән чорның социаль күренешләрен, халык язмышын, аның яшәешен, уй-фикерләрен, катлаулы тормышын сурәтләп, чынбарлыкта хөкем сөргән социаль,

әхлакый тәртипләр турында сүз алып баралар һәм тарихның катлаулы, фаҗигалы елларын күрсәтәләр.

**Әдәбият**

*Вәлиев Р.* Милли дәүләтчелек туганда… // http:// beznenmiras.ru/milli-deuletchelek-tuganda/. Мөрәҗәгать итү вакыты 12.05.2020.

*Ганиева Р.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 272 с.

*Гыйззәтов Т.* Фикерләр. Истәлекләр. Хатлар. Бәхәсләр. Казан: Мастер Лайн, 2000. 320 б.

*Дәүләткол.* «Портфель» сәхнәдә // Коммуна. 1930. 19 гыйнвар.

*Заһидуллина Д.* Әдәби хәрәкәт // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда.???

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 454 б.

*Исәнбәт Н.* Әсәрләр: 4 томда: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

*Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 559 б.

Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Ибрагимова / сост. Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева. – Казань: ИЯЛИ, 2017. 286 с.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47).08+655

*А.Н. Рәсүлов*

# ФИРГАНӘ ҮЗӘНЕНДӘ ТӨБӘК МАТБУГАТЫН ҺӘМ ПОЛИГРАФИЯ ЭШЕН ОЕШТЫРУДА ТАТАРЛАРНЫҢ КАТНАШУЫ

Статья посвящена истории возникновения и развития печатного и полиграфического производства в Ферганской долине, а именно, участию татар в этом процессе. Сама печать появляется в этом регионе во второй половине XIX века, благодаря политическим мигрантам, которые занимаются издательской деятельностью на русском языке. Татарские же шрифто-наборщики с мусульманскими шрифтами приезжают позже для издания узбекоязычных газет. Среди них были Шахингирей Биккулов, Абдулатиф Яушев и Али Бектимиров, которые, на взгляд автора, и заложили основу издания первой узбекскоязычной газеты. Также организации и развитии первой узбекоязычной газеты принимали участие переводчики Ш.Ибрагимов и М.Чанишев. Еще одним из татарских просветителей, оставивших след в области печатного дела в Туркестане, был татарин Хусейн Макаев – педагог, издатель и публицист. В статье выделяется особое внимание его деятельности в Туркестане. Также автор анализирует постреволюционный период в издательской деятельности в Ферганской долине.

**Ключевые слова:** издательская деятельность, татарское печатное дело, Ферганская долина, узбекская печать, история узбекской печати.

This article is devoted to the history of the emergence and development of publishing in the Ferghana Valley, namely, the participation of the Tatars in this process. The press itself appears in the region in the second half of the 19th century thanks to political migrants who engage in publishing in Russian. Tatar typesetters with Muslim fonts come later to publish Uzbek-language newspapers. Among them were Shakhingirey Bikkulov, Abdulatif Yavushev and Ali Bektimirov, who, in the author's opinion, laid the foundation for the publication of the first Uzbek-language newspaper. Also, the organization and development of the first Uzbek-language newspaper was attended by translators Sh. Ibragimov and M. Chanishev. Another of the Tatar enlighteners who left a mark in the field of publishing in Turkestan was the Tatar Hussein Makayev - a teacher, publisher and publicist. The article highlights the special attention of his activities in Turkestan. The author also analyzes the post-revolutionary period in publishing in the Ferghana Valley.

**Keywords:** publishing, Tatar printing, Ferghana Valley, Uzbek press, history of the Uzbek press.

Төркестанда төбәк матбугатын һәм типографияләр барлыкка килү тарихы 1869 елдан башлана. Аерым алганда, 1869 елда Төркестанда вакытлы матбугат мәсьәләсе буенча Төркестан генерал-губернаторы К.П. фон Кауфман хәрби министр Д.А. Малютинга мөрәҗәгатендә Ташкенттагы генерал-губернаторлыкның матбугат органы сыйфатында «Төркестан хәбәрләре» газетасын чыгаруга, шулай ук Санкт-Петербургтан шушы максатларда махсус типография,

полиграфистларны җәлеп итәргә һәм газетаны бастыру өчен типография оештырырга рөхсәт сорый. Шул рәвешле, Үзәк Азиядә яңа өлкәгә – полиграфия сәнәгате һәм нәшрият эшчәнлегенә нигез салына.

Төркестанда вакытлы матбугат һәм типография эше ул Россия империясе составына кергәннән соң формалаша башлый. Россиядә һәм чик буе өлкәләрендә социаль-сәяси вазгыять XIX гасыр ахыры – XX йөз башына катлаулана. Шуңа бәйле рәвештә патша администрациясе тарафыннан Төркестанга сәяси мигрантлар җибәрү көчәя. Башка өлкәләр белән беррәттән, алар «газета эше»н һәм китап басуны тулысынча үз күзәтчелегенә алалар. Рус революционерлары үз өндәмәләрен һәм листовкаларын рус телендә генә түгел, үзбәк, төрекмән, казакъ һәм башка телләрдә дә тараталар. Революцион рухлы мәкаләләр, шигарь-лозунглар, чакырулар яшерен типографияләрдә басыла. Үз максатларын гамәлгә ашыру өчен, революционерлар рус телендә «Рабочий», «Солдатский листок», «Правда», «Ташкентский рабочий», «Наша газета», шулай ук милли телдә «Тараққий», «Хуршид», «Тужор», «Самарқанд», «Улуғ Туркистон», «Турк сўзи», «Ал-Ислоҳ», «Кенгаш» кебек газеталар чыгаралар.

1870 елдан Төркестан генерал-губернаторы К.П. фон Кауфман боерыгы белән «Төркестан хәбәрләре» газетасына кушымта итеп «Туркистон вилоятининг газети» бастырыла башлый. Бу газета өчен К.П. фон Кауфман Петербургтан гарәп шрифтын алып килүләрен сорый[1]. 6–7 айдан соң Ташкентка дөяләрдә (бу вакытта тимер юллар салынмаган була әле. – *А.Р.*) шрифтлар белән хәреф җыючы татар белгечләре – Шаһингәрәй Биккулов, Габделлатыйф Яушев һәм Гали Биктимеров килә һәм беренче үзбәк телле басмага нигез салына. Шуңа бәйле рәвештә Сиражетдин Хуҗаев, Хәмид Хуҗаев һәм Абдурахман Хуҗаевны шулай ук беренче үзбәк газетачылары рәтенә кертергә мөмкин [Эрназаров, Акбаров, с. 18].

Төркестан генерал-губернаторы тәрҗемәчесе Ш. Ибраһимов һәм генерал-губернатор канцеляриясе тәрҗемәчесе М. Чанышев та аеруча зур энтузиазм күрсәтеп, «Туркистон вилоятининг газети» газетасын оештыруда һәм үстерүдә үз өлешләрен кертәләр. 1872 елдан Ш. Ибраһимов бу газетаның мөхәррире була. 1883 елны М. Чанышев та бер ара аның редакциясе белән җитәкчелек итә [Эрназаров, Акбаров, с. 19]. Газета 1883 ел ахырыннан 1917 елга кадәр Н.П. Остроумов редакциясендә басыла [Жалолов, Ўзганбоев, б. 18]. 1872 елның 18 гыйнвары мәгълүматларына караганда, Габдулла Яушев һәм Мөхәммәд Курмишев Төркестан генерал-губернаторлыгы канцеляриясендә һәм «Туркистон вилоятининг газети» газетасы редакциясендә хәреф җыючы булып эшләгән [Үз МА, 1 ф., 20 тасв., 4280 эш, б. 13].

Үз чиратында, бөтен Төркестанга таратыла торган матбугатның һәм полиграфия эшләренең үсешен Фирганә үзәнендә дә күзәтергә

[1] XX гасырның 30 нчы елларына кадәр гарәп язуын төрлечә – гарәп, мөселман, шәркый, татар, төрек, азия шрифтлары дип атап йөртәләр. Бу шрифтлар татар осталары тарафыннан эшләнә. Кара: [Каримуллин, с. 63].

мөмкин. Мәсәлән, 1907 елдан чыга башлаган «Фирганә өлкәсе хәбәрләре» газетасында рәсми мәгълүматлар урын алган. Шул ук вакытта Фирганәдә 1906 елдан «Фирганә», «Яңа Фирганә» газеталары, ә 1908–1909 елларда «Коканд листогы» газетасы чыга. Югарыда телгә алынган газеталар шулай ук Россия хөкүмәте мәнфәгатьләренә хезмәт итәләр [Садриддинов, б. 275]. Газеталар арасында Кокандта басылган «Эль байроги» газетасын да табарга була. Бу газета 1917 елның сентябреннән Коканд шәһәрендә Пулат Солиев редакциясендә чыга башлый[1]. Газета «Гайрат» предприятиесендә Төркестан Вакытлы хөкүмәте типографиясендә басыла. Гәрчә башта бу газета Коканд милли зыялыларының пропаганда органы булса да, соңрак ул Төркестан автономиясе хөкүмәте басмасына әверелә. Ашурали Заһири, Нушервон Ёвушев, Тешабой, Исмаил Обидий, Хаҗи Хафиз Нурмөхәммәдов, Рәүф Якубов, Шакирҗан Рахимий, Юныс Агаликов һ.б. әлеге басма белән тыгыз элемтәдә торалар һәм анда үз мәкаләләрен бастыралар [кара: Мингнаров, 2013, б. 24].

Төркестанда матбугат эшендә тирән эз калдырган татар мәгърифәтчеләренең берсе – Хөсәен Макаев. Фирганәнең мәдәни тормышында ул педагоглар, наширләр һәм публицистлар белән бергә аерым урын алып тора. Үз вакытында ул Казанда Педагогия училищесын тәмамлый һәм җәдит мәктәптә укыта башлый. Әмма 1903 елда Төркестанга китергә мәҗбүр була. Ул үзенең педагогик эшчәнлеген Скобелев (Фирганә) шәһәрендә дәвам итә, мәктәп оештыра. Мәктәптәге яңа тәртипләр, алдынгы тәҗрибә, җәдитчеләрнең идеяләрен тарату хакимият «таләпләренә» җавап бирми. Нәтиҗәдә, бу мәктәп ябыла. Шуннан соң Х. Макаев Нәманганга килергә мәҗбүр була, анда да җәдит мәктәп ача һәм үзбәк, татар балаларын укыта. Педагогик эшчәнлек алып бару процессында ул Исхокхон Ибрат белән таныша. Нәманган Туракурганында җәдит мәктәпкә нигез салган Исхокхон Ибраһим татар мәгърифәтчесе Хөсәен Макаевны һәм аның якташы Габделрәүф Шаһидине (Габделрәүф Шаһидуллинов, Шаһидуллин) укыту һәм тәрбия эшенә чакыра. Татар педагоглары катнашында

[1] Пўлат (Бекпўлат) Мажид улы Солиев (1882–1937) – Әстерханда татар гаиләсендә туган. Аның әтисе чыгышы белән Бохарадан. Үзе Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм Уфа мәдрәсәсендә укый. Төркестанга 1909 елда килә һәм Ташкәнт, Коканд мәктәпләрендә тарих, арифметика, туган тел укыта. Яңа методлы мәктәп беренчеләрдән булып Ташкәнт өлкәсенең Аккурган районында ачыла. Җизакта да, Мирзачулада да мәктәпләр эшли башлый. Ул 1913 елда Ташкәнттә беренче рус-татар мәктәбен ача. 1917 ел Төркестан автономиясен оештыруда актив катнаша. 1918 елда Скобелев шәһәрендә авыл мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү курсы оештырыла. 1919 елның икенче яртысыннан ул Ташкәнттә беренче төрек-татар курсларын оештыра һәм директор булып эшли. 1922 елдан ул – «Революция», «Тонг» журналлары мөхәррире. 1927 елда аңа – доцент. 1930 елны аңа профессор исеме бирелә. 1927 елны Сәмәрканд югары педагогия институтында «Көнчыгыш тарихы» кафедрасына нигез салына. 1935 елда Үзбәк дәүләт университетында «Урта Азия тарихы» кафедрасы оештырыла. П. Солиев беренче мәртәбә «Үзбәкстан тарихы»н яза. Бу – аның фәнни эшчәнлегендә иң мөһим аспектларның берсе. 1937 елда милләтчелектә гаепләнеп кулга алына һәм атып үтерелә. Кара: [Темиров, б. 6–11].

эшли башлаган Исхокхон Ибрат мәктәбендә укытуның алдынгы алымнары кулланыла. Аерым алганда, бу мәктәптә атналык дәресләр тәртибен, физкультура дәресләрен кертү һәм әлеге чараларны уен рәвешендә үткәрү зур әһәмияткә ия була [Долимов, 2006, б. 41].

«Усули савтия» мәктәпләрендә агымдагы имтиханнарда катнашкан Исхокхон Ибрат, Хөсәен Макаев и Мулла Искандар домла Абдуваҳоб углы мәгарифтә һәм белем бирүдә алдынгы тәҗрибәне куллану өчен, шулай ук тәҗрибә алмашу максатында 1907 елны Ташкентка киләләр. Мәгариф өлкәсендәге тикшеренүләр, дәреслекләргә һәм ярдәмлекләргә булган ихтыяҗ, шулай ук аларны зур тиражлар белән үзбәк телендә бастырып чыгару теләге белән янган Исхокхон Ибрат 1908 елда, нәшриятка җиһазлар сатып алу өчен, Уфага һәм Оренбургка бара. Нәтиҗәдә Оренбургта типографияче Кауфманның [Воҳидова, б. 56] 1901 елда эшләп чыгарылган литография[1] машинасы ун ел дәвамында түләү шарты белән сатып алына. Литография машинасы җиһазларын Оренбургтан Кокандка поезд белән, ә Кокандтан Туракурганга дөяләргә төяп кайтаралар. 1908 елда типография эшен яхшы белгән Хөсәен Макаев ярдәме белән «Матбаи Исхакия» типографиясе ачыла. 1908 елда «матбаи Исхакия»дә беренче мәртәбә «Санъати Ибрат, қалами Мирражаб Бандий» әсәре басылып чыга, һәм бу уңайдан 1908–1909 елларда литография мөдире Ахунзадә Габделрәүф Шаһиди түбәндәгеләрне яза: «Аеруча сәләтле укучылар һәм яшь мөгаллимнәр зур нәтиҗәләргә ирешергә тиеш. Без, гомерлек хәер-фатиха өмет итеп, мәктәп-мәдрәсәләргә, китапчыларга һәм каллиграфларга тәүге бүләгебезне алып киләбез» [Исҳоқхон тўра Ибрат, б. 37–38].

Бу китап, югарыда әйтелгәнчә, укырга һәм язарга өйрәтүгә багышланган була. Моннан тыш әлеге литографиядә «Илми Ибрат», «Джомеуль-хутут» әсәрләре һәм Габделрәүф Самадовның (Габделрәүф Шаһиди) Төркестанда беренче драма булып саналган «Махрамлар» пьесасы дөнья күрә. Наманганда басылган бу әсәрне 1915 елда ук Хәмзә Хәкимзадә Ниязи труппасы сәхнәгә менгерә [Долимов, 1994, б. 63].

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, «Матбаи Исхакия» типографиясендә татар милләтенең башка вәкилләре дә эшли. Аерым алганда, типография эшләре киңәйтелү белән бәйле рәвештә 1909 елда типография Наманганга күчерелә һәм анда хезмәт куючыларга ихтыяҗ арта... Мәсәлән, 1913 елдан М. Абдусаттаров тырышлыгы белән типографиянең материаль базасы көчәйтелә... 1916 елда типографиядә эшләүче яшьләр арасына Россиядән татар егете Гасан (Хәсән) Борнашев машинист булып килә. Җирле җәдитчеләрдән Дадамирза кориның «Мифтог-ул аввал» дәреслеге 1912 елда нәшер ителә, 1913 елда Хөсәен Макаевның балаларга белем бирүгә багышланган «Ильми Хол» хезмәтләре басылып чыга [Мансуров, б. 302–303].

[1] Литография – тигез таш өстенә ясалган рәсемнән яки текстан күбәйтү. Кара: Ўзбек тилининг..., б. 501.

Вакыйгаларны анализлау шуны күрсәтә: Оренбург һәм Уфа типографияләре белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә, Исхокхон Ибрат газетаның грамоталылыкны, мәдәниятне пропагандалауда һәм халык аңын формалаштыруда да зур әһәмияткә ия булуын аңлый. Шуңа бәйле рәвештә ул 1913 елда «Матбаи Исхокия» каршында «Ат-тижор ал-Наманган» исемле газета чыгарырга тырышып карый һәм хөкүмәткә гариза бирә. Бу хакта Оренбургта чыга торган «Вакыт» газетасы болай дип яза: «Нәманган, хөрмәтле Исхокхон казый “Ат-тижор әл-Наманган” исемле газетаны ачу турында үтенеч язуы тапшырды. Бу әфәнде 1908 елда Нәманганда типографиясен ачкан. “Кутубхонаи Исҳоқия” дип исемләнгән китапханә ачты һәм төрек, татар һәм үзбәк телләрендә китаплар бастырды. Хәзер газета чыгарырга җыена. Без сезгә чын күңелдән уңышлар телибез». Кызганыч ки, Исхокхон бу газетаны чыгарырга өлгерми, әмма үзенең йортында Исхокия китапханәсен оештыра. Китапханәдә үзбәк, рус, төрек, татар, фарсы-таҗик телләрендә чыккан китаплардан, «Туркистон вилоятининг газети», «Төркестан хәбәрләре», «Тәрҗеман» газеталарыннан тыш, Россиядә нәшер ителгән күпсанлы башка газета-журналлар да саклана [Исҳоқхон тўра Ибрат, б. 38–39].

Эшчәнлеген үзара хезмәттәшлек нигезендә башлап җибәргән «Матбаи Исхокия» литографиясе Нәманганга 1910 елда күчерелә һәм типолитография итеп үзгәртелә. 1910–1913 елларда аңа Хөсәен Макаев җитәкчелек итә, ә 1913–1917 елларда – М.Н. Абдусатторов. Әгәр Оренбургтан кайтарылган һәм татарлар җитәкләгән литография 1917 елга кадәр төрле дәреслекләр бастыру өчен типография булып хезмәт иткән булса, аннан соң ул совет власте карамагына тапшырыла, ә «Народная газета», «Свобода», «Рабочий щит», «Совдеп», «Рост» кебек газеталар бер типографиядә басыла [Исҳоқхон тўра Ибрат, б. 36].

Х. Макаев үзенең китап бастыру тәҗрибәсеннән файдаланып, үзбәк телендә «Фарғона саҳифаси» газетасын чыгара башлый, аның беренче саны 1917 елның мартында басыла. Ләкин бу газета озын гомерле булмый,  нибары 40 саны гына дөнья күрә. Булган мәгълүматларга караганда, Нәманганда типография һәм мәдәни-агарту эшен камилләштерү максатыннан, Х. Макаев 1917 ел ахырында Казанга килә. Сәфәренең төп максаты – Нәманган типографиясе өчен гарәп шрифты сатып алу. Архив чыганаклары буенча аның Казанга килүе һәм гарәп шрифты сатып алуы раслана. Аерым алганда, кайчандыр Казанда укыганга күрә, аның татар мәгърифәтчеләре белән бәйләнышлары саклану, шулай ук Төркестанда матбугат эше белән кызыксыну арту нәтиҗәсендә, М. Макаев 1918 елның 10 гыйнварында М. Идрисов типографиясеннән Нәманган типографиясе өчен 71 пот гарәп шрифты сатып ала [Rasulov, b. 220–221]. Бу хакта Ә. Кәримуллин китабында да билгеләп үтелә: «с 1 сентября 1917 года по август 1918 года... для ..“Онг”,.. “Миллат” (Казань), “Восточной типографии” (Москва), Бирского благотворительного общества (Башкортостан), газеты “Новое

время” (Оренбург), 12-штаба армии, 7-армейского мусульманского политотдела (Верный), 10-штаба армии, типографии Макаева в Намангане, Екатеринбургского комиссариата … подготовлено 638 пудов 12 фунта шрифтов» [кара: Каримуллин, с. 59].

Башка мәгълүматларга караганда, татар мәгърифәтчеләре Х. Макаев һәм Ф. Макаева, ягъни ирле-хатынлы Макаевлар «басмачылык эшендә Мавлоно Ибратның беренче ярдәмчеләре булалар. Типография каршында яшьләрнең драматик түгәрәге оештырыла, аның оештыручысы һәм режиссеры Х. Макаев 1910 елда «Чолборсиз» пьесасын сәхнәгә куя. Төп рольләрне ул үзе һәм Фатиха башкара» [Умматов, Парпиев, б. 45].

Татар мәгърифәтчесе Х. Макаевның 3434 нче номерлы җинаять эшендә: «Х. Макаев – Нәманганда хосусый типография ачкан 62 яшьлек татар мулласы. Макаевны кулга алганда (1937 елның 12 сентябрендә), ул мәктәп укытучысы булган. Ун елга хезмәт белән төзәтү лагерена хөкем ителгән, җәза срогы 12 сентябрьдән исәпләнә. “Ислам җәмгыяте” оешмасын төзүнең инициаторы, пораженчество тарафдары. Ул хөкүмәт карары нигезендә тормышка ашырылачак эшчәнлеккә каршы укытучыларның контрреволюцион демонстрациясен әзерләүдә һәм контрреволюцион пропаганда алып баруда гаепләнә...» [Умматов, Парпиев, б. 45].

Х. Макаевның хезмәттәше Габделрәүф Шаһиди да Исхокхон Ибрат типографиясенең эшендә актив катнаша. Аерым алганда, Х. Макаевның якын дусты, казан татары, Габделрәүф Шаһиди, литографияне алып бару белән беррәттән, биредә оештырылган яңа методлы мәктәптә дә укыта [Үз МА, 1 ф., 3 тасв., 540 эш, б. 181–182].

Габделрәүф Шаһиди соңрак туган ягына әйләнеп кайта һәм 1918 елның маенда Сембердә «Авыл» исемле журнал чыгаруны оештыра. Журнал гади төрки телдә булып, урыннарда общиналарны берләштерү, суд эшләре, кибетләр ачу, зур булмаган җәмгыятьләр төзү кебек мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирү белән шөгыльләнә [Овул журнали].

Типография эшләреннән тыш, алар яңа рухтагы китаплар, газеталар сату һәм Төркестанда китапханәләр оештыру белән дә шөгыльләнәләр. Мәсәлән, 1909 елның 18 августында Исхак Шәрипов Фирганә өлкәсе хәрби губернаторына үтенеч белән мөрәҗәгать итә һәм Коканд шәһәрендә «Кашшофия» дип аталган китап кибете ачарга рөхсәт сорый. Үтенечтә кибеттә, китаплардан тыш, шулай ук газеталар сатуның да планлаштырылуы турында әйтелә. И. Шәрипов үзенең Коканд шәһәрендә 1895 елдан бирле яшәвен, шулай ук 5 ел хәрби хезмәттә булуын ассызыклый [Үз МА, 19 ф., 1 тасв., 28921 эш, б. 22а–22б]. Фирганә өлкәсенең хәрби губернаторы, үз чиратында, Коканд өязе башлыгыннан И. Шәрипов шәхесе турында мәгълүмат соратып алган. Коканд өязе башлыгы И. Шәриповны «артык панисламист» дип характерлаган, ә китап кибете ачуының максаты дини

фанатизм рухындагы китаплар белән сәүдә итү өчен, дип аңлаткан [Үз МА, 19 ф., 1 тасв., 28921 эш, б. 21а–21б].

1909 елгы мәгълүматларга караганда, Чустта – 2, Әндиҗанда – 18, Нәманганда – 20, Кокандта 32 китап кибете булган [Үз МА, 1 ф., 3 тасв., 540 эш, б. 180б]. Бу китап кибетләрендә Бомбейда, Истанбулда, Казанда, Ташкәнттә һәм Мәскәүдә нәшер ителгән 100 дән артык исемдәге китап сатылган [Үз МА, 1 ф., 3 тасв., 540 эш, б. 181б].

1913 елга Төркестан төбәгендә яшәүчеләр арасында Оренбургта чыгып килгән «Вакыт» газетасын укучылар саны кискен арта. Шуңа бәйле рәвештә җирле татарлар бу газетаны Төркестанда яңадан басуны оештырырга тырышып карыйлар. Ләкин хөкүмәттән рөхсәт булмагач, бу эш туктатыла [Үз МА, И. 4, 61 ф., 1 тасв., 1315 эш, б. 112б].

1917 елгы Февраль революциясеннән соң Төркестан җәдитчеләренең татар мәгърифәтчеләре белән басмачылык өлкәсендәге хезмәттәшлеге яңа дәрәҗәгә күтәрелә. Әхмәд-Зәки Вәлиди, Пулат Солиев, Кәбир Бәкер, Мөхтәр Бәкер һәм татар-башкортларның алар кебек үк үз халкы өчен генә түгел, бөтен төрки-мөселман дөньясы өчен җанын бирергә әзер торган башка вәкилләре Төркестандагы иҗтимагый-сәяси процессларда актив катнашалар, шулай ук түбәндәге газеталарны чыгаралар:

1. «Улуг Туркистон» газетасы 1918 елның 25 апреленнән 1917 елның 30 ноябренә кадәр Ташкентта татар телендә Кәбир Бәкер һәм С. Абдусатторов редакциясендә чыга[1]. Газета Татар Төркестанының үзәк советы һәм Ташкент татарлары берлеге җәмгыяте басмасы булып санала [Турдиев, с. 177].

2. «Эл байроги» газетасы 1918 елның 8 сентябреннән 1917 ел башына кадәр Кокандта үзбәк телендә Пулат Солиев һәм Ашурали Заһири редакциясендә Төркестан автономиясе хөкүмәте басмасы буларак чыга [Мингнаров, 2000, б. 24; кара: Германов, с. 15, 16].

3. «Фарғона саҳифаси» газетасы күренекле татар нашире Хөсәен Макаев тарафыннан үзбәк телендә 1917 елның 15 мартыннан чыгарыла башлый. Барысы 19 саны дөнья күрә [Жалолов, Ўзганбоев, б. 15].

4. «Кенгаш» газетасы 1917 елның 25 июненнән октябренә кадәр Ташкәнттә Әхмәд-Зәки Вәлиди һәм Мөнәвәр Кари редакциясендә мөселманнарның Төркестан Үзәк советы басмасы буларак басыла.

5. «Шурои Ислам» газетасы 1917 елның 16 маеннан 1917 елның июненә кадәр Ташкәнттә үзбәк телендә А. Баттол редакциясендә «Шурои Исламия» оешмасы басмасы буларак чыгарыла [Турдиев, с. 177].

6. «Чаён» журналы 1917 елның июненнән 1918 елның августына кадәр Ташкентта татар телендә Хәлиф Тулаков һәм Ибраһим Таһири редакциясендә Төркестанның милли эшчеләр секциясе басмасы буларак нәшер ителә.

[1] Төркестан матбугаты фидаииларының берсе булган Содик Абдусатторов 1919 елның иай аеннан октябрьгә кадәр Төркестан АССР Халык мәгрифе комиссары булып эшләгән. Кара: Үз МА, Р-34 фонд, 1 тасв., 132 эш, б. 485–488.

7. «Чўл чаёни» журналы 1918–1919 елларда Ташкентта татар телендә Ибраһим Таһир редакциясендә басыла [Исоқбоев, б. 107–120].

8. «Халқ дорулфунуни» 1918 елның 31 маенда Ташкентта Мөхтәр Бәкер (Бакиров) редакциясендә Төркестан Халык университеты басмасы буларак чыга башлый.

1917 елның декабреннән Нәманганда татар җәмгыяте инициативасы белән Х. Макаев редакциясендә «Фарғона саҳифаси» исемле яңа газета басыла башлый. Газета башка газеталардан еш чыгуы һәм иң соңгы мәгълүматларны җиткерүе белән аерылып тора [Фарғона нидоси].

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, татарлар басмачылык һәм нәшрият эшендә актив катнашалар, илдә совет власте урнашканнан соң да яңа режимны пропагандалауга «хезмәт итәләр».

**Әдәбият**

*Воҳидова К.А.* Исҳоқхон Жунайдуллоҳхўжа ўғли Ибрат ва унинг тарихий-илмий мероси (XIX аср охири – XX аср бошлари). Наманган: «Наманган» нашриёти, 2018.

*Германов В.А.* Профессор Пулат Салиев и его время. Ташкент: Фан, 2002.

*Долимов У.* Исҳоқхон тўра Ибрат. Тошкент: Шарқ, 1994.

*Долимов У.* Туркистонда жадид мактаблари. Тошкент: Университет, 2006.

*Жалолов А., Ўзганбоев Ҳ.* Ўзбек маърифатпарварлик адабиётининг тараққиётида вақтли матбуотнинг ўрни. Тошкент: Фан, 1993.

*Исоқбоев А.* Туркистон ижтимоий-сиёсий ва маданий ҳаётида татар-бошқирд маърифатпарварларининг фаолияти (XIX аср охири – XX аср бошлари): тарих фан. номз. ... дис. Наманган, 2008.

*Исҳоқхон тўра Ибрат.* Танланган асарлар. Тошкент: Маънавият, 2005.

*Каримуллин А.* Становление и развитие татарской советской книги (1917–1932). Казань: Татар. кн. изд-во, 1989.

*Мансуров У.* 1917–1924 йилларда Наманган шаҳрида халқ таълими ва маданий ҳаёт // Фарғона водийси тарихи янги тадқиқотларда 2-Республика илмий анжумани, 2012. Б. 302–303.

*Мингнаров А.* Туркистондаги ижтимоий-сиёсий жараёнларнинг миллий матбуотда ёритилиши (1917–1918 йиллар). Тошкент: Истиқлол нури, 2013.

*Мингнаров А.Т.* Туркистонда миллий озодлик масалалари давр миллий матбуотида (1917 йил февраль – 1918 йил ўрталари): тарих фан. номз. ... дис. Тошкент, 2000.

Овул журнали // Халқ дорулфунуни. 1918. 31 май.

*Rasulov A.* Turkistan ve Idili–Ural halklari arasindaki ilishkiler (1917–1924). Ankara, 2017. B. 220–221.

*Садриддинов А.* Фарғона водийсида матбаа-ноширлик тарихига доир (XIX аср охири – XX аср биринчи чораги) // Фарғона водийси тарихи янги тадқиқотларда: Республика илмий-амалий конференцияси материаллари. Андижон, 2015. Б. 275.

*Темиров Ф.* Пўлат Солиев. Тошкент: ABU MATBUOT-KONSALT, 2011.

*Турдиев Ш.* Среднеазиатские татары: роль и значение в культурной и политической жизни Туркестана первой четверти XX в. // Ислам в татарском мире: история и современность. Казань, 1997.

Ўзбек тилининг изоҳли луғати. Тошкент: «Ўзбекистон миллий энциклопедияси» Давлат илмий нашриёти, 2006.

*Умматов Р., Парпиев М.* Наманганнинг саркотиби. Тошкент: Voris-Nashriyot, 2019.

Үзбәкстан милли архивы (Үз МА). И. 1 фонд, 20 тасв., 4280 эш, б. 13.

Үз МА. И. 1 фонд, 3 тасв., 540 эш.

Үз МА. И. 19 фонд, 1 тасв., 28921 эш.

Үз МА. И. 4, 61 фонд, 1 тасв., 1315 эш.

Фарғона нидоси // Улуғ Туркистон. 1917. 31 декабрь. Үз МА, Р-34 фонд, 1 тасв., 132 эш, б. 485–488.

*Эрназаров Т., Акбаров А.* История печати Туркестана (1870 – 1925 гг.). Ташкент: Ўқитувчи, 1976.

***Рәсүлов Абдулла Нуретдин улы,***
*тарих фәннәре докторы, Нәманган дәүләт университеты профессоры (Үзбәкстан)*

УДК 28

***Г.Р. Сибгатуллина***

# ТАТАРЛАР ҺӘМ ИСЛАМ РЕФОРМАСЫ ПРОЕКТЫ: ФӘННИ БӘХӘСЛӘР, ЯҢА КАРАШЛАР

Данная статья представляет собой краткий обзор основных дискуссий, которые характеризуют сегодня зарубежные исследования ислама в Российской империи. Автор статьи уделяет особое внимание двум монографиям, вышедшим в конце 2019 – начале 2020 г., написанным под авторством Нэйтана Спаннауса и Даниэлле Росс. Эти две книги стали частью серии недавних публикаций, которые критикуют изучение мусульманской элиты России XIX – начала XX в. с точки зрения её принадлежности к джадидизму или кадимизму. В статье обсуждаются основные аргументы данной критики.

**Ключевые слова:** джадидизм, ислам в Российской империи, улемы, реформизм.

The article provides a brief overview of major discussions that characterise contemporary Western academic studies analysing Islam and Islamic culture in imperial Russia. The author of the article pays special attention to two monographs published in late 2019 – early 2020, written by Nathan Spannaus and Danielle Ross. These two books have become part of a series of recent publications that criticize the study of the Muslim elite of Russia in the 19th and early 20th centuries in terms of its belonging to Jadidism or Qadimism. The article discusses the main arguments of this criticism.

**Keywords:** Jadidism, Islam in the Russian Empire, *ʿulamāʾ*, reformism.

2020 ел башында татар модернизмы темасын өйрәнүгә багышланган ике әһәмиятле хезмәт дөнья күрде: Нэйтн Спаннаусның (Nathan Spannaus) «Ислам традицияләрен саклау: Габденнасыйр Курсави һәм модернизм реформаларының башлангычы» [Spannaus, 2019] һәм Даниэлле Росснең (Danielle Ross) «Татар империясе: Казан мөселманнары һәм империаль Рәсәйнең төзелеше» [Ross, 2020] китаплары. Ике басма да Идел-Урал төбәгенең XVIII гасырдан алып XXгасыр башына кадәрге тарихына яңа күзлектән карау, моңа кадәр игътибарга алынмаган шәхси бәйләнешләрне һәм иҗтимагый-сәяси шартларны ачыклау максатына хезмәт итә.

Авторлар үз хезмәтләрендә Көнбатышта күбесенчә 1991 елдан соң язылган академик тикшеренүләргә нигезләнә, алар революциягә кадәр яшәгән татар мөселман галимнәрен ике капма-каршы төркемгә – җәдидчелек һәм кадимчелек тарафдарларына катгый рәвештә бүлүне тәнкыйть итә. Беренчеләрдән булып бу өлкәдә тикшеренүләрне Михаэль Кемпер (Michael Kemper) башлап җибәргән иде: 1998 елда басылып чыккан китабында ул XVIII–XIX гасырларда яшәгән күренекле мөселман авторларның, алар арасында Г. Курсави кебек җәдидчелекнең атасы буларак танылган галимнәрнең фикерләрен өйрәнеп, бер-берсе белән чагыштырып карады [Kemper, 1998;

Кемпер 2008]. Кемпер фикеренчә, беренче буын «җәдидчеләр» дә, «кадимчеләр» дә ислам хокукы өлкәсендә тигез эшләде, «тәкълид» һәм «иҗтиһад» төшенчәләрен кулланып, ислам йолаларының дөрес үтәлешенә кагылышлы сорауларга җавап эзләү белән шөгыльләнде. Ягъни «реформатор» буларак танылган галимнәр – Габденнасыйр Курсави да, Шиһабетдин Мәрҗани дә исламның институциональ формаларына каршы чыкмады. Аларны өр-яңа, бөтенләй башка бер көч итеп күрсәтү фикере XX гасыр уртасында гына барлыкка килде, һәм бу юнәлеш Курсави, Мәрҗани кебек ислам дине галимнәрен үз чорларына хас булмаган контекстка бәйләп күрсәтү куркынычын тудырды. Нәтиҗәдә, «җәдидче» яки «кадимче» дип атау, бу галимнәрнең эшләрен һәм фикер сөрешләрен берьяклы гына яки дә тулысынча ялгыш итеп аңлатуга китерү мөмкинлеге ачыкланды.

Совет чорында ислам реформасы тарафдарларының күбесе, башта совет хакимияте һәм халык мәгарифе системасына үтеп керде, соңыннан исә сәяси үзгәрешләр чорында эзәрлекләнде яки сөргенгә җибәрелде. М. Кемпер фикеренчә, сталинизм чоры узгач, татар марксист галимнәре җәдидчеләр хәрәкәтен «прогрессив» дип бәяләп, гомумән мөселманлыктан аерып, татарларга хас милли бер феномен рәвешендә тасвирлап, татарлар арасында социализм идеяләрен кабул итү өчен нигез булды, дип күрсәттеләр [Kemper, 2015]. Татар тарихын бу юнәлештә анализлау, голәмәне прогрессив һәм консерватив төркемнәргә бүлү совет чорының соңгы этабында язылган хезмәтләрдә дә дәвам итте һәм постсовет академик әдәбиятына үтеп керде. «Җирле мөселман мәгърифәтчелеге» дискурсы 1980–1990 елларда татар милләтчеләре арасында тамыр җибәреп, бүгенге көнгә кадәр Татарстанның күп кенә тарихчылары, тел һәм әдәбият галимнәре тарафыннан әле дә кулланыла [Bustanov and Kemper, 2012].

Соңгы елларда Көнбатышта язылган фәнни хезмәтләр исә Россия хакимияте астында яшәгән ислам мәдәниятенең эволюциясе күпкә катлаулырак булуын күрсәтә. Аллен Франк (Allen Frank) бу турыда үзенең 2001 елда басылган монографиясендә язып чыккан иде инде: аның фикеренчә, Россия исламында XVIII гасырдан башланган үзгәрешләр Европа фикерләренең мөселманнар арасына үтеп керүе һәм таралуы белән генә бәйле түгел. Рус хөкүмәтенең рәсми ислам институтларын булдыруы, мөселман халкы лидерларына сәяси функцияләр йөкләве, Европаның алгарыш фикерләренә карый, тирәнрәк эффект тудыра [Frank, 2001].Тагын шуны да истә тотарга кирәк: Россия империясе тарихының соңгы чорында, сәяси һәм икътисади үзгәрешләр белән мавыгу үзләрен «реформаторлар» дип атаган кешеләргә генә хас булмады. Традиционистларның «наданлыгы», карашларының катгыйлыгы еш кына арттырылып, «тискәре фикерле руханилар» феноменын барлыкка китерде. Югыйсә, яңа индустриаль, глобаль чынбарлык шартларында туган прогрессив һәм консерватив карашларның бәрелеше күпкә катлаулырак булып, бу ике төркемнең үзара бәхәсендә кителгән аргументлар галимнәр игътибарына бик тә лаек [Frank, 2016].

Шулай ук империя идарәсе астында яшәгән татар мөселманнарның тарихын Урта Азиядәге иҗтимагый процесслардан аерып өйрәнүнең ялгышлыгы күренде. Үзбәк, казакъ һәм таҗиклардагы «реформизм» проблематикасын үз вакытында Әдиб Халид җентекләп тикшергән иде [Khalid, 1999], аннан соң башка күренекле галимнәр дә бу хакта хезмәтләр язды [мәсәлән, Sahadeo, 2007; Campbell, 2017][1]. Бу тикшеренүләр нәтиҗәсендә Кырым, Казан, Урта Азия мөселманнары арасындагы бәйләнешләр, фикер йөртүләрдәге уртаклык, үзара мөнәсәбәтләрендә рус ориенталист галимнәренең һәм христиан әһелләренең йогынтысы билгеләнде [Crews, 2006; Campbell, 2015; Pickett, 2020]. Соңгы биш елда чыккан әсәрләрдә совет чорында миллиятче һәм «дөньяви рухлы» фикер йөртүче дип бәяләнгән күренекле шәхесләрнең ислам хокукы теориясе буенча бәхәсләрдә катнашулары ачыкланды. XX гасыр башындагы мөселман мәдәни реформасының киң интеллектуаль агымга нигезләнгәнлеге, ул агымда сәләфи аспектларның да урын алуы билгеле булды [Eden, Sartori, DeWeese 2016; Sartori 2016].

Яңа чыккан академик хезмәтләрдә «җәдидче – кадимче» терминнарын куллану практикасы әкренләп юкка чыга бара. Моның соңгы җитди этәрелеше булып, Девин Девизның (Devin Deweese) мөселман реформизмын өйрәнү өлкәсендә тәнкыйди караш кирәклеген кисәткән мәкаләсе булды [De Weese, 2016]. Кадимчелек яки җәдидчелекнең бердәм хәрәкәт булмавын, аерым шәхесләрнең үз-үзләрен теге яки бу тараф карашларына шартлы яки вакытлыча гына бәйләүләре бүген инде шик астына алынмый. Д. Девиз шуңа күрә бу тарихи чор өстендә эшләгән галимнәргә карата «ислам модернизмы», «традиционализм» кебек терминнарны кулланганда сак булырга, реформаторларның һәм аларга каршы чыккан тарафларның фикерләрен һәм чыганакларын критик анализларга кирәклеген язды.

**Беренче реформаторлар кемнәр иде?**

1991 елда Советлар Союзының таркалуы һәм аннан соң постсовет дәүләтләрнең китапханәләре һәм архивлары ачылу татар ислах хәрәкәтен өйрәнү өстендә эшләгән галимнәргә зур гына мөмкинлекләр тудырды, бу бай мирасны дөньяга чыгару эше һаман да дәвам итә. Гарәп, фарсы, төрки-татар һәм рус телләрен яхшы белүче Н. Спаннаус һәм Д. Росс үз хезмәтләрендә күпләгән кулъязма чыганакларны, газета-журнал, архив документаларын куллandылар. Шуңа күрә аларның хезмәтләре яңа теоретик карашлар белән кызыксынучы укучыларның гына түгел, моңа кадәр билгеле булган документларны яңача укырга һәм әлегә кадәр ачылмаган материаллар белән танышырга теләүчеләрнең дә игътибарына лаек.

Чагыштырмача яшь галим булса да, Нэйтн Спаннаус татар дини мирасын өйрәнүчеләр арасында үз урынын тапты инде. Аның Г. Курсавига багышланган хезмәтләре [Spannaus, 2012; 2016], һичшиксез,

[1] Мөселманнарда мәгариф һәм реформизм турында язылган фәнни әдәбият исемлеген кара: [Morrison, 2016] .

Россия империясендә яшәгән мөселман халыкларның элитасы, дини институтлары, фикер системалары хакында язылган җитди тикшеренүләр сериясенә керә [Spannaus, 2013; 2014; 2015]. Спаннаус фикеренчә, 1750–1850 еллар арасындагы йөз ел вакыт, мөгаен, Идел-Урал мөселманнары тарихында үзгәрешләргә иң бай чорны тәшкил итә. Ул чорда җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә диярлек мөһим трансформацияләр булып уза. Идел-Урал буе мөселманнары, XVI гасырдан бирле Россия хакимлеге астында яшәсә дә, империя бюрократиясенә бер гасырдан соң гына кертелде. Бу процесста иң әһәмиятле вакыйга дип 1788 елда ислам дине галимнәре өчен рәсми иерархия оештыруны санарга кирәк. Нәтиҗәдә, мөселман җәмгыятьләренең патша дәүләте белән мөнәсәбәтләре яңа бер форма алды. Спаннаус яңа басылган китабында бу үзгәрешләрнең татар зыялылары арасында ничек чагылуын күрсәтергә омтыла, шул максаттан чыгып, ул чорның күренекле шәхесен – Габденнасыйр Курсавины алып карый, һәм аның фикерләрен заманының мәдәни һәм тарихи контекстына куеп, галим күз алдына китергән ислах төшенчәсенең эчтәлеген һәм яңалыкларын тирәнтен анализлый. Автор моның өчен Курсавиның замандашлары булган башка галимнәрнең эшләренә таяна, аның фикерләрен ислам дөньясындагы актуаль тенденцияләр белән бәйли һәм чагыштыра.

Н. Спаннаусның хезмәте ун бүлектән тора. Беренче бүлектә ул китапның язылу максатларын бәян итә, икенче бүлектә Болгар мөселманнарының Россия дәүләте белән мөнәсәбәтләре тарихын, татарлар тормышында XVIII һәм XIX гасыр башындагы җәмгыяви үзгәрешләрне ачыклый. Китапның төп өлешен тәшкил итүче өченче – алтынчы бүлекләр Г. Курсавиның фикерләрен анализлауга багышланган. Бу бүлекләрдә Спаннаус, Курсави хакында моңа кадәр язылган хезмәтләрдән ераклашырга теләпме, галимнең иҗади мирасын өйрәнүдә яңа алым тәкъдим итәргә омтыла. Автор Курсавиның иҗтиһадка карашын тикшерә һәм аның формалашуына ислам институтларының дәүләт контроле астында булуы йогынты ясавын күрә, галимнең постклассик каләм традициясе эчендә калып, бу чорга хас теологик бәхәсләрдәге үзгәрешләрне чагылдыруын күрсәтә. Җиденче бүлектә Спаннаус Курсави фикерләрен тарихи контекстка бәйле рәвештә анализлап, аларның ислам интеллектуаль тарихына, аеруча XVIII гасыр дини әдәбиятына тәэсире турында яза. Сигезенче һәм тугызынчы бүлекләр, алдагыларыннан аермалы буларак, ислах мәсьәләсенә киңрәк иҗтимагый-сәяси карашлардан торып якын килә, XVIII йөзнең икенче яртысыннан алып Беренче бөтендөнья сугышына кадәр мөселманнар арасында барган процессларны, даими үзгәреп торган тарихи мохитне тасвирлый. Унынчы бүлектә бу процесларның ислам модернистларын алгы планга чыгаруын һәм җәдидчеләрнең Курсави фикеренә мөрәҗәгать итүләрен раслый.

Спаннаус ясаган төп нәтиҗәләренең берсе: Курсавины, XX гасыр хәрәкәте күзлегеннән генә карап,»көчләп», җәдидчелеккә якынлаштырырга тырышырга ярамый. Моның урынына Курсавиның

ислах фикерләрен ислам дине тарихындагы интеллектуаль фикерләүнең мөстәкыйль бер өлеше итеп карау күпкә урынлырак икәнлеге аңлашыла. Курсавины беренче төркем җәдидчеләр, прогрессистлар арасына кую, аның Бохара голәмәсе белән бәхәсләрен теологик эчтәлегеннән мәхрүм итүгә һәм ул тарихи чорны хәзерге рационализм тәгълиматы файдасына бәяләүгә китерә. Курсавиның позициясе күп кенә җәдидчеләр алга сөргән мәзһәбсез, туры, рационалистик караштан аерылып тора. Аның әсәрләре үз чорының хәнәфи-матуриди традицияләренә тулысынча туры килә һәм шул заманда рус җәмгыятендә барган үзгәрешләр белән аз бәйләнештә тора. Галимнең ислах аңлаешы татарларның иҗтимагый, мәдәни һәм сәяси үсеше белән бәйләнештә каралганда гына фәнни мәгънәгә ия. XVIII гасыр ислам реформасының (марксистик) модернизация процессына бернинди бәйләнеше дә юк, шуңа да аны феодаль яки урта гасыр ислам фикерләреннән ераклашу дип уку, Курсавиның фикере өчен бик мөһим булган теологик карашларны тулысынча юкка чыгару булып чыга, дип яза Н. Спаннаус.

**XX гасыр җәдидчелегенең нигезләре нәрсәдә?**

Даниэлле Росcның китабы да татар мөселманнары арасында фикер үсешен тикшерүгә багышланган. Юта университетында эшләүче Д. Росс – Россия империясе белән бәйле ислам кануннары һәм мөселман мәгарифе буенча белгеч[1]. Яңа чыккан китабында ул Россия империясе барлыкка килүдә мөселманнарның ролен билгеләү, XVIII–XX гасырлар тарихын мөселманнар күзлегеннән карап өйрәнү максатын куя һәм Идел-Урал буе мөселманнарының XVIII гасырда башланган иҗтимагый-сәяси тормышындагы кискен үзгәрешләрнең әһәмиятенә игътибар итә. Росс фикеренчә, бу үзгәрешләрне Казан татарлары үз файдаларына куллана алды: 1700 еллардан алып Россиянең Көньяк Уралга, Көнбатыш Себергә һәм Казакъ даласына таба киңәюе татарларның сәүдә һәм гыйльми элемтәләренең дә үсүенә тәэсир итте. Татарларның бу вакытта Россиядә яшәгән башка мөселманнардан бер баш өстен образы барлыкка килде: алар алгы планга чыгып, рус булмаган халыклар арасында мәгърифәт таратучылар булып, империя түрәләре арасында ышаныч казанды.Үзләрен прогрессив фикерләрне башка мөселманнар арасында тарату өлкәсендә лидер буларак танытып, Россия империясенең рәсми төзелешендә үзләреннән өлеш керттеләр, ди.

Хронологик тәртиптә язылган бу китапта мөселманнар тарихы Россия җәмгыятендәге тышкы һәм эчке үзгәрешләр белән бәйләп карала. Беренче бүлектә автор 1600 еллар ахырыннан алып XVIII йөз ахырына кадәрге чорда Казан татарларының Урал һәм Көнбатыш Себергә таба таралу этапларын җентекләп аңлата. XVIII йөз ахырында

[1] Росcның соңгы елларда язылган мәкаләләре арасында түбәндәге хезмәтен билгеләп үтәргә була: [Ross, 2019; 2017a; 2017b] . Моннан тыш аның быел Паоло Сартори белән бергә редакцияләнгән күләмле хезмәте дә басылып чыкты [Sartori and Ross, 2020].

барлыкка килгән Оренбург Мөселман диния нәзарәте ислам динендәге халыклар белән идарә итү өлкәсендә мөһим роль уйнарга тиешлегенә басым ясый һәм китабының икенче бүлегендә 1800 еллар башында Диния нәзарәтендәге хәлләрне, анда барлыкка килгән низагларны анализлый. Автор әлеге низаглар Диния нәзарәтенең тотрыклы бер институт булмавын, империя хакимияте өчен нәтиҗәле административ корал буларак эшли алмавын дәлилли. Өченче бүлек 1800–1850 елларда матбугат таралуның һәм арзан кәгазь җитештерүнең мәгариф үсешенә ясаган тәэсирен һәм бу процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа дини күренешләрне анализлый; бу үзгәрешләрнең голәмә арасында борчылу тудыруын ачыклый.

Д. Росс реформаторлар һәм консерватив катламнар арасында зур иҗтимагый һәм нәзари каршылык бар дигән фикерне шик астына куя. Аның фикеренчә, Идел-Урал буе мөселман җәмгыятенең социаль элитасы булган Казан голәмәсе XVIII гасыр башыннан XX гасыр башына кадәр әллә ни зур үзгәреш кичермәгән. Китабының дүртенче бүлегендә Д. Росс татар алдынгы фикер ияләренең институциональ базасын Мәчкәрә җәмгыятенең эшчәнлегендә реконструкцияләп карый. Автор фикеренчә, 1800 еллар уртасында Мәчкәрә мохите, ягъни бу төбәкнең күренекле шәхесләре, мәчетләре һәм мәдрәсәләре, Казан һәм Оренбург мөселманнарының интеллектуаль һәм иҗтимагый тормышын формалаштырды. Бишенче бүлектә автор Мәчкәрәдән чыккан ике күренекле галимгә – Шиһабетдин Мәрҗани һәм Хөсәен Фәезхановка игътибар бирә, һәм татар мөселманнарының ориенталистик проектларда катнашуын раслый.

Алтынчы – җиденче бүлекләр, гомумән, Уралда, Казак далаларында, Урта Азиядә һәм 1880 еллардан алып Россия-Кытай чикләрендә булган мөселман мәгарифе реформасын ачыклауга багышланган. Д. Росс теологиянең һәм фундаменталистик хокук реформасының күтәрелүенә һәм аларның Казан татар җәмгыятенең таянычы булган фәнни мохиткә ясаган йогынтысына игътибар бирә. Автор фикеренчә, иҗтимагый-сәяси шартларның кискен үзгәреше (мәгариф йортларындагы үзгәреш, урбанизация һәм белем алу мөмкинлекләренең киңәюе) белемле яшь мөселман буынын барлыкка китерде. Бу яшьләрнең күпчелеге, алган гыйлемнәре аркасында гамәлдәге дини оешмаларга кереп урнаша алмаганга, өлкән буынга каршы протест белдерергә мәҗбүр булды. Мәчкәрә голәмәсе йогынтысында барлыкка килгән бу яшь зыялылар, Идел-Урал мөселман җәмгыятенең лидерлыгын даулап, миллиятчелек агымына мөрәҗәгать иттеләр, ди автор.

Соңгы ике бүлек татар һәм рус мәдәни империализм фикер системаларының үзара бәрелешен күрсәтә, һәм бу низагның рус түрәләре белән Казан татарлары арасындагы мөнәсәбәтләрнең кискенләшүенә китерүен аңлата. Д. Росс фикеренчә, татарларның ике гасырдан артык Россия чикләре эчендә арадашчылык итүе һәм соңыннан модерн ислам хәрәкәте лидерлары булуы, татар җәмгыятен һәрвакыт үзгәрештә тотты. Рус һәм ислам мәдәнияте аларның дин, мәгариф, сәясәт

турында фикер сөрешләренә зур йогынты ясады. 1917 ел Февраль революциясеннән соң татарлар арасында алгы планга чыккан сәяси һәм милләт төзү амбицияләрен күп очракта әлеге йогынты белән аңлатырга мөмкин.

Бу мәкаләдә бәяләнгән ике китап та авторларының күпьеллык житди хезмәт җимеше, архивларда эшләү нәтиҗәсе дип кабул ителергә хаклы. Д. Росс та, Н. Спаннаус та, пазл кисәкләрен берләштергәндәй, үзләреннән алда язылган хезмәтләрдәге табышларны, Россия империясе чоры исламын өйрәнү өлкәсендәге фикерләрне җентекләп анализлый һәм баета. Әлбәттә, мондый тикшеренү проектлары, күп кенә четерекле күренешләрне аңлатса да, җавабы әлегәчә табылмаган сораулар да кала бирә.

Шундый сорауларның берсе XIX–XX гасыр башында кулланылган дини һәм дөньяви (секуляр) төшенчәләрнең нигезләре, аларның мәгънәви төрлелеге белән бәйле. Совет һәм постсовет фәнни әдәбиятында реформаторлар дөньяви гыйлемнәр, хатын-кыз хокукларын яклау һәм динне хосусыйлаштыру өчен көрәшүче көч буларак тасвирландылар. Әмма соңгы елларда басылып чыккан тикшеренүләр бу фикерне шик астына куя башлады. Татар ислах хәрәкәтендә секуляризм элементлары бар идеме? Дөньявилыкны ул чорның мөселман һәм рус җәмәгать лидерлары ничек тасвирладылар? Бу сорауларга җавап эзләү шулай ук чыганаклар белән эшләүне таләп итә, чөнки бер гасыр элек һәм бүген бирелгән бәяләмәләр бер-берсеннән шактый аерылып торалар.

Н. Спаннаус үз китабында нәкъ менә терминнарның үзгәрешен, аларны куллануның билгеле бер социаль-икътисади контекстка бәйле булуын ачыклый, һәм чыганак буларак үзе кулланган текстларга да тәнкыйди караш кирәклеген искәртә. Шулай ук, бу чор фикер үсешен сурәтләү өчен кулланылган терминологик аппаратка да игътибар белән карау зарурлыгына да басым ясый: кулланылышта калган терминнарның бәхәсле яки бөтенләй ялгыш мәгънәләр белән йөкле булу мөмкинлеген, аларның аерым күренешләрне объектив чагылдыра алмавын фаразлый.

Д. Росcның хезмәте билгеле бер мөселман шәхесен яки аерым бер тарихи чорны аңларга тырышкан кешегә әлеге киң контекстларның – берничә ил яки гасырларга сузылган үзгәрешләрнең ни кадәр зур әһәмияткә ия икәнлегенә бер дәлил булып тора. Россия мөселманнарының халәтен глобаль үзгәрешләр белән бәйләп өйрәнүне яңа табышлар тудырачак бер юнәлеш дип кабул итәргә кирәк. Россия империясендәге мөселманнарның тормышы башка мөселман колонияләреннән (Һиндстан, Малайзия, Индонезия) һәм күпчелек мөселман илләреннән (мәслән, Госманлы империясеннән) шактый аерылып торса да, күп кенә процессларның охшаш булуы да күзгә ташлана. Бу мәсьәләләр әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән[1].

[1] Бу юнәлештә эшләгән авторлар арасында кара: [Morrison, 2006; Meyer, 2014; Gould and Shikhaliev, 2017].

Россия исламына һәм аның интеллектуаль традицияләренә багышланган хезмәтләр, инглиз телендә сөйләшүче академик мохиттә дискуссияләрнең һәм конструктив тәнкыйтьнең артуына, гомумән, бу өлкәнең алга таба үсешенә ярдәм итә. Кызганычка каршы, бу төр фәнни эшләрдәге табышлар татар укучыларына зур тоткарлык белән килеп ирешә. Тик шуны онытмаска кирәк, мондый әсәрләрнең күпчелеге тарихыбызны яхшырак аңларга һәм өйрәнергә, үзебезне читтән карап бәяләргә уникаль мөмкинлек бирә. Бу язмабыз әлеге бушлыкны аз да булса тутырырга ярдәм итәр һәм инглиз телендәге тикшеренүләргә татар укучыларының кызыксынуын арттырыр, дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**

*Bustanov, Alfrid K. and Michael Kemper.* From Mirasism to Euro-Islam: The Translation of Islamic Legal Debates into Tatar Secular Cultural Heritage // Islamic Authority and the Russian Language: Studies on Texts from European Russia, the North Caucasus and West Siberia, 29–53. Amsterdam: Pegasus, 2012..

*Campbell, Elena*. The Muslim Question and Russian Imperial Governance. I. Indiana University Press, 2015.

*Campbell, Ian W.* Knowledge and the Ends of Empire: Kazak Intermediaries and Russian Rule on the Steppe, 1731–1917. Ithaca, NY: Cornell University Press, 2017.

*Crews, Robert D.* For Prophet and Tsar. Cambridge, MA: Harvard University Press, 2006.

*DeWeese, Devin.* It Was a Dark and Stagnant Night (‘til the Jadids Brought the Light): Clichés, Biases, and False Dichotomies in the Intellectual History of Central Asia // Journal of the Economic and Social History of the Orient. 2016. 59 (1–2). P. 37–92.

*Eden, Jeff, Paolo Sartori, and Devin DeWeese.* Moving Beyond Modernism: Rethinking Cultural Change in Muslim Eurasia (19th–20th Centuries) // Journal of the Economic and Social History of the Orient. 2016. 59 (1–2). P. 1–36. https://doi.org/10.1163/15685209-12341392.

*Frank, Allen J.* Muslim Religious Institutions in Imperial Russia: The Islamic World of Novouzensk District and the Kazakh Inner Horde, 1780–1910. Leiden: Brill, 2001.

*Frank, Allen J.* Muslim Cultural Decline in Imperial Russia: A Manufactured Crisis // Journal of the Economic and Social History of the Orient. 2016. 59 (1–2). P. 166–192.

*Gould, Rebecca Ruth, and Shamil Shikhaliev*. A Tale of Two Scholars: Daghestan Modernists in Early Twentieth Century Egypt // History Today forthcoming (June). 2017. https://papers.ssrn.com/abstract=2995762.

*Kemper, Michael.* Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: der islamische Diskurs unter russischer Herrschaft. Berlin: Schwarz, 1998.

*Kemper, Michael.* Imperial Russia as Dar Al-Islam? Nineteenth-Century Debates on Ijtihad and Taqlid among the Volga Tatars // Encounters, 2015. no. 6. P. 95–124.

*Khalid, Adeeb.* The Politics of Muslim Cultural Reform. Berkeley, CA: University of California Press, 1999.

*Meyer, James H.* Turks Across Empires: Marketing Muslim Identity in the Russian-Ottoman Borderlands, 1856–1914. Oxford University Press, 2014.

*Morrison, Alexander.* Russian Rule in Turkestan and the Example of British India, c. 1860–1917 // The Slavonic and East European Review. 2006. 84 (4). P. 666–707.

*Morrison, Alexander, ed.* Muslims and Modernity in the Russian Empire // The Slavonic and East European Review. 2016. 94 (4). P. 715–724.

*Pickett, James.* Polymaths of Islam: Power and Networks of Knowledge in Central Asia. Cornell University Press, 2020.

*Ross, Danielle.* Muslim Charity Under Russian Rule: Waqf, Sadaqa, and Zakat in Late Imperial Russia. Islamic Law and Society. 2017a. 24. P. 7–111.

*Ross, Danielle.* Making Muslim Women Political : Imagining the Wartime Woman in the Russian Muslim Women's Journal Suyumbika // Revue Des Mondes Musulmans et de La Méditerranée. 2017b. no. 141 (June). P. 137–153.

*Ross, Danielle.* The Age of the 'Socialist-Wahhabi-Nationalist Revolutionary': The Fusion of Islamic Fundamentalism and Socialism in Tatar Nationalist Thought, 1898–1917. Genealogy. 2019. 3 (4), 58. P. 1–18.

*Ross, Danielle.* Tatar Empire: Kazan's Muslims and the Making of Imperial Russia. Bloomington, IN: Indiana University Press, 2020.

*Sahadeo, Jeff.* Russian Colonial Society in Tashkent, 1865–1923. Bloomington, IN: Indiana University Press, 2007.

*Sartori, Paolo.* Ijtihād in Bukhara: Central Asian Jadidism and Local Genealogies of Cultural Change // Journal of the Economic and Social History of the Orient. 2016. 59 (1–2). P. 193–236.

*Sartori, Paolo, and Danielle Ross.* Sharia in the Russian Empire: The Reach and Limits of Islamic Law in Central Eurasia, 1550–1900. Edinburgh University Pres, 2020.

*Spannaus, Nathan.* Islamic Thought and Revivalism in the Russian Empire: An Intellectual Biography of Abū Nasr Qūrsāwī (1776–1812): Ph.D thesis. McGill University, 2012.

*Spannaus, Nathan.* The Decline of the Ākhūnd and the Transformation of Islamic Law under the Russian Empire // Islamic Law and Society. 2013. 20 (3). P. 202–241.

*Spannaus, Nathan.* Formalism, Puritanicalism, Traditionalism: Approaches to Islamic Legal Reasoning in the 19th-Century Russian Empire // The Muslim World. 2014. 104 (3). P. 354–378.

*Spannaus, Nathan.* Šihāb Al-Dīn al-Marǧānī on the Divine Attributes: A Study in Kalām in the 19th Century // Arabica. 2015. 62 (1). P. 74–98.

*Spannaus, Nathan.* The Ur-Text of Jadidism: Abū Naṣr Qūrṣāwī's Irshād and the Historiography of Muslim Modernism in Russia // Journal of the Economic and Social History of the Orient. 2016. 59 (1–2). P. 93–125.

*Spannaus, Nathan.* Preserving Islamic Tradition: Abū Naṣr Qūrṣāwī and the Beginnings of Modern Reformism. Oxford: Oxford University Press, 2019.

*Кемпер, Михаэль.* Суфии и ученые в Татарстане и Башкортостане. Исламский дискурс под русским господством. Казань: Российский исламский университет, 2008. 656 с.

***Сибгатуллина Гөлназ Рифкать кызы,***
*Ph.Dr. социолингвистика докторы, Амстердам Университеты*
*тарихи тикшеренүләр үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 398.2

***К.М. Миңнуллин,***
***И.Г. Закирова***

## ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕН БАРЛАУ ЮЛЫНДА

В статьи приводится обзор истории собирания и изучения татарских народных сказок. История изучения татарских народных сказок своими корнями восходит к XIX веку. В фольклорном фонде Института языка, литературы и искусства хранятся многочисленные тексты татарских сказок. Часть этих сказок изданы как в виде отдельных сборников, так и в многотомном академическом издании «Татарское народное творчество» на татарском и русском языках.
**Ключевые слова:** татарский сказки, фольклорный фонд, история изучения.

The article provides an overview of the history of collecting and studying Tatar folk tales. The history of studying Tatar folk tales dates back to the XIX century. The folklore Fund of the Institute of language, literature and art contains numerous texts of Tatar fairy tales. Some of these tales are published as separate collections, and in the multi-volume academic publication «Tatar folk art» in Tatar and Russian.
**Keywords:** Tatar fairy tales, folklore Fund, history of study.

Хәзерге вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә урнашкан фольклор фондында күпсанлы әкият текстлары саклана. Бу текстлар – озак еллар дәвамында Институтның фольклор секторында, соңрак халык иҗаты бүлегендә эшләгән галимнәр тырышлыгы белән тупланган әсәрләр. Бу әкиятләрнең иң уңышлы вариантлары «Татар халык иҗаты» җыелмасы томнарында, күпсанлы җыентыкларда дөнья күргән. Аларны фәнни яктан өйрәнү, яңа җыентыкларга кертү дәвам итә.

Әкиятләрне халыктан туплау һәм бастырып чыгару эшенең башында Мартиньян Иванов [Иванов, 1842] белән Салихҗан Кукләшев [Кукляшев, 1859] тора. XIX йөзнең икенче яртысында Себер татарларының әкиятләрен академик В.В. Радлов җыя [Радлов, 1872]. Шул ук чорда В.Н. Витевскийның [Витевский, 1891], Габделгалләм Фәезхановның [Фәезханов, 1890], Таип Яхинның [Яхин, 1900], Н.Ф. Катановның [Катанов, 1898] татар әкиятләренә мөнәсәбәтле хезмәтләре, әкият җыентыклары дөнья күрә. Халык әкиятләрен җыюга бөек мәгърифәтче галим Каюм Насыйри да зур өлеш кертә [Насыйров, 1900].

Татар әкиятләрен туплауда чит ил галимнәренең дә өлеше бар. Мәсәлән, XIX йөздә венгр галиме Габор Балинт Казан губернасының Мамадыш, Лаеш өязләрендә язып алып, «Казан татарларының телен тикшерү» дигән хезмәтендә 34 әкият текстын урнаштырган [Balint, 1875]. Фин профессоры Хейкки Паасонен 1899 елда татар теленең

көнбатыш диалектын өйрәнү максаты белән килеп, Самара губернасының Бөгелмә өязе авылларында (хәзерге вакытта бу авыллар Чирмешән районына һәм Самара өлкәсенә карый) халык иҗатына караган материал туплый. Ул туплаган материалларны «Мишәр-татар халык поэзиясе» дигән исемдә, аерым китап итеп, Эйно Каранка бастырып чыгара [Paasonen, 1953]. Бу җыентыкка 21 әкият тексты кертелгән. Венгр галиме Игнац Кунош тарафыннан Беренче бөтендөнья сугышы чорында (1914–1918) Чехиянең Эгер һәм Венгриянең Эстергом шәһәрләре тирәсенә урнаштырылган хәрби лагерьларда әсирләрдән шактый гына әкиятләр язып алына [Kúnos, 1989].

Татар әкиятләрен өйрәнүнең XIX гасырга караган чорын шартлы рәвештә бу эшчәнлекнең башлангыч чоры дип атарга мөмкин. Бу вакытта татар халкының төрле этник төркемнәренең әкиятләре язып алына, аларның күбесе басылып чыга, жанрны фәнни яктан өйрәнүдә беренче адымнар ясала.

XX гасыр башында әкиятләрне өйрәнү тарихында бөек татар шагыйре Г. Тукайның да роле зур була. Г. Тукай 1910 елда Казан шәһәренең Шәрык клубында «Халык әдәбияты» дигән темага лекция сөйли. Халык иҗатына багышланган бу лекциясендә Г. Тукай, татар фольклористикасы тарихында беренчеләрдән булып, халык хикәятләренең язма әсәрләрдән аермасын күрсәтә, А.С. Пушкинның «Алтын балык» һәм «Алтын әтәч» әсәрләре мисалында, халык телендә йөргән хикәят яки әкиятләрнең әдәби әсәр булып китә алуларын аңлата. Шагыйрь үзе дә фольклорга нәтиҗәле мөрәҗәгать итә, аның татар халкының аерым әкиятләрен һәм мифологик хикәятләрен файдаланып язган «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән сарык» әсәрләре татар әдәбиятының алтын хәзинәсенә керә. Г. Тукайның халык әкиятләрен яратуы шагыйрьнең замандашлары истәлекләрендә дә искә алына, алар аның мәдрәсәдә укыган елларында шәкертләргә әкиятләр сөйләве турында язалар. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Г. Тукайга нисбәттә теркәлгән өч әкият тексты саклана. Аларны Институтка мәдрәсәдә шагыйрь белән бергә укыган Шәриф Каюмов җибәргән. Ул Г. Тукайның бу әкиятләрне еш сөйләвен, шагыйрьнең стилен сакларга тырышып язуын искәртә. Әлеге әкиятләрне А. Гайнетдинов (текстларны бераз әдәбиләштерергә омтылган зур булмаган үзгәрешләр белән) 2011–2013 елларда «Мәдәни җомга» газетасында бастырып чыгарды.

1921 елда Казанда беренче фәнни оешма буларак Гыйльми үзәк ачылу белән татар фольклорын туплау һәм өйрәнүдә яңа этап башлана. 1926 елда М.А. Васильев һәм Г. Рәхим тарафыннан Гыйльми үзәк карамагында эшләнгән «Фольклор һәм халык әдәбияты җыю өчен кулланма» басылып чыга. 1925–1927 елларда Гыйльми үзәккә күп санда әкият, җыр, бәет һәм башка жанрларга караган әсәрләр килә. 1933 елга кадәр Үзәк тарафыннан татар фольклорының төрле жанрларына караган йөзләрчә текст туплана. Кызганычка каршы, Үзәкнең шәхес культы елларында югалган архивы турында әлегә мәгълүмат юк.

М. Горький Совет язучыларының 1934 елда узган беренче съездында «Үзегезнең фольклорыгызны җыегыз, аңардан өйрәнегез, аны эшкәртегез. Ул сезгә дә, безгә дә, Союзның шагыйрьләренә һәм прозаикларына бик күп материал бирәчәк. Үткәнебезне никадәр яхшырак белсәк, үзебез барлыкка китергән бүгенгенең бөек әһәмиятен шулкадәр тирәнрәк һәм шатлык белән аңлаячакбыз» дип мөрәҗәгать итә [Горький, 1953]. Әдипнең бу сүзләре лозунгка әйләнә, бу хәрәкәткә язучылар гына түгел, гади халык та кушылып китә. Шушы мөрәҗәгатькә һәм мөрәҗәгатькә нисбәттә алга куелган бурычларга җавап итеп, төрле төбәкләргә һәм хәтта аерым оешмаларга махсус фольклор экспедицияләре оештырыла башлый. Мәсәлән, Татарстанның Арча районы авылларына, Казанның Вахитов исемендәге заводына, Казан җитен комбинатына барып үткәрелгән шундый экспедицияләр вакытында күпсанлы фольклор материалы туплана, шул исәптән 32 әкият тексты да язып алына.

1936 елда Татарстан Язучылар союзы оештырган фольклор экспедицияләре Татарстанның Буа, Биләр, Саба районнарында шактый материал туплый. Бу елларда татар халык әкиятләрен фольклор фәне таләпләренә туры китереп җыю эшен язучы Г. Бәширов (Г. Разин) башлап җибәрә. Ул, Татарстанның күп кенә авылларында булып, әкиятләрне, кемнән язып алуларын күрсәтеп, халыкның сөйләм үзенчәлекләрен саклап язып ала. Бу эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак, 1940 елда Г. Бәширов җыйган әкиятләр «Халык әкиятләре» дигән китап булып дөнья күрә. Кереш мәкаләдә татар әкиятчеләре, аларның репертуары хакында мәгълүмат бирелгән. Шушы ук елда Х. Ярми белән Ә. Исхак төзегән «Халык иҗаты» дигән җыентык дөнья күрә. Бу китапта да татар халык әкиятләренә зур урын бирелгән. Г. Бәширов татар әкиятләрен туплау һәм бастырып чыгару эшен алга таба да дәвам итә. Хәмит Ярми белән берлектә төзелгән «Татар халык әкиятләре»нең беренче томы 1946 елда, икенчесе 1956 елда басылып чыга. Бу басмалар татар фольклор фәнендә зур әһәмияткә ия җыентыклар булып санала.

1939 елда Казанда Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачылганнан соң, татар халык иҗаты планлы рәвештә фәнни нигездә өйрәнелә башлый, Себернең Төмән, Тобол, Тара, Новосибирск якларында яшәүче татарлардан фольклорның төрле жанрларына караган материал туплана, шул исәптән шактый әкиятләр язып алына. Мөхәммәт Садри (үзе дә катнаша) бу экспедиция турында берничә мәкалә язып бастыра, шул материаллар нигезендә әлеге экспедициянең эшчәнлеген шактый тулы күзалларга мөмкин.

Фольклорчы галим Хәмит Ярми җитәкчелегендә оештырылган Себер экспедициясендә Вәли Хаҗиев, Мөхәммәт Садри һәм Сәит Әмиров катнаша. Экспедиция эшен Новосибирск якларында, «Бараба далаларында» башлап җибәрәләр. Мөхәммәт Садри үзләренең максаты турында болай дип яза: «Экспедиция Себер татарларының җыр һәм көйләрен эзләп табу, аларны язып алу белән генә чикләнмәде.

Анда катнашкан Хәмит Ярми, С. Әмиров, В. Хаҗиев һәм мин һәркайсыбыз да үзебезнең бурычларыбызны яхшы белә идек. Х. Ярми белән Хаҗиев иптәшләр халыкның бигрәк тә әкиятләрен язып алу буенча, С. Әмиров Бараба, Тары, Усть-Ишем һәм гомумән Новосибирск, Омск өлкәсендәге татарларның тел үзенчәлекләрен өйрәнү буенча эшләделәр, ә мин халык көйләрен, җырларын өйрәндем. Шуның белән бергә без һәркайсыбыз үзебезгә йөкләтелгән эшкә генә ябышып ятмадык, җае чыкканда бер-беребезгә ярдәмләшә дә идек. Әйтик, Х. Ярми иптәш җырлар язып алса, мин үзем ишетергә туры килгән әкиятләрне яза бардым» [Садри, 1964, б. 127].

1940 елгы экспедиция материалларының бер өлеше Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. 1941 елда Бөек Ватан сугышы башланып китү сәбәпле, әлеге экспедиция материалларын вакытында тулысынча барлау, өйрәнү мөмкин булмый. Мәсәлән, Мөхәммәт Садри сугыш башлануга фронтка китә. Ул экспедиция материалларын, 1946 елда хәрби хезмәттән кайтып берничә ел үткәннән соң гына системага сала ала. Әлеге материалларның сакланып калуы да гаҗәп. Бу турыда «Себер истәлекләре» дигән мәкаләсендә әдип болай дип искә ала: «Сугыш вакытында көнкүреш шартларының кыенлыгы сәбәпле, балалар белән квартирадан квартирага күчеп йөрергә мәҗбүр булуына карамастан, тормыш иптәшем Маһруй халыкның тел иҗатына бәйле ул материалларны бар нәрсәдән кадерлерәк итеп саклаган. Бөек Ватан сугышыннан соң, язучы Гази Кашшаф квартирасында гаиләм белән җиде ел яшәдем. Кысан иде. Капчыкларга тутырылган кульязмалар, китаплар аларның ванна бүлмәсендә һәм чоланында сакланды. Гази Кашшаф һәм аның гаиләсенең сабырлыгы, игътибарлылыгы өчен мин гомерем буе рәхмәт әйтеп яшәячәкмен!

Үземдә булган материалларны күптән түгел генә системага сала башладым. Ә укучыга тәкъдим ителә торган шушы истәлекләрнең барлыгын бөтенләй оныткан идем. Аларның шулай соңлап, бары тик 23 елдан соң гына дөньяга чыгуына мин түгел, сугыш гаепле» [Садри, 1964, б. 127]. Мөхәммәт Садри бу экспедиция материалларын халыкка җиткерү буенча зур эш башкара. Ул аларны берничә мәкалә итеп вакытлы матбугатка әзерли. Мәсәлән, 1964 елда «Совет әдәбияты» журналының тугызынчы санында – «Себер истәлекләре», «Казан утлары» журналының тугызынчы санында «Себер халык җырлары һәм әкиятләре» дигән мәкаләләре дөнья күрә. 1989 елда «Иртешкә сәяхәт» дигән җыентыгы басылып чыга. Әдип бу мәкаләләрдә дә, җыентыкта да Себер татарларыннан, шул исәптән Новосибирск өлкәсендә яшәүче татар халкыннан язып алынган фольклорның иң матур үрнәкләрен, шул исәптән уналты әкият тәкъдим итә.

Әлеге экспедиция барышында Новосибирск өлкәсендә яшәүче татарларның гаять бай фольклор мирасы язып алына. Мәсәлән, шулар арасыннан «Ике дус», «Бака кияве», «Алтын балык», «Әләй Хәйбулла», «Батыш исемле батыр турындагы әкият», «Айкула мәргән», «Ал-

тын башлы, көмеш беләкле», «Алтын кош» әкиятләре берничә тапкыр басылып чыккан, укучыларның яратып укый торган әкиятләреннән.

Бөек Ватан сугышы елларында туктап торган фәнни экспедицияләр 1945 елның көзеннән яңадан оештырыла башлый. 1945–1950 елларда Татарстан районнарына оештырылган экспедицияләр вакытында – 243 әкият, 1951–1955 елларда 233 әкият язып алына.

1967 елдан Себер татарларының халык иҗатын өйрәнү максатында яңадан экспедицияләр оештырыла башлый. Фольклор секторында эшләүче галимнәр тагын бер тапкыр В.В. Радлов эзләреннән уза, ул эшләгән төбәкләрнең фольклорын өйрәнә. Фольклор фонды Себер татарларының күпсанлы әкиятләре белән баетыла. Әлеге фондта тупланган әкиятләр саны бүгенге көндә меңнән артып китә. Аларның күпчелеге өч фидакяр галим –Хәмит Ярмөхәммәтов, Гомәр Бәширов һәм Халидә Гатина тарафыннан язып алынган әкиятләр. Бу елларда җыелган материалны укучыларга җиткерү буенча да зур эш башкарыла. Шул ук вакытта әкиятләрнең жанр үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган җитди фәнни хезмәтләр дөнья күрә.

Хәмит Ярми татар әкиятләрен популярлаштыруда зур хезмәт куя. Галим үзе исән вакытта ук татар әкиятләрен үз эченә алган өч дистәдән артык китап дөнья күрә. Алар арасында Мәскәүдә рус телендә нәшер ителгән җыентыклар да дистәгә якын. Галим әзерләгән әкиятләр җыентыгы («Гөлчәчәк») рус телендә Мәскәүдә (1952) генә түгел, төрле телләрдә Ереванда (1954), Пекинда (1954), Алма-Атада (1957), Киевта (1960), Ашхабадта (1961) басыла. Шул елларда Хәмит Ярми әзерләгән «Находчивый джигит» дигән җыентык – Кишиневта (1969), «Татар халык әкиятләре» – Белградта (1969), «Златната птица» Софияда (1989) басылып чыга.

Татар халык әкиятләрен туплауда иң зур хезмәт куйган шәхесләрнең берсе – фольклорчы Х.Х. Гатина. Ул 1945–1969 еллар аралыгында утыз фольклор экспедициясендә катнашып, йөзләрчә текст туплый, лаеклы ялга чыкканнан соң, шул экспедицияләр вакытында җыелып басылмыйча калган әкиятләрне бер-бер артлы аерым китаплар итеп чыгара: «Татар халык әкиятләре» (1999), «Балаларга – әкиятләр» (2000), «Вакытында табылган якутлар: әкиятләр, истәлекләр һәм хатлар» (2006), «Татар халык иҗаты. Әкиятләр» (2007), «Тутый кош: татар халык әкиятләре» (2008). Бу җыентыкларга күп кенә әкиятләр беренче тапкыр кертелгән. Галимә әкиятләрнең кайда һәм кемнән язып алынуын да күрсәтә.

Институтның халык иҗаты бүлегенең узган гасырдагы фәнни эшчәнлегенең иң зур нәтиҗәсе һәм күрсәткече – фольклорчылар тарафыннан әзерләп чыгарылган 12 томлык «Татар халык иҗаты» тупланмасы. «Әкиятләр» томы, шул томнарның беренчесе булып, 1977 елда дөнья күрә. Бу китапта татар халкының хайваннар турындагы һәм тылсымлы әкиятләре урын алган. 1978 елда тылсымлы әкиятләрдән тупланган икенче том басылып чыга. Бу томнарны Х. Ярми белән Х. Гатина әзерлиләр. 1981 елда Л. Җамалетдинов тарафыннан

әзерләнгән тормыш-көнкүреш әкиятләрен эченә алган өченче том дөнья күрә.

1970 еллардан башлап татар әкиятләрен Л.Ш. Җамалетдинов өйрәнә башлый. Институтта эшләгән дәверендә галимнең татар әкиятләренә багышланган күпсанлы фәнни мәкаләләре басыла. Л. Җамалетдинов тарафыннан төзелгән унҗиде исемдәге татар халык әкиятләре җыентыклары арасында рус һәм инглиз телендә чыккан китаплар да бар.Алар арасында «Әсирлектән кайткан әкиятләр: татар халык әкиятләре» (Казан, 2002) җыентыгы аерым игътибарга лаек. Бу җыентыктагы әкиятләрнең күбесе беренче тапкыр бастырып чыгарыла. Болар – венгр галиме Игнац Кунош тарафыннан Беренче бөтендөнья сугышы чорында (1914–1918) Чехиянең Эгер һәм Венгриянең Эстергом шәһәрләре тирәсендәге хәрби лагерьларда әсирләрдән язып алынган әкиятләр. Шул ук җыентыкта моңарчы киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган башка әкият текстлары да кертелгән.

Татар әкиятләренең сюжет үзенчәлекләре, аерым образлар Ф. Урманчеев хезмәтләрендә дә тикшерелә. Галимнең «Татар халык иҗаты» (2002) дигән хезмәтендә татар халык иҗатында әкиятләрнең жанр үзенчәлекләре барлана.

Татар әкиятләрен фәнни яктан өйрәнүдә һәм популярлаштыруда Казан университеты галимнәренең дә өлеше зур. Аерым алганда, М.Х. Бакиров тарафыннан югары уку йортлары өчен язылган «Татар фольклоры» (2008) дәреслегендә һәм рус телендә чыккан «Татарский фольклор» (2012) монографиясендә әлеге жанрның төрләре һәм аларның милли үзенчәлекләре системалы төстә анализлана.

Текстолог галим З.Г. Мөхәммәтшин тарафыннан төзелгән «Айтуган Максудов – Болгаер әкиятчесе» (2016) дигән җыентык татар фольклор фәнендә яңа төр әкият җыентыкларының беренче үрнәге. Бу китапта аерым бер әкиятчедән язып алынган текстлар, аның турында мәгълүмат тупланган.

Хәзерге вакытта татар халык әкиятләрен фәнни яктан өйрәнү, архивларда саклаган әкиятләрне барлау, моңарчы киң катлау укучыларга таныш булмаган текстларны вакытлы матбугатта, җыентыкларда бастырып чыгару, укучыга җиткерү буенча да эш бара. Институт тарафыннан даими оештырылган комплекслы экспедицияләр вакытында да әкиятләргә дә игътибар зур. Мәсәлән, 2020 елның февраль аенда Төмән өлкәсенең Тубыл һәм Вагай районнарында узган экспедицияләр вакытында «Кәтән Иваныч», «Үги кыз» әкиятләренең вариантлары, әлегә кадәр татар фольклорында билгеле булмаган «Каләм белән Сәлам» дигән тылсымлы әкият язып алынды. Татар халык әкиятләрен халыкның серләрен, дөньяны күзаллавын, яшәү кодларын саклаган иҗат буларак өйрәнү дәвам итә. 25 томлык татар фольклоры җыелмасының халык әкиятләренә багышланган алты китабы да, архив материалларын барлап, яңа чыганакларны өйрәнеп әзерләнде һәм шушы күркәм эшчәнлекнең нәтиҗәсен күрсәтеп тора.

**Әдәбият**

*Balint Gabor*. Kazáni tatár nyelvtanulmányok. I Fuzet. Kazáni-tatár szövegek. Budapest, M. Tud. Akadémia, 1875. 170 l.

*Kúnos l.* Kazantatarische Volksmärchen. Auf Grund der Sarnmlung von lgnác Kúnos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk und lmre Baski (Oriental Studies 8). Budapest, 1989.

*Paasonen H.* Mischärtatarische Volksdichtung, gesammelt von H. Paasonen / Übersetzt und herausgegeben von Eino Karahka. Helsinki, 1953.

*Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казань: Ихлас, 2012.

*Витевский В.Н.* Сказки, загадки и песни нагайбеков Верхнеуральского уезда Оренбургской губернии // Труды четвертого Археологического съезда. Том II. Казань, 1891. С. 257–280.

*Горький М*. Әдәбият турында. Казан, 1953.

*Катанов Н.Ф.* Материалы к изучению Казанско-татарского наречия. Часть первая. Образцы книжной и устной литературы казанских татар. Казань, Типолитография императорского университета, 1898.

*Кукляшев С.Б.* Словарь татарской хрестоматии. Казань, 1859.

*Мөхәммәтшин З.Г.* Айтуган Максудов – Болгаер әкиятчесе. Казан, 2016.

*Насыров А.К., Поляков П.А.* Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов. Казань: Тип. ун-та, 1900.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи, собраны В.В. Радловым. Ч. IV. СПб., 1872.

*Садри Мөхәммәт.* Себер истәлекләре // Совет әдәбияты. 1964. № 9. Б. 127.

Сборник татарских рассказов / сост. С. Кукляшев. 1859.

Татарская хрестоматия, составленная Мартинианом Ивановым. Казань: Типография Казанского университета, 1842.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда. Казан: Мәгариф, 2008, 2009, 2011.

*Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты: Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2002.

*Фәезханов Г.* Хикәят вә мәкаләт. Казан, 1890.

Халык әкиятләре / төзүчесе Г. Разин. Казан, 1940. 167 б.

*Яхин Т.* Дәфгылькәсәл мин әссабый вә сабыят. Казан, 1900.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 347.782.5

***Р.Р. Солтанова***

# КАЗАН СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕНДӘ ТЕАТР ДЕКОРАЦИЯСЕ БҮЛЕГЕ: ТАРИХЫ ҺӘМ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ

Статья посвящена системе подготовки мастеров театрально-декорационного искусства в Казанском художественном училище им. Н. Фешина, известного в стране своими талантливыми выпускниками. Впервые раскрывается история театрально-декорационного отделения, анализируется методика преподавания художников-педагогов (П. Сперанский, А. Иванцев, Н. Кумысникова и др.). Исследование базируется на широком использовании архивных материалов, частных коллекций.

**Ключевые слова:** Казанская художественная школа, традиции, сценография, художественное образование, театральная живопись.

The article is devoted to the training system for masters of theatrical and decorative art at the Kazan Art College named after N. Feshin, known in the country for his talented graduates. For the first time, the history of the theater and decoration department is revealed, the methodology of teaching artists and teachers (P. Speransky, A. Ivantsev, N. Kumysnikova, etc.) is analyzed. The study is based on the widespread use of archival materials, private collections.

**Keywords:** Kazan art school, traditions, scenography, art education, theater painting.

Николай Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесының тарихы 1895 елда Казан сәнгать мәктәбеннән (КСУ) башланып китә һәм быел исә әлеге уку йорты үзенең юбилеен билгеләп үтә. Республикада барган мәдәни-тарихи вакыйгалар атаклы уку йорты тормышында да чагылмый калмый. Әмма төрле үзгәртеп коруларга дучар булуга карамастан (1918 елда – Казан ирекле сәнгать остаханәләре, 1920 елда – Казан югары сәнгать-техника остаханәләре, 1921 елда – Казан сәнгать институты, 1922 елда – Казан архитектура институты, 1926 елда – Казан сәнгать-педагогия техникумы, 1927 елда – Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы, 1932 елда – Казан сәнгать техникумы, 1935 елда аннан Казан сәнгать училищесы бүленеп чыга). Бу мәктәп баштан ук үзендәге югары сәнгать культурасы белән аерылып тора. Ә рәссамнар эшчәнлеге шуның белән билгеләнә дә: аның нигезендә ныклы рәсем һәм нәфис осталык – төсләрне тоемлау, буяулар нисбәте гармониясе ята. КСУны тәмамлап, республика театрларында эшләгән осталарның нәкъ менә тулы бер плеядасы театрга бу югары нәфис культура, төсләр фантазиясен һәм катгый зәвык алып килә[1].

Бу нисбәттән Н.И. Фешин, П.П. Беньков, П.Т. Сперанский, Б.И. Урманче кебек педагог-рәссамнарның эшчәнлеге зур бәягә ия.

Алар Татарстан Республикасы сәнгати мәдәниятенең тулаем алдагы үсешен билгеләделәр. Театр декорациясе сәнгатен үстерүдә алар иҗатының әһәмияте биниһая зур. Ә моның алшартлары КСУда ук барлыкка килә.

Театр рәссамнары буларак алар үзләренең станок сәнгате иҗат юнәлешләреннән чыгып эш итәләр. Зур һөнәри осталыкка ия булу, перспективалы рәсем сәнгатен бик яхшы белү әлеге рәссамнар кулында көчле коралга әверелә. Нәкъ менә алар, беренчеләрдән булып, Казан декораторлар мәктәбен нигезлиләр. Үз сәнгати казанышларын театр рәссамнарының алдагы буыннарына тапшырырга тырышып, алар КСУда театр декорациясе сәнгатен системалы укытуны җайга салалар, аның төп принципларын булдыралар.

П.П. Беньков һәм П.Т. Сперанский икесе дә, беренче профессиональ рәссамнар буларак, үз иҗатларын бер үк вакытта диярлек татар театрында башлап җибәрә. Н.И. Фешинны декорация сәнгате буенча аларның беренче укытучысы дип санарга тулы нигез бар.

Сперанский архивында студентлар Н.И. Фешин җитәкчелегендә «Мисыр балы» декорацияләрен әзерләгәндә төшерелгән фоторәсем сакланган. Артистка З. Славянованың җирле декораторлар өчен уку әсбабы буларак нәшер ителгән «Эшче-крестьян театры» (1921) дигән китабында Н.И. Фешинның «әзер үрнәкләр – декорация һәм сәхнәнең арткы планнары эскизларын бирүне максат иткән»[2] җиде төсле рәсеме урнаштырылган. Соңрак Б.И. Урманче татар театрында К.Тинчурин пьесалары буенча спектакльләрнең бизәлешен эшләгәндә, авыл йортының типик интерьерын («Ил», 1928), бай мирзаның шәһәр утарын («Беренче чәчәкләр», 1959) сурәтләгәндә Н.И. Фешин декорацияләренең үзенә бертөрле «татар варианты»н күз алдында тотып эш итә.

Б. Урманче 1927 елда, техникумда уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары буларак, студентларны Мәскәүгә В. Мейерхольд спектакльләрен карарга алып бара.

Ул вакытта ук инде Мәскәүдән белгечләр чакыру тәҗрибәсе кулланышта була. Г. Камал исемендәге театрда Казан берләштерелгән сәнгать техникумының МХАТ артисты Н.А. Шульга җитәкчелегендә куелган «Иске Казан диварлары артында» (авторы чыгарылыш курсы студенты М. Зәетов; бизәүче рәссамы П. Беньков) дип аталган диплом спектакленең фоторәсемнәре сакланган.

1920 елларда театр рәссамнарын әзерләүгә нинди җитди игътибар бирелүен аңлау өчен, рәсем сәнгате факультетында «Театраль-декоратив рәсем сәнгате» белгечлеге буенча уку программасына күз салу да җитә (ул вакытта Казан югары сәнгать-техника остаханәсендә).

Беренче елларда уку планнарына түбәндәге курслар кертелә: театр һәм театр белеме тарихы, театраль рәсем сәнгате һәм постановкалар тарихы, костюм һәм грим тарихы (актерлар киеме), сәхнә архитектурасы (сәхнә сәнгате), театраль рәсем сәнгате һәм постановкалар техникасы (эскиз, декорация макеты – 2 ел); яктырту, бутафория,

грим; костюм тегү һәм тукыма буялышы; сәхнә һәм панорама перспективасы – 1,5 ел; композиция; эшче-крестьян театры идеологиясе һәм техникасы һәм куелыш; сәхнә техникасы буенча рәсемнәр (В.С. Баратов); ачык һавада театр; заманча театр [ТР МА...]. Технологияләрне өйрәнүгә дә зур игътибар бирелә. Остаханәләр политехник (материалларны эшкәртү үзенчәлекләрен һәм ысулларын өйрәнү), сәнгати (аның табигатенә туры килә торган материалны бизәүне өйрәнү) һәм җитештерү (эшләр һәм заказлар башкару) лабораторияләренә бүленгәннәр. Программада язылганча, белгечлек буенча җитештерү остаханәләре югары квалификацияле, практикада кулланыла алырлык иҗади эшләр тудыруны максат итеп куя [ТР МА...]. Чыннан да, ул елларда педагоглар һәм студентлар дәүләт заказларын үтәүдә актив катнашалар, бу өлкәдә П.Т. Сперанский[3] аеруча уңышлы эшли. 1943–1954 елларда КСУның театр декорациясе бүлегенә нәкъ менә ул җитәкчелек иткәндә, биредә йөзләрчә белгечләр әзерләнә. Алар арасында Татарстанда абруйлы театр рәссамнары булып танылган А.Х. Нагаев, М.Г. Сутюшев, Л.Л. Сперанская-Штейн, А.А. Чудаков, П.А. Баландин һәм башкалар бар.

П.Т. Сперанский үз эшендә барлык юнәлешләрдә дә рәссамнар өчен натурадан эшләү зарур, дигән тезистан чыгып эш итә. Ул үзенең тәрҗемәи хәлендә болай дип яза: «Бу эштә мин ял һәм файда табам һәм үз укучыларыма мөмкин кадәр натурадан эшләргә киңәш итәм».

А.Я. Головин, К.А. Коровин, Ф.Ф. Федоровскийның «зур декорация стиле» традицияләрен, күтәренке романтик театр рәсем сәнгатендә югары культурага ирешкән «Сәнгать дөньясы» осталары традицияләрен дәвам итеп, куелыш культурасын күтәрүгә күп көч куя, сәхнәнең арткы планын бизәүгә, күләмле декорацияләрне матур итеп эшкәртүгә, тюльләр, аппликация куллануга һәм костюмнарга аерым игътибар бирә.

П.Т. Сперанский архивында без аның кулы белән язылган IV курс өчен прозводство практикасы планын таптык, ул 5 пункттан тора: 1) сәхнәнең арткы планын һәм заспинниклар язу (85 сәгать); 2) костюмнар һәм аппликацияләр өчен тукымага бизәк төшерү (40 сәгать); 3) бутафория бизәлеше һәм декорация детальләрен фактуралаштыру (40 сәгать); 4) монтажлау репетицияләрендә катнашу (20 сәгать); 5) яктылык кую репетицияләрендә катнашу (20 сәгать). Дәресләр күбрәк аның театрдагы кабинетында уза торган була. Уку дәвамында милли ансамбль чыгышын бизәүгә, бәйрәм уңаеннан хөкүмәт бинасының тышкы бизәлешенә эскизлар ясарга, берәр спектакльгә театр сәхнәсе макетын әзерләргә кирәк була. Ә диплом эше өчен сайлап алынган спектакль өчен һәрбер күренешләрнең һәм костюмнарның эскизларын эшләү таләп ителә. Ул үзенең курсында укучыларны студент вакыттан ук әледән-әле шәһәр масштабындагы декоратив эшләргә җәлеп иткән, һәм әйдәп баручы рәссам-декоратор, архитектор буларак, үзе үк алар белән җитәкчелек иткән. А.О. Визель[4] истәлекләре буенча, «И.Л. Язынин белән мин мондый биремнәрне

үтәүдә катнаштым. Беренчесе опера театры бинасын бизәү белән бәйле; төзелеш тәмамлангач, ни өчендер көтмәгәндә театрның баш портигы колоннадасы өстендәге фронтонны ни рәвешле бизәсәң яхшырак булыр дигән сорау туды. Портикның эре габаритлы макетында тәкъдим ителгән берничә вариантны сынап карарга карар кылынды. Әлеге макетны ясау безгә йөкләнде» [Визель, с. 44]. Икенче эпизод И. Сталинның юбилеена «Татарстан бүләге»н әзерләү белән бәйле: «Бүләккә гобелен кебек чигелгән һәм мозаик бордюр белән каймалап алынган картина рәвешендә зур келәм әзерләргә булдылар. Чигүчеләр келәмгә төшерсен өчен, безгә аның эскизын эшләп бирергә кирәк иде» [Визель, с. 44].

Сперанскийны үзенең «икенче әтисе» дип санаган Әнвәр Нагаев 1946 елда укырга килгәч, шунда ук опера театрында да эшли башлый. Инде рәссам-башкаручы сыйфатында ул оста белән бергә «Бакчасарай фонтаны», «Мәрьям», «Евгений Онегин», «Җиңү юлы», «Җәлил» опералары бизи. Театрда практика узу алдагы елларда да киләчәккә һөнәр сайлауда мөһим фактор булып тора.

Югарыда әйтелгәнчә, рәсем һәм нәкыш буенча көчле мәктәп үзу укучыларның күп кенә эшләренең дәрәҗәсендә дә чагыла. Бу безнең тарафтан шәхси коллекцияләрдә һәм училищеның методик фондында табылган курс һәм диплом эшләре белән дә раслана.

1970 елларда КСУдагы театр декорациясе бүлеге Ә.И. Тумашев (1950–1980 елларда Г. Камал исемендәге Татар театрының әйдәп баручы рәссамы), К.А. Нәфыйков, А.С. Иванцев кебек рәссамнарның исемнәре белән бәйле. Шушы елларда училищеда укыган Н.Х. Кумысникова раславынча, укытуда театраль рәсем сәнгатенә өстенлек бирелә.

Р.Х. Газиевның[5] «Тирән разведка» (1972) дип аталган курс эшендә аның ян декорацияләрне файдалануында, колачлы буявында, локаль төсләрне куллануында үз укытучысы Ә.И. Тумашевка ияреп эшләргә омтылуы сизелә. 4 курста диплом эше – «Орлеан кызы» операсына декорация эскизлары мөстәкыйль рәвештә язылa.

А.Г. Хәмидуллинның (1976–1980 елларда К.А. Нәфыйковта, А.С. Иванцевта укый) «Кармен» спектакленә эскизлары бай төсләр гаммасыннан файдаланып ясалган. Хәтта соры төсне биргәндә дә, ул фонны әлеге төснең күп санлы төсмерләре белән баета. Экспрессив матур буяулар, ачык тональ төсләр контрастлары тулаем бөтен композицияне хәрәкәткә китерә. Аның хәзерге заман рәсем сәнгатенә дә театральлек хас.

Т.Н. Кривошееваның (педагоглары – А.С. Иванцев, П.П. Плотников, А.А. Закиров) диплом эше – Н. Гогольнең «Ревизор» спектакленә декорацияләр һәм костюмнар эскизлары (1982). Алар җылы төсләр кулланып эшләнгән. Аңарда үзара якын төсләр чиратлаша. Киләчәктә бу үзенчәлек аның керамикасына да күчә.

Әлбәттә, студентларның эшләре җитешсезлекләрдән дә мәхрүм түгел. Төрле элементларны бербөтенгә укмаштыра алмау күзәтелә,

кайвакыт төсләр массасының масштаблы нисбәте табылмый. Дизайнер эшләнмәләренә тартым эшләрдә ниндидер схематизм, очраклы төсләрне чиратлаштыру өстенлек итә. Күп кенә эшләр гомуммәгълүм хакыйкатьне күрсәтә: классик рәсем сәнгатендә укучы студентлар локаль төсләргә бай шартлы киңлекне авырлык белән төзиләр. Ачык детальләр күп булган композицияләрдә персонажлар югала, төп нәрсәдән читләшү күзәтелә – шул рәвешле, акцентлар үзгәрәә. Кайбер эшләр гадәти булмаган фактура, төрле техника куллану (коллаж, аппликация) хисабына тышкы эффект тудыруга гына исәпләнгән. Эскиз өчен сайланган техник алымнарның гармониягә ирешеп, образ тудыруга эшләвенә дә мисаллар бар. В. Качалов исемендәге театрның куючы рәссамы П.П. Плотниковның пространствоны оештыруның яңа киңлек һәм ритм-пластика закончалыкларын эзләү белән бәйле экспериментлары студентларның хәтеренә сеңеп калган. Үзенең дәресләрендә ул елның төрле фасылларында табигатьнең төрле халәтен – тынычлыгын, тынычлануын, низагын – чагылдырган абстракт фигуралардан макетлар ясау буенча күнегүләр бирә...

1980 елларда эшләнгән диплом эшләре булачак рәссамнарның һөнәри мөмкинлекләре күпкә киң булуны, аларның текстны театраль интерпретацияләүнең төрле төрләрен үзләштерүләрен күрсәтә. Мәсәлән, Яшь тамашачы театрының баш рәссамы Л.Р. Гыйльметдинов[6] «Борис Годунов» операсының бизәлеше өстендә эшнең барлык этапларына караган эскизларын саклаган: төсләр буенча эшләнмәләр (кроклар), костюмнар, декорацияләр, эскизлары, образларның гримнары. Диплом эшен уңышлы яклап, ул Ленинград театр институтына укырга керү мөмкинлегенә ия була.

Булачак театр рәссамнарын әзерләүдә театр цехларында һәм остаханәләрдә һәрдаим турыдан-туры эш алып баруга зур әһәмият бирелгән һәм хәзер дә бирелә. Студентлар практиканы Казанның барлык театрларында узалар. Осталык серләренә, әлеге һөнәрнең барлык кыенлыкларына төшенүдә театр рәссамы җитәкчелегендә репертуарга кертелгән спектакльләр бизәлеше өстендә эшләү алар өчен иң зур мәктәп булып тора. Әйтик, 1970 еллар уртасында студентлар А.Б. Кноблок җитәкчелегендә М. Җәлил исемендәге опера театрында һәм Яшь тамашачылар театрында спектакльләрнең бизәлешен эшләгәндә, төрле башкару ысулларын (катлаулы аппликацияләр, коллаж) кулланып, төрле материаллардан файдаланырга өйрәнгәннәр. 1976–1995 елларда Казанның әйдәп баручы театрларында сценограф булып эшләгән Ә.Ә. Җәмилова үзенең истәлекләрендә дә шул хакта сөйли.

Яшь тамашачы театрында сәхнәгә куючы-рәссам булып эшләгән Н.В. Пачкова (хәзерге вакытта ул – декорация цехы башлыгы һәм К. Тинчурин исемендәге театр белән уңышлы хезмәттәшлек итә) студентларның Г. Камал исемендәгетеатрында практика үткәндә Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен әзерләүләре турында сөйли: алар декорацияне, бутафорияне бизәргә булышалар, аппликацияләр ясыйлар. Г. Камалның «Банкроты» өчен

йорт җиһазларын бизәклиләр, хәтта акча ясыйлар. Яшь тамашачы театрында сценограф Ә.Ә. Җәмилова[7] спектакльләре өчен сәхнәнең арткы планын рәсем белән бизиләр, марля ярдәмендә чирәпне имитацияләргә, коллажлар ясарга өйрәнәләр. Баш рәссам Р.Т. Сафиуллин, куючы рәссам Ә.Ә. Җәмилова аларны чын театр дөньясына алып керәләр. Биредә костюмнарны бизиләр, салкын батик техникасында эшлиләр, хәтта реклама белән дә шөгыльләнәләр. Н.В. Пачкова укытучыларны зур рәхмәт хисләре белән искә ала: сызым һәм перспектива укытучысы Л.Т. Санкееваны, скульптура һәм шрифтлар буенча – М.А. Салминны. Д. Шәймәрданова ракурска, төскә (йә тоннар үзара якын, йә контраст) басым ясап, кызыклы натюрмортлар, фонны, яктылык чолганышын исәпкә алып, интерьердагы портретларны язарга өйрәтә. Сәхнә киңлегенең гомуми структурасын ачыклаганда, форманы гадиләштерүгә, зур шартлылыкка омтылган коллаж техникасын куллану бигрәк тә уңышлы. Нәкъ менә шуңа күрә укытканда коллажны еш кына пластика законнарын үзләштерү күнекмәсе сыйфатында кулланганнар.

Н.Х. Кумысникованың[8] укытучылары – әйдәп баручы театр рәссамнары Ә.И. Тумашев һәм К.А. Нәфыйков – студент елларында ук аңа Казан мәдәният һәм сәнгать институтының (КУКИ) режиссерлык курсы спектакльләрен бизәү буенча үз көчен сынап карарга мөмкинлек бирәләр. Бу курсны танылган театр белгече Х.Л. Кумысников алып барган. Г. Лорканың «Бернард Альба йорты» спектакле өчен декорацияләрне, костюмнарны ул мөстәкыйль иҗат итә. Укытучыларының мондый эш методикасын соңыннан ул үзенең педагогик эшчәнлегендә (1986–1990 елларда) куллана. Үз студентларыннан ул эскизлар ясауны гына түгел, куючы режиссер белән бергәләп эшләүне дә таләп итә. Аның методикасы күбрәк студентлар индивидуаль рәвештә хәл итәргә тиешле концептуаль проблемалар белән бәйле була. Әйтик, инде 1 курста ук алар пластикага гына корылган спектакльләрне бизиләр. Икенче уку елында бөтен курс белән «Экипаж» театрында «Пир во время чумы» рок-операсының бизәлешен эшлиләр. Ул Идел буендагы яшь театрлар смотрында катнаша һәм диплом ала. 4 курста барлык студентлар да институтны тәмамлаучы режиссерлар белән индивидуаль эшлиләр. Н.Х. Кумысникова, мәктәпнең матур традицияләрен саклап, студентларны, уйлап чыгарып һәм фантазия күрсәтеп, төрле график техникаларны (күмер, карандаш, акварель, линогравюра) кулланып эшләргә өйрәтергә тырышкан. Төрле планда, күп кенә режиссерлар белән эшли белү чыгарылыш курсы укучыларына универсаль сәләткә ия һәм кирәкле белгечләр булырга мөмкинлек бирә. Бүген алар сәнгатьнең күп кенә өлкәләрендә гамәл куя. Алар арасында курчак ясаучы осталар, китап рәссамнары, костюм һәм интерьер дизайнерлары, рәссамнар һәм графиклар бар[9]. 1990 еллар уртасында театр декорациясе бүлеге ябыла.

Озак еллар яшәү дәверендә бу бүлек үз традицияләрен югалтмый. 2016 елда «Театраль-декорацион рәсем сәнгате» белгечлеге

буенча студентлар кабул ителә. Курсның җитәкчесе – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт театрының баш рәссамы, ТРның халык рәссамы С.Г. Скоморохов була. Ул зур эш тәҗрибәсенә ия белгеч, традицияләрне дә, театр үсешенең заманча тенденцияләрен дә яхшы белә.

Яшь рәссамнар әзерләү процессында ул театр сәнгатендә һәрвакыт яңарышлар булып торуны, яңа сценография теле барлыкка килүне исәпкә алып эш итә. Театр-декорация сәнгатен тасвирый режиссура буларак кабул итү көчәя. Спектакльне бизәүнең яңа системасында (действенная сценография) фактура, яктылыкның әһәмияте арта. Болар барысы да һөнәри белемнең урта звеносында театр рәссамнары әзерләү процессына үзгәрешләр кертә. Театр рәссамы бүген, спектакльнең тулы кыйммәтле автордашы буларак, режиссураның һәм актерлык осталыгының төп кануннарын аңларга, классик һәм хәзерге заман драматургиясен яхшы белергә тиеш. Уку планының нигезен классик дисциплиналар белән беррәттән (театр, дөнья мәдәнияте тарихы, сәнгать тарихы, сызым һәм перспектива, пластик анатомия, рәсем, композиция, рәсем сәнгате, театр макеты һ.б.) информацион технологияләр дә тәшкил итә. Хәзерге заман белем бирү процессында спектакльнең пространство масштабын төрле яктан күрсәткән модель буларак чыгыш ясаучы театр макетына аерым урын бирелә. Элек-электән республика театрларында гамәли дәресләргә зур игътибар бирелә. IV курс студентлары Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры сәхнәләрендә беренче тапкыр мөстәкыйль рәвештә сценографлар сыйфатында үз көчләрен сынадылар (Ю. Плотникова, Л. Хөсәенова).

Хәзерге заман театрлары тәҗрибәсе тасвирый культура нигезләрен тирәнтен төшенми торып, чын театр булмавын күрсәтә. Аңа игътибар кимү салон тибындагы тышкы матурлыкка гына корылган спектакльләр тууга китерә. Берничә буын осталар тәрбияләгән мәшһүр педагог, театр һәм кино рәссамнарының берсе М.М. Курилко-Рюмин әйтүенчә, «унылые сценографические схемы, лишенные обаяния пластики, убогие по примитивности мысли, так и остаются схемами» [Курилко, с. 30]. Төсләр, яктылык ярдәмендә фикер йөртүче рәссамның кулы театрга кагылу белән, хәтта буш киңлек тә тамашачыда көчле тәэсир калдыра.

## Искәрмәләр

1. Болар Н. Фешин, П. Беньков, Б. Урманче, П. Сперанский, М. Абдуллин, М. Сутюшев, Ә. Тумашев, П. Баландин, А. Нагаев, А. Закиров, Р. Газиев, А. Җәмилова, Р. Моров, Л. Гыйльметдинов кебек һ.б. исемнәр.

2. Бу – бай йорттагы кунак бүлмәсенең арткы планы, бай сарай һәм замок бүлмәсе (сәхнәнең арткы планы), авыл урамы күренеше, сукно куелышлары (сәхнәнең арткы планы). Шәһәр урамы; крестьян көнкүрешен тасвирлаган пьесалар өчен сәхнәнең арткы планы; эшче-крестьян театрының порталы һәм пәрдәсе; А. Островский пьесаларына сәхнәнең арткы планы.

3. Милли архивта Казан ирекле Дәүләт укыту-сәнгать һәм җитештерү остаханәләре башкарма комитеты җирле комитетының 1920 елның 24 ноябрендәге гомуми җыелышы беркетмәсе сакланып калган. Ул да шуны раслый. Анда болай диелгән: «...Театральные, декоративные и производственные живописные заказы поступают лишь избранным художникам, каковыми в настоящее время являются Щербаков, Сенников (Сперанский), Медведев… Отказ же Сенникова принимать работать в свою мастерскую всех изъявляющих желание, ведение им дела с определенной группой лиц – интересно в предпринимательском и техническом отношениях… В настоящее время прием и распределение работы поручено известным патентованным лицам, как Щербаков и Сенников». ТР ДА. 1431 ф., 1 тасв., 3 сакл. бер.

4. Визель Андрей Оскарович (1930) – химик-органик, ТССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе (1990), ТР Дәүләт премиясе лауреаты (1994). Казан сәнгать училищесын 1951 елда тәмамлый.

5. Р.Х. Газиев – 1983 елдан Г. Камал исем. ТДАТның куючы рәссамы; А.С. Иванцевта (рәсем сәнгате, композиция), Т.А. Зуевада (рәсем), Ә.И. Тумашевта (композиция) укыган.

6. Л.Р. Гыйльметдинов 1980–1984 елларда А. Иванцевта, Р. Төхвәтуллинда укыган.

7. 1977–1984 елларда Ә. Җәмилова КСУда «театр композициясе һәм практикасы» предметын алып барган, аңарда Н. Пачкова, Р. Моров укыган.

8. Н.Х. Кумысникова – театр рәссамы, костюмнар буенча рәссам, күн мозаикасы остасы. 1973–1977 елларда КСУда Ә.И. Тумашевта һәм К.А. Нәфыйковта укыган. 1977–1983 елларда Суриков институтын (М.М. Курилко-Рюмин остаханәсен) тәмамлый. 1986–1990 елларда КСУның театр декорациясе бүлеген җитәкли.

9. Н. Кумысникованың кайбер укучыларын гына атау да җитә: Е. Ермолина – танылган рәссам, киез сәнгате остасы, костюм буенча дизайнер. В. Суриков исемендәге институтын тәмамлаган (М.М. Курилко-Рюмин остаханәсе); Е. Граханцева – курчаклар ясау остасы; Л. Җәләлетдинова, М. Покалев, О. Покалева, Д. Нәүрүзова (Абдрахманова) – Татарстанда һәм Россиядә әйдәп баручы китап бизәүче рәссамнар; С. Рябинин МХАТ мәктәп-студиясен тәмамлый, Калуга театрында рәссам, Казанда телевидениесендә дизайнер булып эшли, бүген – «Әкият» курчак театрында куючы рәссам.

**Әдәбият**

*Визель А.* Скромный и отважный. Иван Язынин глазами однокурсника // Казань. 2008. № 11. С. 44.

*Курилко М.М.* Художник театра. М.: Юный художник, 2007.

ТР МА. 1431 ф., 1 тасв., 23 сакл. бер. Казанские государственные высшие художественно-технические мастерские.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы,***
*сәнгать фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире*

УДК 78.075

***И.М. Газиев***

# ИБРАҺИМ АДАМАНТОВ КЕМ УЛ?

В статье, основываясь на нововыявленных источниках, воспоминаниях современников, рассматривается разносторонняя деятельность одного из ярких представителей татарской интеллигенции начала XX века – журналиста, театрального деятеля, переводчика и певца Ибрагима Кули. Анализируются его журналистская деятельность, творческие связи с татарским театром, для которого он перевел пьесы русской и зарубежной классики. Впервые рассматривается концертный репертуар И. Кули, известного под сценическим псевдонимом И. Адамантов (баритон). Исполнитель татарских народных песен и песен на стихи современников И. Адамантов выступал на литературно-музыкальных вечерах, а также записывался на граммофонные пластинки. Произведена расшифровка записей на обнаруженной автором граммофонной пластинке фирмы «Зонофон». Данная статья – это дань памяти незаурядному человеку, оказавшемуся жертвой политических репрессий 30-х годов прошлого века.

**Ключевые слова:** татарский театр, татарская музыка в грамзаписи, граммофонная пластинка, «Зонофон», «Лирофон», татарская песня, репертуар, исполнитель народных песен.

The article, based on newly revealed sources, memoirs of contemporaries, examines the activities of one of the prominent representatives of the Tatar intelligentsia of the beginning of the 20th century – the journalist, theatrical figure, translator and singer Ibrahim Kuli. The article analyzes his journalistic activities, creative relations with the Tatar theater, for which he translated plays of Russian and foreign classics. For the first time, I. Kuli's concert repertoire, known under the stage name I. Adamantov (baritone), is considered. Artist of Tatar folk songs and songs to poetry of contemporaries I. Adamantov performed at literary and musical evenings, as well as recorded on phonograph records. The author found a gramophone record of the Zonophone company, and also transcribed the records on this platter. This article is a tribute to an outstanding person, a victim of political repression of the 30s of the last century.

**Keywords:** Tatar theater, tatar music in the record, phonograph record, «Zonophone», «Lyrophon», Tatar song, repertoire, performer of folk songs.

*Татар музыкасы тарихын, башкару сәнгатен өйрәнү юлында, шулай ук татарларның граммофон язмаларын өйрәнү барышында миңа бик күп кызыклы кешеләр белән очрашырга, аралашырга туры килде. Алар – танылган татар композиторлары, музыкантлар, җырчылар, музыка белгечләре. Шулай ук күренекле, билгеле кешеләрнең якыннары, туганнары, дуслары.*

*«И. Газиев тәкъдим итә...» циклыннан «Татар җыры – йөз ел элек» дип аталган телевизион музыкаль фильмда без тамашачыга революциягә кадәр татар җырлары язылган граммофон тәлинкәләре арасында И. Адамантовныкы да булуын хәбәр иттек. Ләкин бу җырчы турында мәгълүмат бик аз иде. Граммофон язмалары өлкәсендә озак еллар дәвам*

*иткән эзләнүләр вакытында И. Адамантовның якын туганы – Мәрьям Ибраһим кызы Әхмәтгалиева белән очрашырга насыйп булды. Мәрьям Әхмәтгалиева 30 елдан артык Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгән, шулай ук Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы да булып торган. Ул безгә Ибраһим Кулиның (И. Адамантов) фаҗигале язмышын бәян итте. Алар бертуган энесе – күренекле галим, техник фәннәр докторы, профессор Ильяс Ибраһим улы Әхмәтгалиев белән дистәләгән еллар буена Ибраһим Кули-Адамантовның граммофон тәлинкәләрен эзләгәннәр, ләкин, кызганычка каршы, бер генә язмасын да таба алмаганнар... Бу хәлне узган гасырның 30 нчы елларындагы Сталин репрессиясенә эләккән аталы-уллы Кулиевларның, корбан булган башка бик күп татар зыялылары белән беррәттән, «халык дошманы» дип игълан ителүнең, исемнәрен тыю астында калдырып, хезмәтләрен, күп очракта барлык документларын, китапларын, граммофон тәлинкәләрен юкка чыгаруның нәтиҗәсе дип карарга кирәктер.*

*Очрашу барышында Мәрьям апа эш өчен кайбер материалларны биреп, 1993 елда вафат булган Ильяс Әхмәтгалиевнең байтак кына хатлары тупланган «Гомерлек сагыш» [Әхмәтгалиева, 2007] исемле китабын автограф куеп бүләк итте. Бу китап бик кадерле бер чыганакка әверелде. Чөнки анда кергән хатларның бер өлешендә И. Әхмәтгалиевнең абыйсына кагылышлы фактлар китерелә һәм хатлар авторының бу юнәлештә нинди дә булса мәгълүмат табарга тырышуы күренә.*

Ибраһим Адамантов – ул XX гасыр башындагы танылган татар зыялыларның берсе, журналист, театр эшмәкәре һәм тәрҗемәче Ибраһим Кулиның (1885–1936) сәхнә псевдонимы. «Адамант» – алмаз ташының борынгы исеме. Шул исем астында И. Кули Казанда оештырылган төрле әдәби-музыкаль кичәләрдә чыгыш ясаган һәм тавышын граммофон тәлинкәләренә яздырган.

Ибраһим Кули (Ибраһим Габделвахит улы Кулиев) 1885 елның 9 сентябрендә Сембер губернасы Буа шәһәрендә (хәзерге Татарстан Республикасы) приказчик гаиләсендә туа. Казандагы «Мәрҗания» мәдрәсәсендә укыганнан соң, 1904 елда ул «Бертуган Кәримовлар» сәүдә йорты нәшриятында корректор вазифасын башкара. Ә инде Казанның Укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң, И. Кули төрле елларда «Казан мөхбире», «Йолдыз» һәм «Кояш» газеталарында эшли, үзенең беренче мәкаләләрен «И. Кули», «И. К.» имзалары астында бастыра.

И. Кули тәрҗемәче буларак, русчадан татар теленә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә башлый. И. Әхмәтгалиев үзенең бер хатында кызыклы мәгълүмат китерә: «Ялкын Дәү абый тәрҗемәсендә 1909 елны чыккан бер китап күргән. “Мөтәрҗим Ибраһим Кулиев”, – дип язылган ул китапта 3000 (өч меңенче!) елда дөньяда нинди хәлләр булачагы турында сөйләнелә, ди» [Әхмәтгалиева, б. 21] (Әхмәтгалиева Ялкын Сафа кызы, И. Әхмәтгалиевнең беренче хатыны, галимә. – *И.Г.*). Озак еллар буена якын дусты булган драматург

Галиәсгар Камал (1878–1933) белән бергә И. Кули 1910 елда, сату-алу эше белән шөгыльләнүчеләргә ярдәм йөзеннән, «Бухгалтерия» исемле русча китапны да татарчага тәрҗемә итеп, бастырып чыгара [Ибраһимова, б. 140].

Октябрь революциясеннән соң И. Кули «Кызыл байрак» газетасында эшли башлый. Соңрак Г. Камал белән бергә «Эш» газетасында эшли. Татар совет әдәбиятының башында торган өлкән буын язучыларның берсе Афзал Шамов (1901–1990) үзенең бер мәкаләсендә И. Кулиның исемен телгә ала. Яшь язучы 1920 елның салкын кышында «Эш» газетасына үзенең беренче хикәяләрен китергәндә, редакциясенең Островский (ул чакта Вознесенский) урамындагы ягылмаган бинадан Г. Камалның Нәриман урамындагы җылы фатирына күчкәнен белә дә, шунда бара. Егеткә Г. Камал ишекне үзе ача. «Оекбашым ертык иде, – дип яза А. Шамов, – салкын тимәсен өченме, песи кебек әдәпле генә басып дистәгә якын басманы үттем, икенче катка мендем һәм майдай җылы өйгә барып кердем. Вәли Шәфигуллин, Ибраһим Кули һәм тагын кемдер шунда эшләп утыра. Почмак якта Г. Камалның гаиләсе, балалары тора» [Шамов, б. 4] (Вәли Шәфигуллин (1894–1939) – журналист-мөхәррир, «Эш», «Эшче» газеталары мөхәррире (1918–1921). Репрессия корбаны В. Шәфигуллин 1939 елда Норильск лагеренда вафат була. – *И.Г.*).

Күренекле әдип Г. Ибраһимов үзенең «Дүртенче елга кергәндә» исемле мәкаләсендә, революцияне кабул иткән журналистлар, мөхәррирләр арасында И. Кулины да искә ала: «...Элек матбугат галәмендә эшләгән, исеме танылган мөхәррирләрдән тик берничәсе (Гыйлемдар Баембит, Фатих Сәйфи, Шәһит Әхмәдиев, Ибраһим Кули, менә шул юлларны язучы) генә революция булуга социализм әдәбиятын тудыру чарасына керделәр, әле дә шул рухта эшлиләр» [Ибраһимов, б. 248].

«Эш», «Эшче» редакцияләрендә эшләгәннән соң, И. Кули 1921 елдан алып 1932 елга кадәр Татарстан дәүләт нәшриятында төрле вазифалар башкара, мәкаләләр, рецензияләр яза. И. Кулиның шул чорда Ибраһим Терегулов һәм Хөсәен Ямашев кебек милләтебезнең мәшһүр шәхесләренә багышланган мәкаләләре дөнья күрә. Күренекле актер һәм режиссер Г. Кариев турындагы җыентыкның мөхәррире буларак та чыгыш ясый ул («Артист Габдулла Кариев. Тәрҗемәи хәле», 1924 ел).

И. Кули татар язучысы Г. Газиз (Гобәйдуллин Газиз Салих улы) белән берлектә зур күләмле «Татар календаре»н әзерләп бастыра. Бу календарьның берничә басмасы дөнья күрә. И. Әхмәтгалиев бер хатында болай дип яза: «Дәү абыйның Г. Газиз белән чыгарган “Татар календаре”н (1923 ел) карап утырдым. Ул бер китап итеп эшләнгән, 100 битле, зур форматлы. Бик зур мәкаләләр: революция, җир эшләре, мәгариф һ.б. турында; рекламалар... Бик гади тел белән язылган Ленин биографиясе. Татар театрының атасы Кариев, Тукай турында... Татар халык комиссарларының рәсемнәре... Кызык, уйландырырлык әйбер. Тукай урамында хәзерге Тукай музеена каршы кечкенә

бакча эчендә Мулланур Вахитов һәйкәле куелган булган икән. (Тактагачтан эшләнгән пьедестал өстендә гипс-цементтан ярты гәүдәсе, папахалы...) Кая китте икән ул, кем эшләгән икән аны?» [Әхмәтгалиева, б. 45].

И. Кули шулай ук сүзлекләр төзү буенча да эш алып бара. 1927 елда И. Кули, филолог, укытучы Мөхетдин Корбангалиев һәм тел белгече Риза Газизов бергәләп «Русча-татарча сүзлек» әзерләп чыгаралар. Ә 1930 елда язучы, библиограф Исмәгыйль Рәмиев белән берлектә төзелгән «Татар теленең орфография сүзлеге» бастырыла [шунда ук, б. 141].

И. Кулиның өстендә кара болытлар 20 нче еллар уртасында куера башлый. Башка күренекле татар зыялылары кебек үк аны да милләтчелектә гаеплиләр, эзәрлекләүләр башлана. И. Әхмәтгалиевнең тагын бер хатына күз салыйк. Анда хат авторы кыска гына комментарийлар белән түбәндәгеләрне яза: «Дәү абый турында “Казан утлары”нда (№ 7) 164 нче биттә укыгыз. 1926 елны ук ГПУ, обком төзегән яшерен документта: 1) Г. Ибраһимов, 2) Заһид Наркин **(дусты!)**, 3) **И. Кулиев,** 4) И. Рәми, 5) Садрый Вәлидов, 6) Гали Рәхим, 7) К. Тинчурин, 8) Г. Шәрәфләрне – **милләтчеләр дип, эштән “бушатырга” дип язылган»** (26 сентябрь, 1991 ел). Шунда ук хатта И. Әхмәтгалиев И. Кулиның кайчан, кайда, кем булып эшләгәнен дә күрсәтеп үтә: «Дәү абый (И. Кулиев): 1917 елда – Мөселман социалистик комитетының сәркатибе, М. Вахитов – рәис; 1918–1921 елларда – “Эш” гәзите мөхәррире: Губкомда **(Казгубсовтыр)** милли бүлек әгъзасы; “Эшче” гәзитендә (ВКП(б) Үзәк Комитетының Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының үзәк бюросы органы) – сәркатиб; 1921– 1922 елларда – гыйльми секретарь, бүлек мөдире, татар нәшриятында, комбинатта; 1922–1927 елларда – нәшриятта гыйльми секретарь, бүлек мөдире; 1927, IV– мөхәррир **(төшергәннәр инде!)**; 1932, VI – **калькулятор!!!**; 1932, XII – **эштән чыгарылган!!!**» [Әхмәтгалиева, б. 68].

Әйе, 1932 елның декабрендә И. Кули эштән чыгарыла һәм 22 декабрьдә кулга алына. Җинаять Кодексының 58-11 маддәсе нигезендә аны «милләтче баш күтәрүчеләр оешмасында катнашучы» дип нахакка гаеплиләр. Озакламый И. Кулины төрмәдән чыгаралар, ләкин 1935 елның 23 августында ул яңадан кулга алына. Бу юлы инде аны «антисовет әсәрләре язган контрреволюцион төркемдә катнашучы» дип гаепләп, НКВДның Аерым киңәшмәсе чыгарган хөкем карары буенча, өч елга хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрәләр (ИТГ Карлаг) [Книга Памяти..., с. 388]. Ибраһим Кули 1936 елның 31 гыйнварында Караганда өлкәсенең Долинка авылындагы лагерьдә тоткынлыкта вафат була.

И. Кулиның улы, практик радио техникы Салих Кулиевның да (1907 елда туган) язмышы фаҗигале. Казандагы элемтә училищесы директоры булып эшләгән Салихны «троцкистик милләтчелектә, террористик, диверсион оешмада катнашучы», дип гаепләп, мал-мөлкәтен конфискацияләп, СССРның Югары Хәрби суды коллегиясе карары

нигезендә 1938 елның 11 маенда Казанда атып үтерәләр [Книга Памяти..., с. 388]. Сталин репрессиясе корбаннары булган меңәрләгән кешеләр белән бергә аталы-уллы Кулиевлар 1957 елда гына аклананалар.

«И. Кули үз чорында тирән белемле, үз эшенә чын күңелдән бирелгән милләтпәрвәр булып исәпләнгән», – дип язды татар галимәсе Ф. Ибраһимова [Ибраһимова, б. 140]. Әйе, Ибраһим Кули – XX гасыр башындагы татар журналистикасы, әдәбияты һәм мәдәниятендә күренерлек эз калдырган алдынгы яшь татар зыялыларының берсе ул. Заманасының күренекле язучылары, журналистлары, музыкантлары һәм актерлары белән аралашкан кеше. Озак еллар буена И. Кулиның эшчәнлеге татар театры белән бәйле була. Ул күренекле әдип Фатих Әмирханнар белән бергә йорт спектакльләрендә катнашып, татар театрын тудыру юлында башлап йөрүчеләр рәтенә керә [шунда ук]. «Сәйяр» труппасы белән хезмәттәшлек, труппаның репертуарын баету И. Кулины рус пьесаларын татарчага тәрҗемә итүгә алып килә. Драматург Г. Камал, актер Нури Сакаев, язучы Шәриф Камал тәрҗемәләре белән беррәттән, И. Кули тәрҗемәсендә Л. Кирьяновның «Шәфкать туташы», С. Шиманскийның «Кан», испан әдәбиятыннан булып урысчадан «Яңа драма» пьесалары театр труппасының репертуарына керә [Татар театры, б. 66]. И. Кулиның соңгарак тәрҗемәләре арасында итальян язучысы Г. Дригиллиның «Яхшы тегелгән кием» комедиясен һәм актер Зәйни Солтанов белән берлектә рус язучысы П. Карповның «Юлбасар галим» пьесасын билгеләп үтәргә кирәк [шунда ук].

И. Кулиның театрга булган эчкерсез мөнәсәбәте, аңа булган бирелгәнлек, тәрҗемәченең «Сәйяр» труппасы тарафыннан «Шәрык клубы»нда куелган кайбер спектакльләрендә суфлер вазифасын башкаруында да чагыла. Труппа артистлары белән булган тыгыз хезмәттәшлекне без сакланып калган фотографияләрдә дә күрәбез. Әйтик, аларның берсендә И. Кули танылган актерлар Зәйни Солтанов, Касыйм Шамил һәм актер, режиссер Габдулла Кариев белән төшкән. Ә инде «Сәйяр» труппасының якынча 1917–1918 елларда алынган фоторәсемендә И. Кулины без драматург Кәрим Тинчурин, артистлар Заһидә Тинчурина, Әшрәф Синяева, Габдулла Кариев, Ситдыйк Айдаров, Гөлсем Болгарская һәм труппаның башка актерлары белән бергә күрәбез. К. Тинчуринның хатыны Заһидә Тинчуринаның Г. Кариев турындагы истәлекләрендә берничә тапкыр И. Кули да искә алына. Г. Кариев, труппа башлыгы булуына карамастан, күп кенә җитди мәсьәләләрне ялгызы гына түгел, дуслары, аерым алганда, К. Тинчурин, Г. Мангушев, И. Кули белән бергәләшеп, киңәшләшеп хәл итәргә тырыша [Габдулла Кариев..., б. 93] (Мангушев Габдрахман Габделкәрим улы (1887–1919) – актер, журналист, драматург. 1910 елдан «Сәйяр» труппасында, ә 1915 елдан «Ширкәт» труппасында эшли. «Мөхәррир» (1914), «Бәхет эзләүчеләр» (1918) пьесаларының авторы. – *И.Г.*). 1918 елның җәендә труппа таралып, Гражданнар сугышыннан соң театр яңадан аяк баскан көннәрдә дә И. Кули башка артистлар белән кабат театрга килеп кушыла. З. Тинчурина Г. Кариев каты

авырып яткан вакытта аның янында дежур торган артистлар арасында И. Кулиның да булуын искә ала [шунда ук, б. 98]. Татар театрының атасы саналган Г. Кариевны җирләгәндә «мәрхүмнең мәетен кабергә өч кеше – иң якын дусты К. Тинчурин, артистлардан И. Кулиев һәм Колмәмәт төшерә», дип яза З. Тинчурина (Колмәмәт (Хәмид Мөхәммәт улы Азимов) (1895–1942) – актер, сәхнә эшчәнлеген 1915 елда «Сәйяр» труппасында башлап җибәрә. 1922 елдан – Татар академия театрында, ә 1939 елдан Татар күчмә театрында эшли. – *И.Г.*).

Театр, клуб эшләрендә актив катнашкан И. Кули, үзенең йомшак түбән тембрлы баритон тавышы белән, Ибраһим Адамантов исеме астында, үз чорының танылган шагыйрьләренең сүзләренә язылган һәм татар халык җырларын башкаручы буларак сәхнәгә чыга. Кызыклы бер факт. Г. Камал җырчы дустының исемен үзенең «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясенә кертә. Бу әсәрен драматург «Манзара, биш пәрдәдә» дип атый. Бишенче пәрдәсендә әдәбият кичәсендә булган җәнҗал (шау-шу) сурәтләнә. Кичәнең беренче номеры – скрипкада татар көйләре башкарыла, икенчесе – Г. Тукайның «Хатыннар хөррияте» шигырен Фәләнов исемле берәү сөйли, аңардан соң И. Адамантов чыгарга тиеш. Сәхнәгә Дирижер чыга: «Әфәнделәр, программада мәшһүр җырчы Адамантов җырлаячак дип язылган булса да, ул, авыру булган сәбәпле, килә алмады. Шул сәбәптән без аның урынына шәһәребезнең мәшһүр музыка һәвәскәрләрен чакырдык. Хәзер, 3 нче номер – җырчы Адамантов урынына милли музыка һәвәскәрләреннән ясалган оркестр уйнаячак» [Камал, б. 188, 189]. Залда кемдер бу хәбәрне тыныч кына кабул итә, кемдер канәгатьсезлеген белдереп Адамантовны таптыра, тавыш күтәрелә. Ахырда барысы да ризалашып оркестрны тыңлыйлар. Шулай итеп, Г. Камал үзенең бу пьесасында И. Адамантовны халык арасында шактый гына популяр булып киткән җырчы итеп күрсәтә.

И. Адамантовның граммофон тәлинкәләрендәге язмалары безнең өчен аеруча кызыклы. И. Әхмәтгалиевнең чираттагы хатына күз салыйк: «Менә, Мәрьям, Фатих, кызык нәрсә: 1912 елны басылган игълан – татар пластинкалары турында (Кәримовлар сәүдә каталогы, Оренбург, 1912)». Алга таба хат авторы тәлинкәләрне, анда язылган җыр исемнәрен, башкаручыларның исемлеген тәфсилләп китерә. «Димәк, ун тәлинкә чыгарган булган Дәү абый!!! 20 (18) әйберне укыган-җырлаган булып чыга! Кемдә дә булса, берсе генә булса да, саклана торгандыр бит аларның! Китапларны каядыр – архивларда саклаган кебек, тәлинкәләрне дә сакламыйлар микәнни?...», – дигән сорау куя [Әхмәтгалиева, б. 42]. Бу хаттагы мәгълүматка караганда, сүз И. Адамантовның «Граммофон һәм патефон. Татар көйләре пластинкаларының мөкәммәл каталогы»на кергән язмалары турында бара (Типография «Вакыт» в Оренбурге, 1912 г. Торговый дом братьев Каримовых, Оренбург). И. Адамантовның язмалары турында мәгълүматның без икенче каталогта булуын да ачыкладык. Югарыдагыча «Граммофон һәм патефон. Татар көйләре пластинкаларының мөкәммәл

каталогы» дип исемләнгән каталог 1914 елда Уфада борадәран Кәримовларның «Шәрык» матбагасында бастырылып дөнья күрә.

Граммофон тәлинкәләренең каталогларына һәм татар газета-журналларында басылып чыккан тәлинкәләр исемлегенә таянып, шуны әйтергә була – И. Адамантовның тавышын граммофон тәлинкәләренә «Граммофон» ширкәтенең «Зонофон» бүлентек предприятиесе, «Фаворит-рекорд» һәм «Лирофон» фирмалары яздырган. Барлыгы 28 язма.

1909 елның 21–22 июлендә «Граммофон» ширкәтенең агенты булган И.Р. Холмс дигән кеше Казан шәһәрендә татар язмаларының зур сессиясен оештыра. Танылган инглиз дискографы, доктор Алан Келлинең «Көнчыгыш каталогы»ндагы мәгълүмат буенча, бу сессия барышында татар музыкантлары, җырчылары һәм артистлары башкаруында сиксәннән артык язма эшләнгән була [The Gramophone...]. И. Адамантов башкаруында ун язма «Граммофон» компаниясенең «Зонофон» бүлентек предприятиясе тәлинкәләре өчен яздырылган. «Зонофон» тәлинкәләренең каталогында И. Адамантов «мәшһүр татар җырчысы (баритон)» дип күрсәтелгән.

Бу язмалар сессиясендә И. Адамантов башкаруында ике әсәр игътибарны үзенә җәлеп итә. Беренче тапкыр XX гасыр башы татар граммофон язмалары арасында без романс жанрындагы әсәрләр язылганын күрәбез: «Мәхбүс», романс (Г. Камал) (№ X-4-102824) һәм «Төш», романс (Г. Камал) (№ X-4-102825). Г. Камалның бәет стилендә язылган бу шигыре беренче тапкыр 1908 елда Казанда басылып чыга һәм халык арасына таралып бик зур популярлык казана. Г. Ибраһимов үзенең «Яңа әсәрләр» мәкаләсендә болай дип язды: «Татар драма әдәбияты атасы, татар сәхнәсе өчен аның башлап тууыннан алып 16 нчы елларгача үзенең әсәрләре белән зур байлык бирә килгән, “Бүләк өчен”, “Беренче театр” кебек комедияләре белән татар әдәбияты тарихында мәңгелек урын алган Галиәсгар Камал иптәшнең көйләп язарга куәте барлыгы күптән мәгълүм иде. Аның “Мәхбүс” атлы бер мәнзумәсе (дастаны) бөтен татар яшьләре тарафыннан ятланган, унбиш еллар буенча телдән, сәхнәдән төшми йөргән бер нәрсә иде» [Ибраһимов, б. 266, 267]. «Мәхбүс» әсәре XX гасыр башында популяр җырчы К. Мотыйгый-Төхфәтуллинның да граммофон репертуарына кергән. Җырчы аны «Тәфтиләү» көенә яздырган булган.

Күренекле татар журналисты, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй 1914 елда «Йолдыз» газетасында басылып чыккан «Музыкамыз» (граммофоннар) дип аталган мәкаләсендә, башка татар башкаручылары белән беррәттән, И. Адамантовның язмаларына да бәя бирә, аларны тәнкыйть күзлеге аша үткәрә. «Адамантов Ибраһим әфәнденең тавышы салмак, ләкин артык тәрбияле түгел <…> Адамантовның «Төш» дигән җыры бар. Менә шушы «Төш» белән ул ифтихар кыла (горурлана) ала. «Төш» һәйбәт ул, әмма... Адамантов әфәнденең бер зат белән җырлаган көйләре бар. <…> ул зат (Сәхәпзадәме, әллә кем) тәмамәи боза, ямсезли...», – дип тәнкыйтьли С. Сүнчәләй [Сүнчәләй, б. 238].

И. Адамантовның граммофон репертуарында XX гасыр башында шәкертләр арасында бик популяр булган «шәкертләр гимны» – *сада* язмалары да урын ала: «Беренче сада» (№ 4-102828) һәм «Икенче сада» (№ 4-102829) «Зонофон» тәлинкәләренә язылган булган. Искә алып киткән каталогларда И. Адамантовның җырчы Гариф Сәхиб белән дуэтта башкарылган «Сакмар» (№ X-2-104014), «Башмак» (№ X-2-104015), «Ай, нарасый бала» (№ X-2-104022), «Мәхәббәт» (№ X-2-104023) җырлары барлыгы да ачыкланды.

1909 елның ноябрендә Германиядә төпләнгән «Фаворит рекорд» граммофон фирмасы вәкилләре Казан шәһәрендә татар башкаручылары язмаларын эшлиләр. И. Адамантов та бу тавыш яздыру сессиясендә катнаша. Җырчы тарафыннан «ир-ат җырлавы» бүлегендә «Сада I» (№ 1-275055) һәм «Сада II» (№ 1-275056) җырлары язылган. Ә инде халыкныкы булган «Ашказар» (№ 1-275057) һәм «Сәфәр» (№ 1-275058) җырларын И. Адамантов скрипкага кушылып яздырган. «Фаворит рекорд» язмалары арасында без шулай ук җырчының «куплетист» буларак та язылган язмасы барлыгын ачыклыйбыз. «Прикашчиклар, көлке» (№ 1-277001) дип аталган бу әсәрне башкаручы гармоника аккомпанементы астында яздырган. И. Адамантовның сөйләм номерларына килгәндә, аларда узган гасыр башындагы куплетистларның типик репертуары чагыла. Шул чор татар җәмгыятендәге булган байлыкка табыну, комсызлык, эчкечелек кебек ямьсез күренешләрне мыскыллап көлү язмаларның исемнәреннән үк күренеп тора: «Исерек һәм зилзилә. Көлке» (№ 1-277002), «Байлар. Көлке» (№ 1-277003), «Бай бетчә. Көлке» (№ 1-277004).

И. Адамантовның тавышы шулай ук Германиядә теркәлгән «Лирофон» фирмасы тәлинкәләренә дә яздырылган булган. Бу фирманың рус телендә басылып чыккан каталогы болай дип атала: «Каталог двухсторонних пластинок новой казанско-татарской записи. Акционерное общество “Лирофон”. Берлин S.W. 61. Казань, Типография Т-го Дома “Бр. Каримовы”, 1909». Бу каталогта И. Адамантов «халык җырларын һәм романслар башкаручы күренекле җырчы (баритон)» итеп күрсәтелгән. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, җырчының «Лирофон» язмаларынын исемнәре «Зонофон» тәлинкәләрендәге язмалар белән туры килә: «Мәхбүс», романс (Г. Камал) (№ 6019), «Төш», романс (Г. Камал) (№ 6020), «Ашказар» (№ 6021), «Корсын, балам, бу кала» (№ 6022). Язмалар арасында шулай ук дуэт («ике ир тавышы») – И. Адамантов һәм Г. Сәхиб башкаруында «Мәхәббәт», татар халык җыры («6024), «Башмак» (№ 6024), «Сакмар суы» (№ 6026), «Сәлим бабай (хыялый)» (№ 6023) язмалары бар.

И. Адамантов Әхмәт Латыйф исемле тагын бер башкаручы белән бергә – дуэтта, татар-мөселман мәдәниятенең бер чагылышы булган гыйбадәт көйләренең ике үрнәген «Лирофон» граммофон тәлинкәләренә яздырган. «Тәравих (тәсбих Рамазанда)» (№ 6027) һәм «Тәкбир, Корбан бәйрәмендә» (№ 6028) номерлары югарыда искә алган каталогта «Гыйбадәт көе» («Духовное пение») дип күрсәтелгән.

XX гасыр башында татар граммофон язмаларына булган каршылыклы мөнәсәбәт И. Адамантовның язмаларына бәя бирүдә дә чагылыш таба. Әйтик, «Бәянелхак» газетасы битләрендә «Бер татар» исеме астында билгесез автор Казандагы музыка кибетләрендә сатылуга куелган тәлинкәләр арасында Ибраһим Адамантов һәм Гариф Сәхиб әфәнделәрнең фамилияләрен очратуы турында әйтә. Мәкалә авторы, әлегә хәтле бу әфәнделәрнең татар халык җырларын хисле генә һәм җитәрлек дәрәҗәдә чибәр итеп җырлаулары белән аерылып торуларын билгеләп уза. Һәм шунда ук, дуэт башкарган «Сәлим бабай (хыялый)» җырының язмасын бик каты тәнкыйтьләп ташлый. «Борынгы танылган җырның сүзләрен икенче көй белән такмакка әйләндереп җырлап, җырның бөтен мәгънәсен һәм тирәнлеген үзгәрттеләр», – дип яза автор [Бәянелхак].

Монда безгә шул чорның башкару практикасына хас булган үзенчәлек турында әйтеп китәргә кирәктер. Ул да булса – танылган җырларның сүзләрен яңа көйгә салып җырлау, я булмаса, иске көйләрне яңа сүзләр белән башкару, татар сүзләрен урыс көйләренә җырлау. Үзенә күрә бу – узган гасыр башында формалашып килгән татар шәһәр музыкасы мәдәниятенең бер чагылышы, җырларны төрләндерү, яңа интонацияләр, формалар эзләүне күрсәткән бер факт. Кайчак андый тәҗрибәләр, әлбәттә, тыңлаучылар тарафыннан тискәре кабул ителгәннәр. Ләкин ничек кенә булмасын, шул чордагы К. Мотыйгый-Төхфәтуллин, М. Искәндәрова, Х. Юсипов кебек популяр җырчыларның граммофон репертуарында без мондый җыр үрнәкләрен еш очратабыз.

Граммофон музыкасы турында сүз барганда, беренче чиратта, әлбәттә, сакланып калган тәлинкәләрне барлау, өйрәнү, башкаручыларның манерасын, стилен, язмадагы сүзләрне ачыклау, шул язмалар аша татар теленең йөз елдан артык элек булган фонетикасын өйрәнү кебек мөһим эшләрне башкару таләп ителә. Бу күзлектән караганда, граммофон тәлинкәсе татар музыкасы язмаларының тарихын өйрәнү юлында кыйммәтле бер чыганакка әверелә. Өлкән буын музыка белгече Йолдыз Нәкый кызы Исәнбәт белән булган бер очрашуда граммофон язмалары турында аның миңа әйткән сүзләре хәтеремдә нык сакланып калды: «Идрис! Таушалып, кителеп беткән тәлинкәләрдән чыккан, 10–15 секунд кына булса да яңгыраган музыка, җыр, сүз – өйрәнелергә тиеш! Чөнки ул – узган гасыр башы авазы, аның аһәңе!».

Казандагы бер шәхси архивта И. Адамантовның бүгенге көнгә кадәр сакланып калган бер генә граммофон тәлинкәсе барлыгы ачыкланды. «Зонофон»ның бу тәлинкәсендә башкаручының ике җыры язылган. «Граммофон» ширкәтенең 1909 елда Казанда булган сессиясе вакытында язылган язмалар алар. «Гранд» форматындагы тәлинкәнең бер ягындагы этикеткага «Ашказар, народная песня» (№ Х-4-102826), ә икенче ягында – «Курсун, балам» (*«Корсын, балам»*) (№ Х-4-102827) җырлары яздырылган.

И. Адамантов башкарган «Корсын, балам, бу кала» җырында татар хатынының ачы язмышы сурәтләнә. Саладан шәһәргә күчкән татар гаиләсе башлыгы шәһәр тормышының күңел ачу якларын гына күреп, эчкечелеккә, тәртипсезлеккә салынып, хатынын рәнҗетә. Бу хәлләргә түзә алмаган әни кеше үзенең эчке кичерешләрен ачып салып, кызына зарлана, саладагы матур тормышны челпәрәмә китергән шәһәрне, каланы каргап, «Корсын, балам, бу кала», дип җырлый. Бу җыр заманасында бик популяр булган.

Башкорт халык җырларыннан «Ашказар» да XX гасыр башында татарлар арасында киң таралган җырлардан санала. Бу җырның инструменталь вариантлары да, хатын-кыз, ир-ат җырчылар башкаруындагы вариантлар да граммофон тәлинкәләренә теркәлгән. Бер яктан, Ашказар елгасының матур табигате, икенче яктан башкорт кызы һәм аның сөйгән егетенең фаҗигасе сурәтләнгән тирән эчтәлекле бу җырны шул чордагы татар җырчылары бик яратып башкарганнар. Салмак, түбән тавышлы И. Адамантов «Ашказар»ны түбәндәге сүзләр белән җырлый:

1. Һай, уймак кебек кенә, сызылып ага,
   Ашказаркай суының агымы.
   Әй, Ашказаркай суының агымы...
   Күкрәккәемне лә яндырадыр,
   Йөрәккәемнең лә ялкыны.
   Әй, йөрәккәемнең лә ялкыны.

2. Җанкай-җаным китте, ай, сунарга
   Ашказаркай буена чәшкегә.
   Әй, Ашказаркай буена чәшкегә.
   Сунар китеп кенәй вафат булдый,
   Ялгыз башым калды, лай, яшь кенә.

И. Адамантов XX гасыр башы җырчыларыннан беренчеләрдән булып үзенең җырларын фортепианога кушылып яздырган. Заманасы өчен татарлар арасында мондый башкару алдынгылыкка, татар музыкасын Европа үрнәгендәге профессиональлеккә омтылуны күрсәтә. Кызганычка каршы, этикеткада да, каталогта да аккомпаниаторның исеме күрсәтелмәгән. Бу язмаларда фортепиано партиясен кем башкарган икән соң? Игътибарыбызны шуның белән бәйле булган бер кызыклы мәгълүмат җәлеп итә. XX гасыр башындагы татар музыкасы мәдәниятенә зур өлеш керткән данлыклы рус скрипкачысы Илларион Козлов (1861–1933) үзенең «Тарихи доклад»ында хәбәр итүенчә, Казанда граммофон язмаларын оештыручыларның берсе булып танылган халык музыканты – скрипкачы һәм пианист Гали Зайпин (1875–1918) торган. И. Козлов, башка музыкантлар белән чагыштырып, Г. Зайпинның уйнавындагы аерым бер үзенчәлек турында яза: «Фортепианода уйнаганда ул үзенең уенын төрле форшлаглар, пассажлар, арпеджиолар белән бизи һәм бер нотада медиатор белән мандолинода уйнаган кебек итеп уйный иде» [Козлов, 65].

И. Адамантов башкарган «Ашказар» җырын тыңлап анализлаганда без аккомпаниаторның нәкъ шундый манерада уйнаганын ишетәбез. Үзеннән-үзе шундый фараз туа: бәлки бу җырларны И. Адамантов данлыклы Г. Зайпин белән граммофон тәлинкәләренә бергәләшеп яздырганнардыр?!

И. Адамантовның нindидер могҗиза аркасында сакланып калган граммофон тәлинкәсеннән яңгыраган ике җыры 5 минут 15 секунд яңгырый. Бер яктан караганда бу, әлбәттә, бик аз, ә икенче яктан – шул минутлар эчендә яңгыраган тавыш, аһәң безне XX гасыр башына алып кайта, беркадәр андагы мәдәни музыкаль мохитне аңларга ярдәм итә. Шул аһәңнәр безгә татар милләтенең киләчәген кайгырткан шәхесләребезнең берсе, фаҗигале язмышлы журналист, тәрҗемәче һәм җырчы Ибраһим Кули-Адамантов биографиясенең татар граммофон язмалары тарихында калдырган, әлегә кадәр билгеле булмаган сәхифәләрен ачарга ярдәм итә.

И. Адамантовның җырлары граммофон тәлинкәсеннән CDга күчерелеп, туганы Мәрьям Әхмәтгалиевага да тапшырылды. Ибраһим Габделвахит улы Кулиев-Адамантовның исемен кадерләп, аның турындагы истәлекләрне хәтерендә саклаган өчен, без аңа эчкерсез рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Әдәбият**

*Әхмәтгалиева М.* Гомерлек сагыш. Казан: Паритет, 2007. 72 б.

Бәянелхак. № 510, 1909. 25 август.

Габдулла Кариев турында истәлекләр / Коллектив; төзүчесе Х. Гобәйдуллин. Казан. Татар. кит. нәшр. 1967. 230 б.

*Ибраһимов Г.* Дүртенче елга кергәндә (Әдәбият, матбугат хисабы урынында) // Әсәрләр. Сигез томда. 5 том. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 615 б.

*Ибраһимова Ф.* Ибраһим Кули (1885–1936) // Татар әдипләре. Мәгърифәтчеләр. (XX йөз башы): биобиблиографик сүзлек / Кереш сүз авт., фәнни ред. З.З. Рәмиев. Казан: Алма-Лит, 2005. 276 б.

*Камал Г.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 304 б.

Книга Памяти жертв политических репрессий. Том 7. «Кл – Кя» / гл. ред. А.А. Иванов. Казань: Книга Памяти, 2003. 470 с.

*Козлов И.* Исторический доклад // Научная библиотека им. Н.И. Лобачевского КФУ. Отдел рукописей и редких книг. Ф. 6, ед. хр. 22, л.76.

*Сүнчәләй С.* Әсәрләр һәм хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 367 б.

Татар театры (1906–1926). Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: Мәгариф, 2003. 308 б.

*Шамов А.* Яшьлек елларына сәяхәт // Социалистик Татарстан. 1968. 6 март.

The Gramophone Company Limited ZONOPHONE RECORDS. THE ORIENT CATALOGUE / compiled and edited by Alan Kelly. March, 2000. CD-ROM (кульязма).

***Газиев Идрис Мөдәррис улы,***

*сәнгать фәннәре кандидаты, профессор, Россиянең атказанган, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты, Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге дәүләт премиясе лауреаты*

УДК 792.09

***Г. Кәрам***

# КАЗАНДА ТАТАРЧА СПЕКТАКЛЬЛӘР
## (Театр вә музыка кыйсеме)

В статье рассматривается постановка произведения «Сестра милосердия» («Шәфкать туташы») М.А. Кирьяковой на сцене Большого театра. В спектакле задействованы актеры-любители. Особое внимание уделяется игре актеров и дается оценка их актерскому мастерству.

**Ключевые слова:** татарский театр, театральное искусство, спектакль, актеры-любители.

The article discusses the production of the work «Sister of Mercy» («Shuffle Tutashi») by M.A. Kiryakova on the stage of the Bolshoi Theater. Amateur actors are involved in the play. Particular attention is paid to the actors' play and their acting skills are evaluated.

**Keywords:** tatar theater, theatrical art, performance, amateur actors.

Шәрык клубының мәүкыйтан[1] ябылуы шәһәремездә мәдәни вә иҗтимагый хәятемезнең сүнүенә хили[2] сәбәбиять бирде. Һәр атнада милли театр вә милли музыканы күрергә вә ишетергә өйрәнгән Казан халкы бу ел ул әкләнчәләрдән[3] бөтенләй мәхрүм калды: бердән, клубымызның ябылуы, икенчедән, сугыш булу мөнәсәбәте илә бездә театр хәятенең матлубынча[4] дәвам итә алмаячагы көтелә иде. Буңа карамастан, Сәйяр труппасының мөдире Г. Кариев, яшь куәтләрне җәлеп итеп, бер антреприза тәшкил итү ниятенә төшкән иде. Ләкин бала ахирән тәәссефкә каршы[5] түгел антреприза тәшкил итү, хәтта иске артистларымызны да бер ноктага туплый алмады. Болай да күп булмаган артистларымызның күбесе, труппаны ташлап, төрле якка таралдылар. (Мәсәлән, Иманскийлар, Байкиннар, Мангушев вә Сакаев). Ничә еллардан бирле бер һәйәт[6] булып килгән бердәнбер труппамызның болай таралып китүе, табигый бик күңелсез бер хәлдер. Аларның һәрхәлдә тәкрар[7] берләшүләре бик матлубдыр.

Труппаның таралуына күптөрле сәбәпләр булырга мөмкин, ләкин башлыча сәбәпләре – «дахили»дер вә Кариевның бер елдан артык дәвам итеп килгән хасталыгыдыр. Бер ел сугыш исбат итте ки,

[1] Мәүкыйтан – вакытлыча.
[2] Хили – байтак.
[3] Әкләнчәләрдән – күңел ачулардан.
[4] Матлубынча – теләгәнчә.
[5] Тәәссефкә каршы – үкенечкә каршы.
[6] Һәйәт – берләшмә.
[7] Тәкрар – кабат.

гомумән театр галәмендә эшләр көткәннең хилафынча[1] фәукылгадә[2] муаффәкыятьле[3] чыкты. Шуңар стенада Сәйяр труппаны идарә итүчеләр вакытында тауранып[4] бераз аздыру бәйнанә хәрәкәт итеп мәүҗүд[5] труппаны тарату гына түгел, хәтта яшь куәтләрне җәлеп итеп, труппаны тагы да көчәйтергә тиеш иделәр. Ләкин бу эш мәйданга чыкмый калды. Хәзер дә халкымызның театр кеби мәдәни вә әдәби әкләнчәләргә иҗтимагый бик зур вә 35–40 меңле Казан мөселманнары өчен бер труппа күп түгел. Яхшы труппаны һәрхәлдә бик мәмнүният илә күтәрешәчәкләрендә шөбһә юкдыр. Бу сүземезгә 27 ноябрьдә Большой театр сәхнәсендә уйналган «Шәфкать туташы» шаһиддыр. Ошбу спектакль шулкадәр күп халык җәлеп итте ки, бу матди муаффәкыять татар театры тарихында беренче мәртәбәдер.

«Шәфкать туташы» үткән елда «Новый клуб» сәхнәсендә куелып, зур муаффәкыять казанган иде. Былтыр һәммә рольләр яхшы артистларга тапшырылып, уен бик тулы вә мөкәммәл[6] чыккан иде. Бу ел исә бәгъзе бер һәвәскәрләрнең иштиракълары[7] илә уйналды. Ләкин шулай да уен зарарсыз вә тигез уйналды.

«Шәфкать туташы»ның мәүзугы[8] нидән гыйбарәт ителгәнлеге хакында тәфсыйлат бирүне хаҗәт күрмимез (теләгән кеше «Аң» журналының 1914 елгы 13 нче санына мөрәҗәгать итсен).

Драманың уйналуына килсәк, аны муаффәкыятьсез уеннардан дип әйтеп булмый. Һәрбер уйнаучылар мөмкин кадәр матур вә тигез уйнарга тырыштылар вә тамашачыларда яхшы тәэсир калдырдылар.

Иң беренче урынга, шөбһәсез, Болгарскаяны куярга тугры килә. Шактый рухлы вә психологический бер роль. Монда оста артисткага үзенең талантын күрсәтергә зәмин[9] бик иркен.

Болгарскаяны бу уенда уйнамады, бәлки Любаның хәяте илә сәхнәдә яшәде диярге мөмкин. Аның һәрбер хәрәкәте, һәрбер сүзе Любаның зәһәрләнгән хәятенең ачык бер тәрҗеманы иде. Беренче вә өченче пәрдәләрдә ул яңлыш тон (тонъ)[10] алса да, ләкин соңгы пәрдәләрдә, хосусан өченче пәрдәдә тәмамән Любаның роленә кереп, фәукылгадә[11] рухлы вә тәэсирле бер сурәттә уйнады. Аның һичбер яңлыш хәрәкәте, яңлыш интонациясе хис ителмәде. Бары тик өченче пәрдәнең ахырында, Козандиновның йортын ташлап чыгар алдындан, артыграк бер шатлык күрсәтте ки, шул дәкыйкадә[12] генә шулкадәр дәһшәтле

[1] Хилафынча – киресенчә.
[2] Фәукылгадә – гадәттән тыш.
[3] Муаффәкыятьле – уңышлы.
[4] Тауранып – күтәрелеп.
[5] Мәүҗүд – булган.
[6] Мөкәммәл – камил.
[7] Иштиракълары – катнашлыклары.
[8] Мәузугы – сюжеты.
[9] Зәмин – җирлек.
[10] Бу сүз кириллицада бирелгән.
[11] Фәукылгадә – гадәттән тыш.
[12] Дәкыйкадә – минутта.

бер туфандан соң кинәт үзеңне шулкадәр шат хис итү мөмкин түгел. Бу шатлык асылда кайгы яэс[1] илә катыш булырга вә тамашачыларда агыр бер хис калдырырга тиеш иде.

Козандиновны һәвәскәрләрдән Камал уйнады. Һәвәскәрләрдән, әлбәттә, артыкны таләп итеп булмый. Аның өченче пәрдәдә Юлиягә игълан гыйшкы дикъкатене җәлеб итмичә үтте вә шул ук пәрдәдә Любага каршы дәфгатән[2] бик артык ачулы күренде. Козандиновның ачуы тәдриҗән[3] артырга тиеш иде. Ул шулай да үзен сәхнәдә тигез тота белде. Гримы да матур вә муафикъ иде. Бу яшь һәвәскәр яхшы ук өмидле күренә. Тырышса тәрәккый итәчәге[4] шөбһәсездер.

Любаны Гомәрева туташ уйнады. Бу туташның сәхнәгә чыгуы беренче түгел. Гомәреваның үзенең яшьлегенә карамыйча, шулкадәр гыйшвәбазлык итүе[5], күз вә кашлар илә уйнау аның файдасына түгел, бәлки зарарына хезмәт итәдер. Ул сыйфатларның драма сәхнәсенә түгел, бары тик шантан сәхнәләренә генә килешәчәген яшь туташ хәтерендән чыгармасын иде. Аның уйнавы аркасында драманың иң матур роле булган Юлия роле, әлбәттә, бер бад булды (Сара Байкина бу рольдә гаять мөкәммәл[6] уйнаган иде). Ләкин аның драма сәхнәсендә булуы вакытлы бер хәл булдыгындан, аның хакында төрле тәнбиһәләр[7] ясау, әлбәттә, урынсыз булса кирәк.

Матрос Никитаны Кариев уйнады. Аның тавышы хәзер яхшы ук төзәлгән, Никита роле кечкенә булса да, Кариев аны бик көлке вә яхшы йөрәкле бер матрос итеп уйный белде. Шунысы бар, сөйләшкәндә бераз татар ноталары ишетелде. Шулай да аны халык ярат-ты вә былтыргы уйнаучыга караганда ул максатка тагы да якынлашкан иде. Доктор ролендә үзбәк – Тинчурин оста вә тигез уйнады. Ләкин манерларда вә сөйләшкәндә бераз асыллык вә нәзакәт кирәк.

Раиса Куприяновна ролендә Болгарски уйнады. Бу хәйләкәр хатынны ул зарарсыз, хәтта былтыргы Иманскаядан яхшы уйнады. Әлбәттә, асылзадәлек саткан мөтәкәббир[8] бер рус ханымын, бер татар артисты шундан да артык уйный алмас иде, бары тик киемнәре генә бик начар иде. Гомумән артисткаларның бу юлы киемнәре бик фәкыйрьчә иде. Бу алар өчен зур минус. Уенның куелуы яхшы иде. Большой театрның сәхнәсе кечкенә булса да, актык пәрдәдә сугыш мәйданнары вә мәнзарәләре күтелгәннән муаффәкыятьле чыкты.

Дикъкать ителерлек бер хәл. Былтыр бу «Шәфкать туташ»ын кирәк русча вә кирәк татарча уйнаганда, уенның биргән тәэсиреннән күп рус ханымнарына истерика булган иде. Безнең ханымнарда

[1] Яэс – өметсезлек.
[2] Дәфгатән – кинәт.
[3] Тәдриҗән – акрынлап.
[4] Тәрәккый итәчәге – үсәчәге.
[5] Гыйшвәбазлык итүе – гыйшык уйнавы.
[6] Мөкәммәл – камил.
[7] Тәнбиһәләр – кисәтүләр.
[8] Мөтәкәббир – тәкәббер.

андый бер хәл күренмәде. Ахры безнең ханымнарымызның нервлары бик тазадыр.

Театрда халык гаять тә күп иде. Буш урын калмаганлыктан, бик күп халык кире китте вә сборның мең сумга якын булдыгы мәгълүм булды.

---

Югарыда язып үткән идем: бу ел татарча театрны монтазам[1] сурәттә дәвам иттерү фарыз кылынмаган иде. Шулай да 20 ноябрьдә Большой театрда уйналган «Кызганыч бала» вә «Бизәнү» уеннары илә безгә дә театр мәүсимен[2] ачылганга хисап кылырга ярый. Чөнки шул көннән бирле җомга көннәрне спектакль куела вә һәр дәфгасында[3] театрда халык тулы буладыр.

Беренче спектакльдән соң ук «Гөнаһсыз гаеплеләр» исемле русчадан тәрҗемә кылынган бер яңа уен игълан ителде исә дә, ләкин ул бу көнгә кадәр кичектерелеп киленде.

Беренче уендагы матди муаффәкыять труппага яхшы өмид биргән булырга кирәк, чөнки буннан соң сезонны ничек дә булса алып барырга карар бирелгәнлек аңлашылды. Аңа уеннар илә генә бөтен сезонны чыгу мөмкин булмадыгыннан, ара-тирә иске уеннарны да уйнарга тугры киләчәге табигый бер эштер.

Шулай да бу ел труппа исеменнән дүрт-биш данә яңа пьесаларның цензурга йибәрелдеге мәгълүм булды. Ушбу яңа пьесалар, шөбһәсез, бөтен сезонны кысма тәэмин итмеш булачаклардыр.

Шулкадәре бар труппаның кечерәюе бу яңа уеннарның уйналуына күп җәһәттән зарар китерәчәкдер. Труппа исеменнән бәгъзе бер яңа уйнаучыларның чакырылдыгын хәбәр бирелсә дә, ләкин алар киләчәкләрме? Килсәләр дә матлуб булган[4] нәтиҗәне бирәчәкләрме? Мәгълүм түгел.

Эшләр муаффәкыятьле рәвештә барган мөддәттә[5] мин халисана[6] бер киңәш улмак үзрә, һичвакыт кичермичә, арадагы һәртөрле үпкә вә интригаларны ташлап, иң элек милли сәхнәләремезнең булган Сәхибҗамал туташ Гыйззәтуллинаны, аннан соң оста артистымыз Мортазин – Иманскийны вә Сара Байкинаның чакыруларын тәүсыя итә идем.

Минем бу фикеремә милли сәхнәмезне тәкъдир иткән вә аның тәрәккыясене арзу иткән[7] бөтен театру пәрваннның кушылачагына мин әминмен. Сәйяр труппасы үзенең шанын, үзенең шәрәфен югалтасы килмәсә, үзенең киләчәкдә муаффәкыятьле рәвештә дәвамын тәэмин

[1] Монтазам – тәртипкә салынган.
[2] Мәүсимен – сезонын.
[3] Дәфгасында – тапкырында.
[4] Матлуб булган – таләп ителгән.
[5] Мөддәттә – вакытта.
[6] Халисана – чын күңелдән.
[7] Арзу иткән – омтылган.

итәсе килсә, шул милли идея наменә берләшергә тиеш һәм дә бу аның бердәнбер вазыйфасыдыр.

———

Бу көнгә кадәр уйналган уеннарда бәгъзе бу һәвәскәрләр иштиракъ иттеләр вә бәгъзе бер рольләрне алмашырга тугры килде.

«Кызганыч бала»да Гата ролен беренче мәртәбә үзбәк – Тинчурин уйнады. Ләкин бу роль аның файдасына чыкмады. Ул бу роль илә гашыйк рольләрендә дә үзенең кабилиятьсезлеген[1] күрсәтте.

«Бизәнү» комедиясендә Тинчурин яхшы иде. (Дворник ролендә).

Дүртенче декабрьдә Әмирханның «Тигезсезләр»е илә Кариевның «Артист»ы уйналды. Бу матур уен көткәннең, киресенчә бик начар, бик рухсыз чыкты.

Рокыя, Сәлимә, Сөләйман, Закир рольләрендә Таждарова, Болгарская, Тинчурин, Кариев гаҗәп бер сурәтдә дикъкатьсез вә ямьсез уйнадылар. Пьесаның иң матур урыннары, алкышларны муҗиб булган[2] сүзләрне күрелмичә, ишетелмичә үттеләр.

Бу уенда зур артистларымыз үч иткән кеби рухсыз уйнадыкылары хәлдә, һәвәскәрләр билгакес үз дәрәҗәләрендә яхшы уйнадылар.

Гомәр ролендә Габдрахман Камал яхшы ук матур вә тигез уйнады. Бу һәвәскәрләрдә артистлык чаткысы юк түгел, Сакмарский ролендә ул һәркемнең дикъкатен җәлеб итде.

Сәйфулла Насыйбуллин ролендә Кариев бик муафикъ иде исә дә, Закир ролендә матлуб типны бирә алмады. Аның сөйләшүе бик тиз, сүзләрендән бернәрсә дә аңлар хәл юк. Кариевның гадәте: һәрбер сүзне кат-кат әйтә. Һәрбер очраган рольне карт татар рухына тәкълид итәргә ярамый. Моннан әүвәл Закир ролендә Саклиев, һич шөбһәсез, күп мәртәбә артык вә яхшы иде. Яңа һәвәскәрләрдән Айдаров, Вәлишин әфәнделәр зарарсыз, матур уйнадылар.

11 декабрьдә русчадан алынган «Көнче ир» илә Ф. Сәйфинең бер пәрдәлек «Безнең заман» исемле комедиясе уйналды. Бу уеннарның беренчесе – дикъкать вә тәнкыйтькә лаек булмаган бер сафсатадыр. Бу мәгънәсез нәрсәне күпдән сәхнәдән чыгарып ташларга тиеш иде.

Мондый уеннар халыкның зәвыкын боза, җитди артистларның әһәмиятләрен төшерәдер. «Безнең заман» – матур гына милли нәрсә. Бунда Кариев, Г. Камал вә Таждарова үзләренең уйнаулары илә мөхәррирнең максадына якынлашканнар булса кирәк.

Урыны килгәндә шуны да әйтеп узарга кирәк: спектакльләр бик соңга калып башланалар. Бу халыкның тәхәммәлен[3] сүи истигъмаль[4] була. Киләчәкдә буңар юл куймаска тиеш.

[1] Кабилиятьсезлеген – сәләтсезлеген.
[2] Муҗиб булган – барлыкка килгән.
[3] Тәхәммәлен – түземлеген.
[4] Сүи истигъмаль – сынау.

Соңра уен вакытында балалар шаулашып, йөгерешеп, бердән, халыкны тәгъҗиз итәләр[1], икенчедән, уенның яхшы тәэсирен җуялар. Әлбәттә, буңар шул ук театрга килгән халык үзе гаепле. Гаҗибә![2] Театрга балаларын төяп алып килгән ул ата-аналар, балаларның урыны олугларга махсус куелган спектакльләр түгел икәнен белмиләр микәнни? Әгәр белсәләр, ни өчен алып киләләр икән?

*Мәкалә 1915 елда «Аң» журналының*
*21–22 санында (15 декабрь) басылган*

*Текстны басмага әзерләүче*
***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

[1] Тәгъҗиз итәләр – талчыктырдылар.
[2] Гаҗибә – шаккатырлык.

УДК 677.057.53

***Н.М. Мифтахетдинова***

# ТАТАРЧА ЯЗУ МАШИНАЛАРЫ ХАКЫНДА М. ИДРИСОВНЫҢ ХӘРЕФ КОМИССИЯСЕ АЛДЫНДА ЯСАГАН ЧЫГЫШЫ

В Национальном музее Республики Татарстан хранится архив полиграфиста, старшего научного сотрудника отдела новых шрифтов НИИ Полиграфмаш М. Идрисова.

Среди многочисленных документов, рукописей и фотографий, связанных с его научной и профессиональной деятельностью, сохранился доклад, с которым М. Идрисов выступал в 1926 г. на совещании по установлению арабских шрифтов на пишущие машины.

Доклад представляет собой машинопись на арабском шрифте, с рукописными правками и дополнениями автора. Документ богат интересными данными о специалистах в области полиграфии, о системе пишущих машин на татарском языке. Значение его состоит в глубине исследования, сделанного Идрисовым: им проведен анализ наличия и состояния пишущих машин на арабском шрифте в 20-е годы XX века, описан предложенный автором новый подход к приспособлению татарских шрифтов для готовых машин.

Идрисов представил конструкцию, при которой весь алфавит умещается в нижнем регистре. На освободившемся верхнем регистре устанавливаются темные (жирные) буквы.

**Ключевые слова:** М. Идрисов, Шейхали, Мадьяров, пишущая машинка «Гаммонд», «Ундервунд», регистр.

The National Museum of the Republic of Tatarstan stores the archive of a polygraphist, senior researcher at the New Fonts Department of the Research Institute Polygraphmash M. Idrisov.

Among the numerous documents, manuscripts and photographs related to his scientific and professional activities, a report was preserved, with which M. Idrisov spoke in 1926 at a meeting on installing of Arabic fonts on typewriters.

The report is typewritten in Arabic, with author’s handwritten corrections and additions. The document is rich in interesting data about specialists in the field of printing, about the system of typewriters in the Tatar language. Its significance lies in the depth of the research done by Idrisov: he analyzed the presence and condition of typewriters in Arabic type in the 20$^{s}$ of the 20$^{th}$ century, described a new author’s approach to adapt Tatar fonts for ready-made machines.

Idrisov introduced a design in which the entire alphabet fits in lowercase. On the freed upper case, dark (bold) letters are set.

**Keywords:** M. Idrisov, Sheikhali, Madyarov, typewriter «Hammond», «Underwood», register.

Кыйммәтле мәдәни мирасыбызның бер өлеше Татарстан Республикасы Милли музее фондларында саклана. Биредә археология, этнография, нумизматика, төрле диннәргә бәйләнешле раритетлар,

рәсем сәнгате буенча материаллар, кулъязма һәм басма китаплар, газета-8557журналлар, фото һәм документлар тупланган. Аларның һәркайсы халкыбызның үткәнен, гомумән, илебездә барган тарихи вакыйгаларны барларга ярдәм итә.

Татар әдәбияты тарихы һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры музее (Татар китабы йорты) экспозициясен эшләү барышында фонддардагы күп кенә материаллар күтәрелде. Илдә барган сәяси-иҗтимагый вакыйгалар, сәнәгать, мәдәният, халык көнкүрешендәге, уку-укыту, әдәбият өлкәсендәге үзгәрешләр хронологик эзлеклелектә, тарихи яссылыкта өйрәнелде.

Вакытлар үтү белән көнкүрештә киң таралган әйберләр кулланылыштан чыга. Алар урынына яңалары килеп керә, һәм бу әйләнеш эзлеклелеге музей экспонатларында чагылыш таба. Төрле гасырларга караган әйберләрнең бергә туплануы тулаем җәмгыять үсешен күзалларга ярдәм итә.

Җәмгыятьнең технологик яктан алга китүе нәтиҗәсендә бүгенге көндә кулланылыштан төшеп калган язу машиналарының музей фондларында XIX–XX гасырларда эшләнгән үрнәкләре саклана. Татар халкы өчен шунысы әһәмиятле: XX гасыр башында татарча язу машиналарын җитештерү җәмгыятьтә, дәүләт органнарында татар теленең рус теле белән бертигез кулланылышын тәэмин итә. РСФСР күләмендә беренче язу машиналары Казанда җитештерелә башлый.

Танылган полиграфист, татарча язу машинасын уйлап табучы Мөхәммәд Идрисов архивын өйрәнү барышында күп кенә кызыклы материалларга юлыктык. Алар арасында XX гасыр башында илдә кулланылган чит ил язу машиналары һәм аларны татар теленә яраклаштыручы шәхесләр, шулай ук М. Идрисовның әлеге өлкәдәге эшчәнлеген бәян иткән үз кулъязмасы саклана. Ул – М. Идрисовның 1926 елда Казанда үткәрелгән язу машиналарына гарәп шрифтын урнаштыру турындагы киңәшмәдәге чыгышы. Әлеге кулъязма уйлап табучы, белгеч күзлегеннән язылуы белән дә кыйммәтле чыганак булып тора. Оригинал гарәп шрифтында язылган. Укучы игътибарына ул үзгәртүләрсез, беркадәр аңлатмалар белән тәкъдим ителә.

*М. Идрисов*

**Язу машинасы турында ясаган докладым**

Бу докладымда бу көнгә кадәр гарәп хәрефле язу машиналарын чыгу тәртибе белән санап, һәркайсына аз гына булса да тукталып, аларның җитешсез якларын күрсәтмәкче булам. Һәм шушы докладның дәвамы итеп, үз тарафымнан тәкъдим ителә торган гарәп хәрефле язу машинасы хакында да бер кушма доклад ясап, барысын бер йомгакка җыярга уйлыйм.

1. Ремингтон машинасы – Америкада XX йөз башында гарәпләр өчен ясалган. Хәрефләре 4 шәкел әсасында булып, тәнкыйтьтән түбән дәрәҗәдә бик ямьсезләр. Хәрефләрнең барлык шәкеле бөтен хәлендә

машинага кереп бетмәгәнгә күрә, нокталар (точкалар) аерым беркетелгәннәр. Койрыклы ахыр, ялгыз хәрефләргә дә койрык аерым сугыла торган итеп ясалган. Шул рәвешчә, ахыр «п» ны язу өчен иң әүвәл сугарга, икенчеләп ں сугарга, аннан соң югары регистр төймәсенә төртеп, дүртенче хәрәкәттә ۛ сугарга кирәк.

Бу машинада язуы әйтеп бетергесез авыр һәм эш үрчемсез булганлыктан, машинаны бала-чага өчен генә яраарлык дияргә туры килә.

2. Гаммонд машинасы. Бу машинада пластинкасын алмаштырып кую белән нинди генә телдә булса да язып була. Яһүдчәдә язарга кирәк булганга, машина ике якка таба йөри торган итеп ясалган. Шуннан файдаланып, 1913 елда мин шул машинага хәрефләр язып биргән идем. Рычагны тарту белән русча язарга да мөмкин иде. Шул вакытта баш хәрефне гамәлгә кую ерак ихтималлардан саналганга күрә, әлифбаны дүрт шәкелдән язып бирергә туры килде. Әлбәттә, барлык шәкел машинага кереп бетмәгәнлектән, точкалар төп билге белән бергә булсалар да, койрыкны аерым сугыла торган итеп ясалды. Хәрефләре бик ямьсез түгел иде. Яурупа сугышы башланып калмаса, бу машина ул вакытта күп кенә таралып калган булыр иде.

Шулай итеп, бу машинага хәреф кую бер тәҗрибә генә булып калды.

3. Мадьяровлар – 1922 елда Мәскәүдә эшли башладылар. Болар гади язу машинасын кирегә йөри торган итеп, шуңа үзләре хәреф кисеп урнаштырдылар. Хәреф урнаштыру системасы дүрт шәкелле булып, «Гаммонд» машинасындагы ысулдан артык аермасы юк иде. Борнаш ысулында матбага хәрефе чыккач, машинага ике шәкелле хәреф кисеп куя башладылар. Шәехгали иптәш шикелле алар да, хәрефнең киңлегенә карап, машинаны ике төрле сикерештә ясый башладылар. Хәзерге көндә «точный механика» трестында шул ике сикереш үзгәрмәләрен күпләп чыгару өчен калыплар әзерләнеп куелган. Алар үзгәртәчәк машинаның СССРда бар кадәрлесе истигъмальгә[1] кереп беткәнлектән, машиналарны заграницадан алдырырга туры киләчәк. Ләкин ул фирма алар чамалаган машинаны чыгаруны туктатканлыктан, аларның барлык техника әзерлекләре бушка чыкты – әрәм булды дип ишетелә. Шулай итеп, Мадьяров иптәшләр «смесь-примьер» фирмасының иске машиналарын төзәтеп, шуңа төрле үзгәрешләр кертүдән артык уза алмадылар. Алар эшкә керешкәнгә 4 ел тулды инде, алай да эшкә яраарлык бер машина чыгара алганнары юк әле.

4. Алпар хәрефләре куелып ясалган машина – Ташкентта Алпар иптәш язмасы белән хәреф кисеп чыгарып карадылар. Алпар иптәш баш хәрефләргә койрык кушу әсасында эшләде. Мадьяровларча машинаның үзенә үзгәреш керткәне беленмәде. Бу яктан караганда аның ысулы белән язу машинасы тизрәк барлыкка килергә тиеш иде. Ләкин ул башлаган эшен дәвам иттермәде. Хәзерге көндә ул якларда

[1] Истигъмальгә – кулланылышка.

гарәп хәрефеннән һич хәбәре һәм ул эшкә һичбер мөнәсәбәте булмаган кешеләр котчыккыч ямьсез хәрефләр белән иске язу машиналары сатып көн күрәләр.

5. Казанда Татарстан Дәүләт мастерскоенда эшләнгән Шәехгали машинасы. Бу иптәш, машинаның кирегә йөртүдән башка, гарәп хәрефләренең киңлегенә карап, машинаның сикерешен төрләндергән. Әлифкә – бер миллиметр калынлыкта, «б»ларгә – ике, «җ»ләргә – өч һәм «с», «ш»ларга дүрт миллиметр кадәр сикереш ясаган. Шушы төрле сикерешләр керткән. Хәрефләр баш хәреф әсасында киселеп, барлык галәмәт түбәнге регистрга кереп бетәрлек булган. Өстәвенә буш калган югары регистрга русча хәрефләр урнаштырырга мөмкинлек табылган.

Шәехгали иптәш тә, Мадьяровлар шикелле үк, машинага үзгәрешләр кертү белән зур читенлекләр тудырганга күрә, бу көнгә кадәр аның да күпләп машина чыгара алганы юк.

6. 1925 елда Германиядә ясалган машина. Бу машина да «б», «җ»ләргә – бер, «с», «ш»ларга ике сикереш ясалган һәм хәрефләре 4 билге әсасында эшләнгән. Барлык билгеләр сыешмаганга күрә, тагын бер регистр арттырганнар. Аның өстәвенә тоташ хәрефләр дә куеп азапланганнар (кирәк дип белгәннәр ахры). Язганда әледән-әле регистрларга күчеп торырга кирәк булганлыктан, бу машинада эш бик үрчемсез, хәтта мөмкин түгел дәрәҗәсендә читен һәм авыр.

7. Ундервуд машинасы 1926 елда килде. Яурупа-Америкада кулланыла торган машинаның кирегә йөри торганы, шулай ук ике сикерешле. Борнаш системасы шикелле ике билгеле хәрефләр. (Борнаш алардан күргәндерме яки алар Борнашныкын алгандырмы, анысын белеп булмады.) Бер төймәдә ике төрле сикереш ясалган. Түбәнге регистрда «б»гә бер сикереш, югары регистрдагы ялгыз «б»гә ике өлеш киңрәк сикереш ясый. Югары регистрга ялгыз хәрефләр урнаштырылган. Машина гарәпләр өчен эшләнгәнгә күрә, безгә кирәкле билгеләрнең берсе дә юк. Киресенчә, кирәкмәс билгеләр күп. Цифрлар искечә, тыныш билгеләре берсе дә куелмаганнар. Хәрефләре күренешкә бик [...оригиналда өзеклек. − *Н.М.*]

Түбәндәге күңелсез нәтиҗәләр туды: хәреф урнаштыру эшеннән башка, машинаның үзен чуарлауга әллә никадәр вакыт һәм көч исраф ителде, күп акчалар түгелде. Шуның аркасында машинаның дөньяга чыгуы кичекте. Таратып ташлаганчы, яхшы гына эшли торган машина соңыннан калтырап кына эшли ала торган яки бер дә эшләми торган булып чыкты. Кирәкмәскә машина рәнҗетелде, бозылды, эшкә ярамаслык хәлгә китерелде.

Болар өстенә тагын бер куәтле факторны әйтеп узмый булмый. Бу машиналарда язган вакытта киң хәрефтән соң сугылган хәрефләр шул киң хәреф өстенә барып төшә торган булды. Болай булмасын өчен, киң хәреф сугылганнан соң, машинаның кареткасы тиешле урынына барып утырсын өчен, киләчәк хәрефне сукканчы бераз көтебрәк торырга кирәк була торган булды. Машинада язучының тиз сугарга

өйрәнгән бармакларына, машинаның кареткасы сикерүенә карап, төрле-төрле интерваллар-паузалар ясап бару мөмкин эшләрдән булмаганга күрә, болай акрын язарга кирәклек мәҗбүриятен машинаның зур кимчелекләреннән санарга кирәк.

Менә хәзер мин тәкъдим итә торган язу машинасы бу әсасларга бөтенләй хилаф рәвештә эшләнде. Хәрефләрне баш хәреф әсасында кисеп, шул гади машиналарның сикерешенә яратырга тырышылды. Ачыграк итеп әйткәндә, башкалар кебек машина хәрефкә түгел, бәлки хәреф машинага яратылды. Моннан соң машиналарда баш хәреф белән генә язу имкяне табылганлыктан, ялгыз хәрефләр төшеп кала торган булгач, баш хәрефләр өчен төрле сикереш ясауның һич кирәге булмаячак. Дөрес, бу машинага урнаштырылган хәрефләр арасында беренче карауда «с», «ш» хәрефләре бик үк килешле булып тормыйлар. Ләкин ул ике хәрефнең генә килешеп бетмәве белән машинаны эштән чыгару-вату арасында күп аерма бар. Русларда да «ш» хәрефе гадәттәгедән таррак эшләнгән, аңа карап машинаның йөрешен үзгәртергә һич кирәк булмаган. Заграницада соңгы вакытларда сөйләгәнне үз-үзеннән язып бара торган язу машиналары ихтираг ителгәндә[1], шул ук заграницадан эшләнеп килгән гади язу машиналарын безгә ярамый дип, сүтеп үтерүебезне әллә ничек акылга сыймый торган эшләрдән дип әйтәсе килә.

Машинага минем тарафтан тәкъдим ителгән ысул белән хәреф урнаштырганда, хәрефләрне беркетү чыгымыннан башка бер чыгым да булачак түгел. Машинаны заграницадан алгач, бер генә винтын да борыштырмыйча, үзгәртмичә үзебездә әзерләнгән хәрефләрне беркетү белән бер-ике көннән соң шул ук машинада теләсәң нәрсә язарга мөмкин булачак. Машина үзгәртү өчен үзенә хаслап мастерской ачуның да һич кирәге юк. Менә мәсьәләнең әһәмиятле ноктасы да шушында. Болай эшләгәндә, машина да очсызга төшәчәк һәм дөньяга чыгуы да тиз булачак.

Болардан башка бу машинадагы хәрефләрнең күренешләре турында булган тәҗрибәләремне дә әйтеп узмакчы булам. Русча язу машинасы белән кәгазьдә «ленинизм» дип язылган сүз күртеген (иероглифны) нинди озынлыкта укырга өйрәнгән булсак, шул ук сүзне гарәп хәрефләре белән дә «ленинизм» дип, шул ук озынлыкта уку күзгә һич ят тоелмый. Киресенчә, кыскартылган яки тарайтылып язылган сүзләрне уку читенрәк була. Мәсәлән, кибет вывескаларында хәреф никадәр эре булса да, сыймаганга күрә тарайтылып язылган сүзләр читенлек белән генә укылалар. Шуның шикелле үк язу машинасында да хәреф билгеләрен тарайтып, машинаның йөрешен кысу гади машиналарда язылган русча сүзләрне мәгълүм бер киңлектә укып өйрәнгән күзләргә байтак читенлек тудырачак. Шуңа күрә дә машиналарның юллары, бу яктан караганда да, башка милләтләргә яраган машинаның йөрешен безнең хәрефләр өчен генә үзгәртүгә һич

[1] Ихтираг ителгәндә – уйлап чыгарылганда.

урын юк. Машинага минем тарафтан урнаштырылган хәрефләрне киң диючеләр дә булды. Алар, бу хәрефләр кәгазьдә урын күп ала, диләр. Әлбәттә, матбага хәрефләренә чагыштырып әйтәләр. Ләкин (алар) башка милләтләрдә дә язу машинасы хәрефләренә караганда күп киң һәм зуррак итеп эшләнгәннәр. Чөнки язу машинасында язылган эш кәгазьләренең хәрефләре һәркем җиңел укый алырлык рәвештә ачык һәм эрерәк булырга тиешле. Шулай булгач, машиналарга урнаштырылган гарәп хәрефләренең тар һәм вак булуларын теләү, безнең эшче-крестьянның аң-белем дәрәҗәсен хәтергә алганда, бигрәк тә урынсыз дип беләм.

Латин һәм рус хәрефләрен язганда, бер үк үлчәүдәге киңлеккә никадәр тавыш билгесе керсә, мин тәкъдим иткән ысул белән урнаштырылганда, гарәп хәрефләре дә бер үк санда керәләр яки артык керми. Аннан соң бу вакытта кайчан да булса бер хәрефләрне латин яки рус хәрефләре белән алмаштырырга туры киләчәк булса, машина һаман да эшкә яраячак! Сикерешләр үзгәртеп торганга күрә, кадере кимемәячәк. Латин хәрефләренә күчү шикелле бер үзгәреш алда торганда, мәсьәләнең бу ягына да күз йомып узарга туры килми.

Язу машинасында хәреф билгеләренең санын тәгаенләү турында да берничә сүз әйтеп китмичә булмый. Чөнки моңа кадәр чыккан гарәп хәрефле язу машиналарында эшләү, хәреф билгеләре күп булганлыктан, бик үрчемсез һәм комачаулы була. Язганда әледән-әле югары регистрга күчәргә туры килә. Сул бармак югары регистр төймәсен төртеп торудан бушый алмый. Шуңа күрә әлифбадагы бер генә хәреф билгесе дә югары регистрга чыккан булмаска тиешле. Менә машинада шуңа аерым дикъкать ителгән югары регистрда буш калган урыннарга эре яки симез хәрефләр урнаштырырга яки рус һәм латин хәрефләре куярга мөмкин. Баш хәрефләрне гамәлгә куя башлау хәзерге көндә язу машинасына бер әлифба гына түгел, бәлки ике зурлыкта яки ике телдә хәреф билгеләре сыйдырырга юл ачты. Докладны тәмамлау алдыннан, язу машинасына гарәп хәрефләрен урнаштыру турында киңәшмәгә шушы тәкъдимемне кертәм:

1. Киң булган ялгыз һәм ахыр хәрефләр гамәлдән чыгарылып, баш хәрефләр генә калганга һәм язу машинасына өстәмә чыгынтылар ясау машинаның эшкә ашуына, күп таралуына киртә булганга күрә, машинага төрле сикереш ясау әсасын бөтенләй ташлап, хәрефләрне гади язу машиналары йөрешенә яратырга.

2. Машинада язуның үрчемле булуын күз алдында тотып, барлык хәреф билгеләрен машинаның түбәнге регистрына урнаштырып бетерергә. Менә минем тарафтан тәкъдим ителә торган машинаның төзелеше шушы төп ике нигезгә корылган.

*Текстны басмага әзерләүче һәм кереш сүз язучы:*
***Мифтахетдинова Нурия Мидхәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы*
*Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

# ИСЕМНӘР ХАЛЫККА КАЙТА: ИСХАК ӘХМӘРОВКА БАГЫШЛАНГАН ЯҢА КИТАП ТУРЫНДА

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгы – илебез тарихында әһәмиятле дата. Бу уңайдан күпсанлы әдәби китаплар һәм фәнни хезмәтләр нәшер ителде. Күптән түгел Чиләбедә басылып чыккан «Отец и сын Ахмеровы: выбор резидента» дигән китапны да шулар арасына куярга мөмкин. Аны документаль проза жанрына кертергә була.

Китапның авторы – Чиләбедә туган якны өйрәнүче буларак танылган тикшеренүче һәм публицист, ә көндәлек тормышта – табиб, сәламәтлек саклауны оештыручы Анатолий Владимирович Шалагин. Туган якны өйрәнүче буларак, ул тормышлары теге яки бу дәрәҗәдә Көньяк Урал төбәге белән бәйләнгән күренекле фигуралар белән һәрвакыт кызыксынган. А.В. Шалагин – татар сәүдәгәрләренең күренекле эшлеклеләренә багышланган мәкаләләр һәм очерклар да бастырган кеше. Әмма разведчик Исхак Әхмәров фигурасы, аның тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнү иҗатының һәм фәнни эзләнүләренең магистраль темасына әверелә.

Исхак Әхмәров турында 10–15 еллар элек кенә сөйли башладылар. Аңарчы аның исеме бик сирәк кешегә билгеле иде. Хәер, бу – чын разведчикның профессиональлеге дәрәҗәсе күрсәткече. 2007–2008 елларда «Идел» журналында А.В. Шалагинның «Между Сциллой и Харибдой» һәм «Черный лотос» дип исемләнгән ике документаль-әдәби повесте чыга. Аларның төп герое Исхак Әхмәров була. Бу публикация укучыларда зур кызыксыну уята, күп кенә тикшеренүчеләрне, журналистларны һәм язучыларны И. Әхмәровның биографиясен мөстәкыйль өйрәнүгә этәрә. Шул вакыттан бирле безнең күренекле милләттәшебезгә багышланган дистәләгән яңа мәкаләләр һәм очерклар дөнья күрде, аның турында романнар язылды, документаль фильмнар төшерелде. Чиләбедә И. Әхмәровка һәйкәл куйдылар, Казанда «Разведчик Әхмәров» урамы барлыкка килде.

Һәм менә хәзер тулы кыйммәтле фәнни-документаль тикшеренү укучылар хөкеменә чыгарыла. Авторга бик зур тикшеренү эше башкарырга туры килгән, күп кенә яңа, әлегә кадәр аз билгеле документлар әйләнешкә кертелгән, алар Исхак Әхмәров образын күз алдына китерергә, аның вакыйгаларга бай биографиясенең аерым мизгелләрен торгызырга ярдәм итә. Шуңа да карамастан, кайбер эпизодлар әле һаман да кадр артында» кала, бу, һичшиксез, аның эшчәнлегенә хас үзенчәлек, Исхак Әхмәров катнашкан операцияләрнең мөһимлеге һәм яшеренлеге белән бәйле. Яңа китапның өстенлеге шунда: А.В. Шалагин архивлардан күренекле разведчикның тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле моңарчы билгеле булмаган берничә фоторәсем табып, аларны беренче тапкыр әйләнешкә кертеп җибәрә алган.

Исхак Абдулла улы Әхмәров (1901–1976) – һичшиксез, күренекле һәм ординар булмаган шәхес. Троицки шәһәрендә (ул вакытта Оренбург губернасына кергән) гади татар гаиләсендә туып, ул АКШтагы совет резидентурасы җитәкчесе дәрәҗәсенә кадәр үскән. Икенче бөтендөнья сугышы елларында ул «күзгә күренми торган фронт»та мөһим фигураларның берсе булган, әһәмиятле сәяси вакыйгаларга йогынты ясаган. Дәүләт департаментындагы, Чит илләр икътисады идарәсендәге, Хәрби сәнәгать департаменты, ФБР идарәләрендәге, юстиция департаментындагы һәм АКШның башка дәүләт оешмаларындагы кыйммәтле чыганаклар Әхмәров кулында булган.

«Манхэттен проекты»на (кодлы исеме) ул турыдан-туры мөнәсәбәтле булган, СССРга атом бомбасын булдырырга мөмкинлек бирәчәк күп кенә кыйммәтле мәгълүматлар тапкан.

Китап авторы И. Әхмәровның АКШтагы легаль булмаган эше белән бәйле күп кенә кызыклы фактлар китерә. Мәсәлән, ул совет резидентының үзен ничек яшерә белгәнлеге турында җентекләп сөйли. АКШның мөһим стратегик үзәге булган Балтиморда (Вашингтоннан ерак түгел), шәһәр портыннан ленд-лиз программасы буенча йөкләр җибәрелгәнгә күрә, Әхмәров мех кибете ачып җибәргән, ул халык арасында зур уңыш казанган. Бу эштә аңа әле революциягә кадәрге тәҗрибәсе ярдәм иткән, чөнки ул Россиядә үз бабасының мех кибетендә ярдәмче булып эшләгән.

Нәтиҗәдә, совет резиденты бик күп кешеләр белән танышу мөмкинлеге алган. Аңа АКШ Финанс министрлыгы, Икътисади сугыш идарәсе һәм башка оешмалар агентлары мәгълүмат җиткереп торган. Аның өчен иң кыйммәтле чыганакларының берсе Британия разведкасының Нью-Йорктагы координация үзәгендә эшләгән инглиз разведчигы «Чарли», шулай ук Америка разведкасы җитәкчесенең шәхси ярдәмчесе булган.

Бу кешеләр аша Әхмәровка бик зур мәгълүмат агыла, аны тиз арада Үзәккә тапшырырга кирәк була. Соңрак 1942 елда – 59, 1943 елда – 211, 1944 елда – 600, 1945 елда 1896 микропленкалы катушканың Мәскәүгә килүе турында мәгълүм була. Алар 75 000 биттән торган яшерен мәгълүматны үз эченә алган.

АКШтан тыш Исхак Әхмәров Төркиядә, Кытайда да эшли, анда да мөһим дәүләт бурычларын үти. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, аның биографиясенең бер өлеше ата-бабаларының туган җире саналган Татарстан белән бәйле булган. 1921 елга кадәр ул үзе дә Казанда яшәгән һәм эшләгән.

Татарстан тарихы өчен Исхак Әхмәров тормышының Казан чоры белән бәйле моментлары мөһим. Бу революциядән соңгы беренче еллар була: шәһәр ак чехлар кулына күчкән вакыт. 16 яшьлек яшүсмер 1918 елның 7–8 августында Казанда ак чехлар һәм каппельчеләр оештырган канлы сугышның шаһиты була. Ул көннәрдә шәһәрдә меңнән артык совет власте яклылар атып һәм суеп үтерелә. Бу вакыйга, китап авторы фикеренчә, «аның дөньяны кабул итүенә бик нык тәэсир итә».

Булачак тормыш юлын Әхмәров Казанда сайлады дип әйтергә тулы нигез бар, киләчәктә разведчик булу турындагы карарга ул мөгаен нәкъ менә биредә килгән.

Китап тере һәм аңлаешлы тел белән язылган, аның сюжеты укучыга бик көчле йогынты ясый һәм ахыргача киеренкелектә тота. А. Шалагинның яңа китабы Казанда зур тираж белән (шул исәптән татар телендә дә) басылсын иде дигән теләктә калабыз.

***Ахунов Азат Марс улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

**2020 елның 27 мартында** Халыкара театр көне уңаеннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында «Тантана 2020» театр премияләрен тапшыруга багышланган чара уздырылды, ул онлайн-трансляция форматында тәкъдим ителде.

Театр сәнгате өлкәсендәге әлеге профессиональ премия «Дебют», «Эпизодта иң яхшы роль», «Курчак театрының иң яхшы актеры», «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле», «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» , «Музыкаль спектакльдә иң яхшы роль», «Актерлар ансамбле өчен», «Иң яхшы хатын-кыз роле», «Иң яхшы ир-ат роле», «Балалар өчен иң яхшы спектакль», «Намус һәм тугрылык» номинацияләрендә иҗатта, җәмәгать эшчәнлегендә аерым казанышларга ирешкән артистларга тапшырылды.

**2020 елның 26 апрелендә** татар халкы бөек шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 134 ел тулуны билгеләп үтте. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салды.

Туган тел көненә һәм Габдулла Тукайның тууына 134 ел тулуга багышланган барлык тантаналы чаралар онлайн-форматта үткәрелде. «Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалында бәйрәм фильм-концерты күрсәтелде һәм 2020 ел лауреатларының исемнәре игълан ителде. Татарстан Язучылар берлегенең социаль челтәрләрендә шигърият бәйрәме оештырылды, флешмобта танылган әдипләр, Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүче галимнәр, шул исәптән күрше төбәкләрдән һәм чит илләрдән вәкилләр катнашты.

К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры, «Әкият» курчак театры, Татарстан Республикасы Милли музее, Г. Тукайның Казандагы әдәби музее, Казан федераль университеты һәм башка оешмалар тарафыннан да социаль челтәрләрдә онлайн-чаралар һәм марафоннар оештырылды.

**2020 елның 26 апрелендә** Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителде. Агымдагы елда әлеге мәртәбәле премиягә Лирон Хәмидуллин («Дәрдмәнд», «Буранлы төндә», «Зарницы на горизонте» китаплары өчен), Денис Осокин («Огородные пугала с ноября по март» җыентыгы өчен), Идрис Газиев (татар композиторлары һәм халык җырлары әсәрләреннән аерым башкару программалары, музыкаль-мәгариф эшчәнлеге өчен); Юрий Александров, Гөлнара Гатина, Виктор Герасименко, Ринат Салаватов (Резеда Ахиярованың «Сөембикә» операсын куйган өчен) лаек булды.

**2020 елның 21 маенда** Халыкара Төрки академиянең оешуына 10 ел тулу уңаеннан «Абай һәм XXI гасыр: чор дәвамчылыгы» темасы буенча халыкара онлайн-конференция үткәрелде. Конференция күренекле казакъ шагыйре, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе Абай Кунанбаевның тууына 175 ел тулуга багышланды. Әлеге чарада

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре дә катнашты, пленар утырышта әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов «Татар-казакъ әдәби багланышлары һәм Абай» темасына чыгыш ясады.

**2020 елның 27 маенда** Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы турында» Декретка кул куюның 100 еллыгына багышланган парламент утырышы узды. Тантаналы утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин, парламент фракцияләре вәкилләре, хөкүмәт әгъзалары катнашты.

Тантаналы чарага «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарының махсус саннары әзерләнде, аларда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның республиканың 100 еллык юбилеена багышланган мәкаләсе һәм республиканың беренче Президенты, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең интервьюсы басылды.

Утырыш башланыр алдыннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашында әлеге дата хөрмәтенә чыгарылган почта маркасына мөһер кую тантанасы һәм истәлек тәңкәсен тәкъдир итү оештырылды.

Тантаналы утырышта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Татарстан АССРның 100 еллыгы: үткәне һәм бүгенгесе» темасына төп доклад белән чыгыш ясады. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Татарстан парламентаризмы үсешенә зур өлеш керткән татарстанлыларга «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медален тапшырды.

Утырыш нәтиҗәләре буенча Татарстан министрлыклары һәм ведомстволарына, иҗтимагый һәм фәнни оешмаларга карата тәкъдимнәр белән киңәйтелгән Карар кабул ителде.

**2020 елның 27 маенда**, ТАССР төзелүгә 100 ел тулуга багышлап, Татар халкы һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы музеенда «Алга – үткәнебезгә» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Экспозициядә Татарстан Республикасы предприятиеләре, Чаллы шәһәре тарихи-туган якны өйрәнү музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы материаллары урын алды.

Күргәзмә республиканың фән, сәнәгать, оборона җитештерүе, авыл хуҗалыгы өлкәләрендәге төп казанышлары, шулай ук эре предприятиеләр эшчәнлеге белән таныштыру максатыннан оештырылды. Ул 2020 елның 20 сентябренә кадәр эшләячәк.

**2020 елның 27 маеннан 9 июненә кадәр** Казан федераль университетында педагогик белем

бирү буенча VI Халыкара VIFTE (International Forum on Teacher Education) форумы үткәрелде. Форумның төп эш юнәлешләре буларак, заманча педагогик белем бирүне цифрлаштыру, квалификацияне күтәрү һәм «цифрлы аерма» шартларында педагогик кадрларны яңадан әзерләү, булачак укытучыны әзерләүдә цифрлы технологияләр куллану һәм башкалар билгеләнде.

Виртуаль форматта үткәрелгән чарада Россиянең 200 гә якын һәм чит илләрнең 70 тән артык югары уку йортларыннан әйдәп баручы галимнәр катнашты. Төп спикерлар буларак Алексей Лубков (Мәскәү педагогика дәүләт университеты, Россия), Иен Джеймс Ментер (Оксфорд университеты, Бөекбритания), Марджери Макмахон (Глазго университеты, Бөекбритания), Мария Асунсиао Флореш (Миньо университеты, Португалия), Конор Гэлвин (Дублин университеты, Ирландия), Мурат Чошанов (Эль-Пасода Техас университеты, АКШ) һәм башкалар чакырылды.

**2020 елның 29 маенда** Казан дәүләт мәдәният институтында «Полимәдәни җәмгыять шартларында күпдәрәҗәле тел әзерлеге» VII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Чара галимнәр, югары уку йортлары һәм һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары, аспирантлар һәм студентлар катнашында онлайн-режимда үткәрелде. Конференциягә җиде юнәлеш буенча фәнни докладлар кабул ителде, пленар утырыш һәм секция эшләре оештырылды.

**2020 елның 8 – 17 июнендә** онлайн-форматта VI «Нәүрүз» Халыкара театраль-белем бирү фестиваль-форумы үткәрелде. Чара кысаларында театр педагогикасы, актерлык осталыгы, курчак театрында режиссерлык һәм актерлык сәнгате, менеджмент, PR-технологияләр, сценография, театраль тәнкыйть, театрның әдәби һәм иҗади-кую бүлегенең эшчәнлеге буенча лекцияләр, семинарлар, лабораторияләр һәм «Вызовы разума» дип аталган фәнни онлайн-конференция узды. Фәнни конференциянең AKT-ZENT Бөтендөнья театраль треннинг институты, ЮНЕСКО каршындагы Халыкара театр институты (ITI), «Нәүрүз» Халыкара театраль-белем бирү фестиваль-форумы тарафыннан оештырылды.

Фестиваль-форумда Германия, Колумбия, Польша һәм Россиядән әйдәп баручы белгечләр, театр сәнгате һәм менеджмент өлкәсендәге күренекле шәхесләр катнашты.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2020. № 2

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: .07.2020. Басылды: .07.2020.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12,5. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла